**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ**
**МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ**
**МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫның МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫНЫҢ**
**«АБДУЛЛА АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ 20 НЧЕ ГИМНАЗИЯ»**
**ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

# *«Алиш эзләреннән»*

***VIII бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе тезислары җыентыгы***

Казан – 2021 нче ел, февраль

УДК 37.01:821.512.145
ББК 74.202:83.3Тат
А 50

**Төзүчеләр:**

**Рәхимә Минвәли кызы Арсланова –** Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия директоры, К. Насыйри исемендәге премия лауреаты

**Фәрхетдинова Эльмира Мингазизовна –** Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең директор урынбасары, җәмгыять белеме укытучысы

**Редколегия әгъзалары:** Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучылары: Л. Г. Ефимова, башлангыч сыйныф укытучылары Л. Ф. Гизатуллина,И. М. Сәгъдиева, рус теле укытучысы Г. М. Сапарова

**Рецензент:**

**Фәйрүзә Әсгать кызы Мөслимова** – шагыйрә,Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Абдулла Алиш премиясе лауреаты

**Йолдыз Әдип кызы Шәрапова**, балалар шагыйрәсе, Абдулла Алиш премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

**А 50** **Алиш эзләреннән:** VIII бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе. – Казан, «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. – 284 б.
**ISBN**

Укучыларда татар халкының тарихына, әдәбиятына мәхәббәт, патриотик хисләр, милли үзаң тәрбияләү, А.Алишның тормышына, иҗатына кызыксыну уяту, сәләтле укучыларны барлау максатында Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиясендә «Алиш эзләреннән» исемле VIII төбәкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Конференциягә барлыгы 450 эш кабул ителде.

Укытучылар татар телен укыту, проблемалары һәм нәтиҗәләре буенча, хәзерге заман мәгълүмати технологияләр кулланып эшләү буенча тәҗрибә уртаклаштылар.

Конференциягә килгән эшләрнең яхшы дип табылганнары җыентыкка кертелде.

*Доклад материаллары автор редакциясендә басыла.*

УДК 37.01:821.512.145
ББК 74.202:83.3Тат

**ISBN**

© Казан шәһәре Совет районының «А. Алиш исемендәге 20 нче гимназия», 2021
© «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021

# ТАШКА БАСЫЛГАН, ДИМӘК – ДөРЕС!

Республикабыз һәм башка төбәк мәктәпләрендә укучы балалар арасында бу әдәби иҗат конкурсы инде берничә ел дәвам итә. Ул Казандагы 20 нче татар гимназиясе директоры Рәхимә ханым Арсланова идеясеннән башланып киткән иде. Шуннан бирле күпме укучы үзенең иҗат мөмкинлекләрен сынап карады, тормышка карашын, өметләрен-хыялларын шигырьләрендә, әкиятләрендә, хикәяләрендә чагылдырды. Дөрес, бүгенге заманда һәрбер мәктәпнең копмпьютер ярдәмендә үз газеталарын, журналларын чыгару мөмкинлеге бар. Ә инде киң күләмдә уздырылган конкурс нәтиҗәләре буенча нәшер ителгән җыентыкның дәрәҗәсе бөтенләй башка! Элек-электән халкыбызда китапка зур хөрмәт белән караганнар, китап сүзенә «ташка басылган» дигән дәрәҗә биргәннәр. Ташка басылган, димәк – дөрес!

Һәрбер баланың күңеленә туганда ук Аллаһы Тәгалә тарафыннан нинди дә булса сәләт салынган була, аны үз вакытында күрү, үстереп җибәрү, әлбәттә инде, әти-әниләре, остазлары кулында. Бу очракта да иҗатчы балаларның янәшәсендә укытучылары, нигездә татар теле һәм әдәбияты укытучылары тора. Шуңа күрә дә еш кына мәктәп программасында бирелгән темаларга, төрле календарь даталарына багышлап язарга яраталар балалар. Яңа елга, Кыш бабайга, Җиңү көненә...

Арча районы Ашытбаш мәктәбе укучысы Ландыш Хисамиева «Ана һәм мәңгелек солдат» шигырендә сугышта улын югалткан ананың ачы күз яшьләрен тетрәндергеч итеп тасвирлый. «Күзләрем дә, кулларым да тимер, Мәңгелеккә солдат инде мин...» – дип сүзсез генә җавап кайтара таш һәйкәл.

Шулай ук Арчадан, район үзәгенең 7 нче мәктәбе укучысы Зәлия Әхмәдуллина «Кыш бабайга хат» язып, «Акыл белән аңлыйм инде үзем Могҗизаның мөмкин түгелен», – дип белдерә дә, «Кайтар инде безнең этине!» – дип ялвара.

Булдыра инде кызлар! Һич уйламаганда, Казандагы 6 нчы гимназиянең 8 класс укучысы Мәдинә Фәхретдинова «Солдат буласым килә» дигән шигырь язып шаккатыра. «Минем дә этием кебек солдат буласым килә!» – дип яза.

Чыннан да, шигырьме, хикәяме, башка әдәби әсәрләр укыгандамы – без, үзебез дә сизмичә, яңалык эзлибез, моңа кадәр күрмәгәнне күрәсебез, беләсебез килә. Казандагы 20 нче гимназия укучысы Зилә Гыйльманова кыш көне, җимлекләр куеп, кошларны ашатуы турында яза да, «Нәни песнәкләрне кайчак өйгә кертәсем килә», – дигән теләген белдереп куя.

Бу шигырьне укыгач, кошларның да, җәнлекләрнең дә, барыбызныңда бердәй табигать баласы булуыбыз турында уйланасың. Тик кайбер кешеләрнең «кече туганнары»бызга карата рәхимсезлеге җанны телгәли. Ландыш Хисамиева (Арча, Ашытбаш) яз көне җылы яктан кайткан кыр казларына мылтыктан атучы явыз бәндәләрне тәнкыйтьли. Мылтык тавышыннан «Ыңгырашып куйды Җир-Анабыз. Ник соң кеше кансыз бу кадәр?» – дип ихлас күңеленнән борчыла ул.

Белгәнебезчә, бу ел Туган телләр елы дип игълан ителде. Татар телен саклау максатында премьер министр урынбасары Марат Әхмәтов җитәкчелегендә Татар телен саклау комиссиясе дә булдырылды хәтта. Ләкин ана телебезне үзебез яратмасак, үзебез сакламасак, безгә бернинди комиссияләр дә ярдәм итә алмас. Әйтик, без үз исем-фамилияләребезне ШайхУтдинова, ИнсафУтдин, ИлЬсур, ИлЬнур, ЮнУс, ИлЬназ, ИлЬгиз, ЗУлЬфия дип, Казанның Вахитов районын Вахит (кем ул Вахит?) дип язабыз икән, телебезнең тәме югалуга кем гаепле булачак? Ташка басылган сүзләр бит, әйдәгез, игътибарлырак булыйк әле, кадерле милләттәшләрем! Ни дисәң дә, бу җыентык тиз арада әзерләп чыгарыла, андагы хаталарны төзәтеп утыручы кешеләр дә, аның өчен мөмкинлекләр дә бик чикле. Телебезне яратыйк, хөрмәт итик. Иҗат дөньясыннан аерылмыйк! Аңлашып яшик. Аңлашып эшлик!

***Фәйрүзә Мөслимова,***
*шагыйрә, Татарстан Язучылар берлегенең*
*Абдулла Алиш премиясе лауреаты*

Бүген иртән күрдем кыр казларын
Көнчыгышка таба киттеләр.
Канат җилпи– җилпи, каңгылдашып,
Тигез сафка тедзелеп үттеләр

А. Алиш « Кыр казлары»

Күп кенә язучыларның күңеленә иҗат оеткысын әниләре сала. Абдулла Алишның да нәкъ шулай. Әнисе Газизә апа нечкә күңелле, шигъри җанлы кеше булган, бик матур моңлы итеп җырлаган. Улына язган күп кенә хатлары шигырь юллары белән язылган. Абдулла Алиш һәлак булгач, бер шигырендә:

Үзем үләм, димәгән,
Балам кала, димәгән,
Дошман сүзенә алданып,
Туган илен бирмәгән, – дигән юллар бар.

Абдулла Алишның тормыш юлы, иҗаты – балаларыбыз өчен батырлык үрнәге. Аның язган әкиятләре, шигырьләре бүгенге көндә дә яратып укыла. Элек тә нәниләр язучыны бик ятратканнар. Ул мәктәпкә килеп керүгә: « Әкият сөйли торган абый килгән!»– диеп, аны шундук сырып ала торган булганнар.

Менә шушы нечкә күңелле, тыйнак, хисчән кеше фашистлар алдында да тез чүкми, геройларча һәлак була. Шуңа да җәлилчеләрнең батырлыгы – үлемсез. 2015 нче елда гимназиябез каһарман-язучы Абдулла Алиш исеменә лаек булды. Бу безнең өчен горурлык кына түгел, зур җаваплылык һәм яңа үрләргә этәргеч тә. Укучыларыбыз Алиш исеменә кызыллык китерми, тырыш, уңган, белемле булырга сүз бирәләр, төрле чаралар үткәрәләр, бәйге-ярышларда катнашып, каһарман – язучының исемен мәңгеләштерүдә үз өлешләрен кертәләр. 2013 елдан гимназиябездә Бөтенроссия статусына ия булган «Алиш эзләреннән» фәнни– эзләнү конференциясе үтә. Быел, 2021 нче елда, бу чара Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге дип игълан ителгән елда zoom аша узса да, катнашучылар саны аз түгел, барлыгы 455 эш кабул ителде. Укучылар үзләренең эзләнү эшләрен, әкиятләрен, шигырьләрен тәкъдим итсә, мөгаллимнәр мәгариф, тел, тәрбия темасына кагылышлы мәкаләләре, эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

***Рәхимә Минвәлиевна Арсланова,***
*Казан шәһәренең Абдулла Алиш*
*исемендәге 20 нче гимназия директоры, К. Насыйри*
*премиясе иясе, Татарстан Республикасының Язучылар*
*берлеге әгъзасы, Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» Казан бүлеге җитәкчесе.*

## «ШИГъРИЯТ БАКЧАСЫНДА» ЮНӘЛЕШЕ

***Ахунзянова Алия***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*110 нчы лицееның 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гаязова Рәзилә Рафаэл кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

### *Әнием*

Бу дөньяда иң җылы сүз
Иң кадерле һәм якын сүз – әни сүзе.
Әни синең елмаюыңда
Һәр сүзеңдә кояш үзе.

«Әни» – дип сиңа дәшүләрем,
Синең биргән миңа киңәшләрең –
Барысы да бит минем өчен
Бу җирдә шатлык – бәхетләрем.

***Әхмәдуллина Зәлия***
*ТР Арча районы 7 нче УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Валиева Ләйсән Фоат кызы,*
*рус теле һәм әдәбияты укытучысы*

### *Кыш бабайга хат*

Яңа елга аяк атлаганда
Могҗизалар көтә күңелем.
Акыл белән аңлыйм инде үзем
Могҗизаның мөмкин түгелен.

Әгәр чынга аша торган булса,
Кыш бабайга язган теләкләр.
Тик бер генә нәрсә сорар идем –
Саклап йөртә аны йөрәкләр.

«Кыш бабакай, үтисеңме минем
Теләгемне, зинһар, әйт инде?
Тик бер генә нәрсә сорыйм синнән:
Кайтар инде безнең әтине.

Исән бит ул, читтә генә йөри,
Бикләп куйды аны Убырлы.
Кышкы бураннары адаштырды,
Бер көн аны күреп булырмы?

Адашканнар да бит таба юлны
Туган илгә, туган нигезгә.
Язмышлары буталганнар гына,
Юл табалмый менә ил гизә.

Кайтмасын да беләм, нишлим инде,
Һаман көтә минем күңелем.
Теләгемне үтә, Кыш бабакай,
Аңласам да мөмкин түгелен!!!

***Бариев Булат***
*ТР Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*30 нчы УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре:Бәриева Зилә Равил кызы,*
*Гарифуллина Энҗе Рафик кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Муса Җәлил-халык горурлыгы!*

Муса Җәлил– халык горурлыгы,
Батырлыгы аның мәңгелек.
Шагыйрь-герой үлгән аягүрә,
Таштан һәйкәл аңа истәлек!

Тез чүкмәгән безнең Муса абый,
Күргәчтен дә палач балтасын.
Олы җаны аның гүя сизгән,
Шигырьләрдә мәңге каласын!

Корал итеп алган уй-хисләрен,
Дан җырлаган газиз халкына.
Сындырырга дошман теләсә да,
Тугры калган биргән антына!

Җәлилчеләр үлгән елмаешып,
Богау чыңы җырга кушылган.
Бу түгелме мәңгелеккә адым?
Үлемсезлек юлы – шушыннан!

Шигырләрең кайтты, Муса абый,
Һәм Син һәрчак безнең күңелдә!
Халкы өчен гомрен биргән шагыйрь,
Янәшәмдә сыман бүген дә!

***Вәлиева Гузәл***
*ТР Арча районы Иске Чуриле*
*УГБМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Валиева Ләйсән Фоат кызы,*
*рус теле һәм әдәбият укытучысы*

## *Мин килдем яшәр өчен*

Нинди генә фаҗигаләр
Төшсә дә безнең башка,
Безгә яшәргә кирәк,
Тиңләшеп асылташка.

Гомер бер генә бирелә
Сакларга аны кирәк.
Якты көнгә шатланып,
Яшәргә кирәк, димәк.

Бу яп-якты җир йөзенә
Мин килдем яшәр өчен.
Хәтта үлемне җиңәргә
Җитәргә тиеш көчем.

***Валиуллина Диләрә***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*185 нче многопрофиль лицееның 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Киямова Динара Ринат кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Мин татарча сөйләшәм*

Мин татарча сөйләшәм,
Мин татарча аңлашам.
Татар телем – ана теле,
Әгәр шуны аңласаң.

Ярышларда җиңү бирде –
Мин татарча сөйләшәм.
Әнием гөлдәй елмая,
Үз телемдә сөйләсәм.

Мин сөенәм, дусларым,
Телне белеп үсәбез.
Мәкаль – телнең бизәге,
Энҗе итеп тезәбез.

Мин татарча аңлашам,
Мин татарча сөйләшәм.
Үткән юлыбыз данлы,
Әгәр белсәң, өйрәнсәң.

***Газизова Гөлинә***
*ТР Биектау районының Әлдермеш*
*УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Вәлиева Алсу Зөфәр кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Туган авылым*

Бик тә матур минем туган авылым,
Тирә-ягы яшел болыннар.
Җәйләр җиткәч, шушы болыннарда
Утлап йөри нәни колыннар.
Мин дә синең назлы кочагыңда
Иркәләнеп үсеп киләм бит,
Тирәңдәге салкын чишмәләрең
Мина яшәү көче бирә бит.
Күреп шушы гүзәллекләреңне
Шушы болын, шушы кырларны-
Тәндә җаны булган кайсы кеше
Мактанмыйча түзеп торармы.
Мәңге яшә гөрләп, туган авылым
Канат куеп безнең иңнәргә.
Имин, тыныч күкләр теләп калам,
Алда туар һәрбер көннәргә.

***Сиразиева Зәринә***
*ТР Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*43 нче УГББМ 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Багавиева Лилия Данис кызы*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Алтын көз килде*

Менә алтын көз җитте
Җиргә яфраклар сипте.
Без көзне күптән көттек
Без аны сагынып беттек.

Бар дөнья сары булган
Әйтерсең, алтын юрган.
Агачлар да сап-сары
Матур киемнәр кигән.
Бала-чага куана,
Көз килүгә шатлана.
Кулларына портфель алып
Алар мәктәпкә бара.

***Галимзянов Ильяс***
*ТР Казан шәһәре Мәскәү районының*
*9 нчы гимназиясенең*
*6 нчы Б сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Абитова Язиля Салим кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучыс*

## *Туган авылым*

Әллә кайдан күренеп тора
Минем туган авылым.
Сихерле дә, илаһи да
Тылсымлы туган ягым.
Бары синдә генә үсә
Үләннәрнең төрлесе.
Чәчкәләрнең хуш ислесе,
Зәңгәре, шәмәхәсе.
Болының да хәтфә кебек,
Кырларың алтын төсле.
Җәелгән җиләк кырлары
Ал, кызыл, яшел төсле.
Туган якта күреп була
Салават күперләрен.
Күңелемә бик тә якын
Чишмә, инеш, күлләрең.
Сайрар кошлы, сандугачлы
Гүзәл туган авылым.
Шушы матурлыкны саклап
Яшәр минем буыным.

***Гарипова Адилә***
*ТР Казан шәһәре ГАОУ Адымнар-Казан*
*полилингваль комплексы 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Габдрахманова Резеда Әнәс кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Ромашка*

Ак нәфис таҗларын балкытып
Ромашка кояшка үрелә.
Саф хисләр тудырган чәчкәгә
Кояш та бик якын күренә.

Ал, зәңгәр чәчкәләр янында
Әйтерсең, туй кызы, ромашка.
Таң белән керсәң син аланга
Сокланасыың гүзәл карашка.

Ак йомшак таҗларыннан сөеп
Шифалы хуш исен иснисең.
Табигать сылуы – чәчкәнең
Алдагы гомерен уйлыйсың.

Аңласаң чәчкәнең күңелен
Син аны рәхимсез өзмисең.
Аланның кояшы – чәчкәгә
Елмаймый һич тә син түзмисең.

***Галимуллина Гузәл***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районы*
*114 нче УГББМ 6 нчы А сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Шәрәфетдинова Ләйсән Вазых кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Кояш булса күгемдә*

Ак күмәчне көн дә ашыйм,
Бал белән, каймак белән.
«Әти-әни» диеп язам
Ак карга бармак белән.
Мәктәбемә көн дә барам,
Букчам тулы дәфтәрләр.
Уку беткәч, өйгә кайтам –
Анда мине көтәләр!
Бер дә тик тора белмим мин:
Биеп тә куям кайчак.
Шигырьләр дә чыгып куя,
Утырсам күбрәк качып.
Балачагым бик бәхетле,
Һәр көне нурга чумган.
Сугышлар бер дә булмасын,
Җирдә һәр кеше туган!
Җир шарының һәр илендә
Җырлап үссен балалар!
Халкын сөйсен, телен сөйсен –
Шат булсыннар аналар!
Үткән белән киләчәкне
Тоташтырам күңелемдә.
Хыялларым чынга ашыр
Кояш булса күгемдә!

***Гатина Ләйлә***
*ТР Кукмара районының Р. И. Зарипов исемендәге*
*Байлангар УГББМ 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гильфиева Алсу Рәиф кызы, педагог-китапханәчесе*

## *Сыерчык нигә моңсу?*

Килде ясаган ояма
Бер сыерчык. Бер генә.
Нигә ялгыз? Ник пары юк?
Аңлый алмыйм һич кенә.
Ерак юллардан кайтканда
Һәлак булганмы пары?
Әллә кошчык нәни парын
Өлгермәгәнме табып?
Ялгыз сыепчык нигәдер
Моңсулана, кайгыра.
Кайгысыннан ботаклар да
Ташымый оясына.
Ни булды соң? Нигә моңсу?
Ник җырламый кошкаем?
Мөгаен, ерак юлларда
Югалткандыр дускаен...

***Гафарова Камилә***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*«175 нче гимназия»нең 5 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Гафарова Гөлнара Галимхан кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Телефон турында*

Коридорларда арлы-бирле
Йөриләр укучылар.
Һәркайсының кулларында –
Кәрәзле телефоннар.

Кирәксә – кирәкмәсә дә,
Сөйләшеп  алгалыйлар.
Экран буйлап бармак йөртеп,
Музыкасын сайлыйлар.

Дәрәҗә дип беләләрме
Инде шул телефонны?
Сиксән яшьлек әбиләр дә
Куллана хәзер аны.

Шул телефон дигәннәре
Дәрестә дә шалтырый.
«Синнән колак кагам», – диеп,
Хуҗасы дер калтырый.

Телефонны кулланыйк без
Бары тик кирәк чакта.
Ә дәрестә бар игътибар
Булсын дәфтәр – китапка!

***Гафаров Руслан***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*«175 нче гимназия»нең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Гафарова Гөлнара Галимхан кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Көзге урман*

Илһамланып йөргән кеше өчен
Урман бирә илһам җимешен.
Хыялыма җавап табу өчен,
Кабат, урман, сиңа килешем.

Көзге урман. Сары яфраклардан
Җиргә алтын юрган ябылган.
Сихри табигатьне күзәтергә
Яратамын бала чагымнан.

Каеннарга барып серем сөйлим,
Җавап табам ничә сорауга.
Чыршыларга атап шигырь язам,
Уйланамын карап шуларга.

Миләшләргә карап юанамын
Күңелкәем тулган чакларда.
Шуның өчен җыям яфракларын
Көз бүләге итеп сакларга.

Карт имәннәр каршы алган иде,
Озатып калды биек наратлар.
Ярый әле барып юаныгра
Урманга бай безнең бу яклар.

***Гаязова Гүзәлия***
*ТР Теләче районы Югары Кибәхуҗа*
*УГББМ 7 сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Афзалова Гөлназ Җәүдәт кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Абдулла Алиш*

Бүген Абдулла Алишның
Карадым тормыш юлын,
Беразга сүзсез калып,
Басып калдым шаккатып.

Күпме авырлыклар үткән,
Бирешмәгән, сынмаган.
Ләкин сугыш яуларында
Дошман аны яулаган...

Татарстан шагыйрьләре
11 булганнар алар,
Шушы сугыштан кайтмыйча,
Тарихка эз салганнар.
Туган як өчен көрәш,

Бер көн генә бармаган.
Ләкин җиңү килсен өчен,
Алар бик күп көч куйган.

Курыкмаган авырлыктан,
Бик күп хезмәт күрсәткән.
Илем тыныч яшәсен дип,
Төн йокысын күрмәгән...

Рәхмәт сиңа, Алиш абый,
Бирешмәгәнең өчен.
Ничек авыр булса да,
Артка китмәвең өчен!

Сине мәңге онытмабыз,
Син бит безнең күңелдә!
Алиш кебек булам диеп,
Яшим эле бүген дә!

***Гизатуллина Динә***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районының*
*78 нче «Фарватер»лицееның 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Нәбиева Гөлчәчәк Мөнәвир кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Кыш килде*

Кар-бураннары белән,
Сагынып көткән кыш килде.
Башланды салкын көннәр,
Туңдырды бөтен җирне.
Ап-ак карга төренделәр
Бөтен кырлар, урманнар.
Су өстенә гүя боздан
Келәм җәеп куйганнар.
Чыршы, нарат агачлары
Бик купшыдан киенгән.
Аларның ылысларында

Әйтерсең лә энҗеләр.
Аяк астында шыгырдый
Салкын көндә ап-ак кар.
Тәрәзләргә бизәк ясый,
Табигать гүя рәссам.

***Гиззатуллина Альмира***
*ТР Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*23 нче лицееның 7 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Абрамова Людмила Василий кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Дуслык*

Балачакның бәхетлесе
Минеке бит, бик беләм.
Чөнки әби-бабайларым,
Әти-әни, туганнарым-
Барчасы минем белән.
Урам тулы дус-ишләрем,
Мәктәбемдә – остазлар.
Агачтагы сайрар кошлар
Бар да дуслар-туганнар.
Дошман белән дөнья бармый,
Дуслык кирәк дөньяда.
Аңласын иде кешеләр,
Рәхәт Дуслык булганда.

***Гиниятуллина Исламия***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең*
*3 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе:Сагдиева Илсөяр Миргазиз кызы,*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

## *Алиш абый*

Абдулла Алиш исеме,
Яхшы таныш һәркемгә!
Күпме тәрбия бирә ул,
Әсәрләрендә безгә.

Нәни чагында ул зирәк,
Тәртипле бала булган.
Һәрвакыт дусларына,
Ярдәмгә дип ашыккан

Кызыклы, тирән мәгънәле,
Әкиятләр язган ул.
Үсәчәк буын өчен дип,
Зур мирас калдырган ул.

«Куян кызы»әкияте,
Барыбызга да үрнәк.
Әти-әни сүзләренә
Колак салырга кирәк!

Ә «Сертотмас үрдәк» безне,
Сер чишмәскә өйрәтә.
Якын дусларына һәрвакыт,
Кирәк саклый белергә.

***Гыйлманова Зилә***
*ТР Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге*
*20 нче гимназиянең 7 сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре:Фәхретдинова Гөлшат Мөхәммәт кызы,*
*Зарипова Миләушә Гаделҗан кызы, татар теле,*
*әдәбият укытучылары*

## *Кошларым*

Җәй җитүгә җимнәр куям
Кошларыма ашарга.
Барысы да китеп бетми
Кала бездә кышларга.
Салкын көннәр башлануга,
Киләләр очып җимгә.
Сары песнәкләрне кайчан
Кертәсем килә өйгә.
Тик аларга урам кирәк.
Өйдә яши алмыйлар.
Яратуымны кошларым
Җимнәр аша аңлыйлар.

***Җиһаншина Ризәлә***
*ТР Биектау районының Әлдермеш*
*УГББМ 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Сәгыева Ризидә Әмир кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Печән өсте*

Учка кысып чалгы сабын
Бер егет печән чаба.
Бер адым алга бара да,
Чалгысын янап ала.
Пакуслар офыкка кадәр!
Болында печән исе...
Чалгылар чаж да чож килә,

Авылда печән өсте.
Июль. Җәйге иртә.
Болында бүген бәйрәм!
Печән чаба яшь егетләр,
Кайда, бирегез әйрән!
Чалгы чыңы, тургай җыры...
Нинди күңелле, кара!
Учка кысып чалгы сабын
Егетләр печән чаба.

***Җәләева Әминә***
*ТР Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге*
*20 нче гимназиянең 7 сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Фәхретдинова Гөлшат Мөхәммәт кызы,*
*Зарипова Миләүшә Гаделҗан кызы, татар теле,*
*әдәбият укытучылары*

## *Китаплар да авырый*

Кешеләр дә авырыйлар,
Авырый икән китап та
Тышы купкан, бите ертык,
Дәва кирәк китапка.
Матур итеп тышлап куйдым,
Ябыштырдым битләрен.
Укыганда сак тотыгыз,
Бөкләмәгез читләрен!

***Закиров Руслан***
*ТР Казан шәһәре Авиатөзелеш районы*
*«145 нче лицей»ның 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Шайхутдинова Рәсимә Сәгит кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Тукай бәйрәме*

Яз да җитте. Тагын апрель безгә,
Алып килде Тукай бәйрәмен.
Шигырьләре яңгырый һәр тарафта,
Күңелләрдә «шигырь бәйләме».

Ятимлектә үткән  бала-чагын,
Уйлап минем күңелем сызлана.
Бөек шагыйрь – халкым горурлыгы,
Авырлыкта һич тә сынмаган.

Төшләремдә күрәм «Шүрәлесен»
«Су анасы «очрый күлләрдә.
Тукай шигырендә сурәтләнгән,
Күбәләкләр куна гөлләргә.

Тукай эзе буйлап сәяхәткә,
Чыгам әле җәйләр җиткәч тә,
Тыңлар өчен кошлар сайраганын
Кырлай янындагы тирәктә.

Тукай кебек бөек шагыйрьләрне,
Халкым минем һәрчак олылар.
Шигырьләрен яттан өйрәнербез,
Әкиятләрен укыр оныклар.

***Зиннурова Камилә***
*ТР Казан шәһәре Киров районының*
*137 нче УГББМ 6 нчы Б сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Муллахмәтова Рәмзия Кәрим кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Бүген сезнең көнегез!*

Ал чәчәкләр белән
Ветераннар чыккан урамга.
Чын йөрәктән, баш иябез,
Тыныч көннәр өчен, аларга.
Бәхетле безнең балачак,
Кояшлы – аяз күгебез.
Рәхмәт сезгә, ветераннар,
Бүген сезнең көнегез.

***Кадырова Энҗе***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*187 нче многопрофиль лицееның*
*6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Нугманова Диләрә Рәшит кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Кыш*

Урамда салкын,
Ап-ак кар ява.
Кар бөртекләре
Битемә куна.

Яратам кышны
Салкын булса да.
Бит алмалары
Бик-бик туңса да.

***Калимуллин Динар***
*ТР Казан шәһәре Вахит районының*
*98 нче ГББМУ 5 нчы А сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Иггисамова Ландыш Ильгизәр кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Бәхет*

«Бәхет нәрсә ул?»дип сорасагыз
Күзләремә минем карагыз!
Иң зур бәхет – тату гаиләң булу,
Әткәң-әнкәң булу, аңлагыз!

Сул канатым минем – әти булса,
Уңы аның – газиз әнкәем.
Ярдәм кулын сузар абыем бар,
Һәрчак аңлый бит ул хәлкәем.

Кайтып керсәм – җылы өем көтә,
Табыныбыз тулы сый, нигъмәт.
Якыннарым һәрчак янәшәмдә
Шушы икән лә ул – чын җәннәт!

***Кашапова Динә***
*ТР Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*«13 нче гимназия»нең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Шагараева Алинә Ильсур кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Сагыну*

Белмим, әллә нидән бүген,
Болыт каплый күңел күгемне.
Яңгыр тамчылары түгел, күз яшьләре
Чылаталар битне, күземне.

Нигә моңсу, нигә авыр миңа?
Йолдызларым, җавап бирегез.
Төн тып-тыныч, ай, йолдызлар балкый,
Нидән миңа болай күңелсез?

Назлы дустым, җилем, әйтче, нигә
Елмаясым килми һич кенә?
Бөтен җиһан, бар зур дөнья, нидән
Минем өчен бүген кечкенә?

Ай-сердәшем, бәлки син әйтерсең,
Кайдан килгән мондый ашкыну?
Ай дәшмәде, тик төн пышылдады:
«Күңелеңдә синең сагыну»...

***Кашапова Нурия***
*ТР Питрәч районының Сафин Ф. Ә. исемендәге Шәле урта*
*УГББМ сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Җәмәлиева Тәнзилә Сәлим кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Туган телем*

Туган телем – татар телем,
Минем өчен бик якын.
Аны хөрмәтләсәң генә
Анлыйсың ватан хакын.
Туган телем – Тукай телем,
Әти-әнидән к калган.
Алар телгә мәхәббәтне
Күңел түремә салган.
Туган телем-анам телен,
Өйрәнәмен бик теләп.
Горурлыгы милләтемнең
Булырга теләү, исәп.

***Касимов Инсаф***
*ТР Казан шәһәре Вахит районының 98 нче*
*УГББМ 6 нчы Б сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Касимова Гөлнур Наил кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Мин – татарның улы*

Мин – татарның ялкынлы бер улы,
Тукай белән Җәлил дәвамчысы.
Бар бер максат минем күңелемдә:
Горур басып алга барасы.

Татар йолаларын үтәп яшим,
Әби-бабам олы хөрмәтле.
Гореф-гадәт, иман саклангандa,
Киләчәгем минем өметле!

Милләт диеп, туган телем диеп,
Ялкынланып яшим туган җирдә.
Курыкмыйча татар булуыма,
Горурланып яшим үз илемдә.

***Марданова Гузәл***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районы*
*«78 нче лицей»ның 8 нче Г сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Инсафутдинова Миләүшә Тәлгать кызы,*
*Вәкилова Зилә Юнус кызы туган тел*
*һәм әдәбият укытучылары*

## *Телле халык булыйк!*

Телсез халык – моңсыз халык, диләр.
Кеше китсә, җыры калачак.
Ләкин бетсә милләт, туган телләр,
Ул җырларны кемнәр җырлаячак?

Телсез халык – илсез халык, диләр.
Җир шарында калмый эзе дә.
Илең бетсә, ансыз калыр ниләр? –
Кешеләре яшәр ятимдә.

Телсез халык – нурсыз халык диләр.
Ямең, нурың бетсә, нишләрсең? –
Яшәү көчең, дәртең, көнең бетәр,
Бүтән илгә башлар иярсең.

Яшә, халкым, бердәм, көчле булып!
Туган телең бакый яшәсен!
Халык, җырын милли моңга салып,
Туган телләрендә сөйләшсен!

***Мөхәммәдшина Ләйлә***
*ТР Казан шәһәре Авиатөзелеш районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә*
*торган 62 нче УГБМ» ГББМУ 6 нчы Г сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Муктат Флера Исламетдин кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Халкым минем*

Татар халкы моңлы халык –
Җырларыннан моң ага.
Җыр-биюне яратучы
Татардан үрнәк ала.

Татар халкы тырыш халык,
Һәр эштә дә алдынгы.
Тырыш булганга тапкан ул
Хәтта кара алтынны.

Татар халкы тату халык –
Тынычлыкны ярата.
Азан тавышлары аша
Иман нуры тарата.

Татар халкы батыр халык –
Күп лачыннар үстергән.
Батырларның исемнәрен
Йөрәкләргә күчергән.

Яшәсен халкым һәм телем,
Бу безнең иң зур теләк.
Шундый халкың булу белән
Горурланырга кирәк!

***Мөхетдинова Камилә***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районы*
*«78 нче лицей «Фарватер» 8нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Кәримова Гөлназ Фәрит кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Авылны бик яратам*

Шәһәр кызы булсам да мин,
Авылны бик яратам.
Җәйләр җитүгә сагынып,
Авылга очып кайтам.
Анда яши әби-бабам,
Дусларым бик күп монда.
Әти-әнием дә минем
Шушы авылда туган.
Бик яратам авылымның
Саф сулы чишмәләрен.
Җилләрнең дә иң назлысын,
Авылда искәннәрен.
Бигрәк матур су буйлары,
Урманнары, таулары.
Җәй көнендә бигрәк ямьле
Иген тулы кырлары.
Авылымның матурлыгын
Алыштырмыйм бернигә.
Җәй җитүен шуңа көтәм,
Түземсезләнеп менә!

***Мифтахова Адилә***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*175нче УГББМ 7 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре:Галиуллина Диләрә Әхмәдулла кызы,*
*Габделвәлиева Рәмзия Наил кызы*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## *Хыялларым*

Күңелемдә булган хыялларны,
Башны һаман салам уйларга
Һөнәрләр дә бик күп бу тормышта
Белмим инде, кайсын сайларга.
Хыялымда укытучы булам
Әле табиб, әле төзүче.
Әни әйтә, бар, ди тегүчегә
Әти әйтә, бул, син пешекче.
Дәресләрдә карап сокланамын
Укытучы белем биргәннен
Такта яннарына басып сөйләп
Әкрен генә атлап йөргәнен.
Хыялларым белән яшим көн дә,
Ак халатлар киям төшемдә.
Дәвалыймын кебек сабыйларны
Эшлим кебек туган җиремдә.
Һөнәрләрнең кайсын сайласам да,
Минем бары бер теләк:
Максатыма ирешер өчен
Тырышып укырга кирәк.

***Набиуллина Гөлназ***
*ТР Арча районы Сиза УГББМ*
*6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Залялеева Гелусә Ильсун кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## *Җиңү кайтавазы*

Дәһшәтле сугыш еллары...
Онтылмый яралары.
Әти-әнисез калдырды
Ул бик күп балаларны.
Күпме шәһәр, авылларны
Явыз фашист юк итте.
Үч алып совет солдаты
Берлинга барып җитте.
Бик күп кеше башын салды
Бөек Җиңү хакына.
Күпме җәфалар чигәргә
Туры килде халкыма.
Ләкин халкым тыныч булды,
Сынмады, сыгылмады.
Шуңа да ул күпме еллар,
Җиңү җырын җырлады.

Ләкин җиңүне күпләргә
Күрү насыйп булмады.
Тол хатыннар, бала, ана
Күз-яшь түгеп елады.
75 ел тыныч кына,
Еллар үтеп баралар.
Һаман ирен, улын көтә
Ялгыз калган аналар.
Бабайларның батырлыгы-
Безгә иң күркәм үрнәк.
Бүтән сугышлар булмасын-
Бу безнең иң зур теләк.

***Нуреев Данис***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*«169 нчы УГБМ» ГББМУ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Насырова Рима Мухаматфарис*
*кызы, Нуреева Чулпан Загир кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Кирәкми безгә сугыш!*

Булмасын җирдә сугышлар,
Дөньялар тыныч булсын!
Сабыйлар бишекләрендә
Татлы йокыга талсын!
Сугыш җилләре беркайчан
Тәрәзләрне какмасын!
Газиз туган җиребезгә
Дошман аяк басмасын!
Ирексездән балаларның
Күз яше түгелмәсен,
Вакыты җитми беркемнең дә
Гомере өзелмәсен!
Кабатлый көн дә иреннәр:
«Кирәкми безгә сугыш!
Яшәү рәхәт, яшәү татлы,
Бәхетле булсын тормыш!»
«Сугыш»дигән ачы сүзне
Ишетергә язмасын!
Булмасын җирдә кан кою,
Дөньялар имин булсын!

***Нотфуллина Фирүзә***
*ТР Казан шәһәре Совет районы 169 нчы*
*УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләр: Нотфуллина Г. И., Кәримова Ф. Ю.,*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Туган ягым*

Туган ягым – Татарстан,
Башкаласы – нурлы Казан.
Кая барсам, кая китсәм,
Ераклардан сагынып кайтам.
Синдә генә яшел болын,
Салкын сулы чишмәләр.
Кып-кызыл җиләкле алан,
Алан тулы гөмбәләр.
Монда тудым, монда үстем,
Монда мин белем алам.
Шушы бәхеткә сөенеп,
Яшим мин – синең балаң.

***Низамова Азалия***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районы*
*«78 нче лицей»ның 8 нче Г сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Инсафутдинова Миләушә Тәлгать кызы,*
*Вәкилова Зилә Юнус кызы туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Кәрәзле телефон*

Минем бүген Туган көнем,
Шатлана күңелләрем.
Бәйрәм белән котлар өчен,
Җыелды дус-ишләрем.
Котлау килә, бүләк ява
Мул өстәлдә сый-хөрмәт.
Ә күңелгә нидер җитми,
Риза түгел, ни хикмәт.

Әтием эштә шул әле.
Кайтып җитмәгән икән.
Кәрәзле телефонын да
Бүләк итмәгән икән.
Зур итеп ишек ачылды,
Кайтып керде әтием.
Кәрәзле телефонымны
Сузды миңа әнием.
Рәхмәт, сезгә, якыннарым.
Мине сөендердегез.
Туган көнем белән котлап,
Бик зур бүләк бирдегез!

***Сабиров Әмир***
*ТР Казан шәһәре Мәскәү районы Г. Ибраһимов исемендәге*
*17 нче татар гимназиясенең 6 нчы А сыйныфы укучысы*
*Җитәкче:Абдуллина Рамилә Агзам кызы*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Алиш ничек шагыйрь булган?*

Җавап эзлим бер сорауга:
Алиш ничек шагыйрь булган?
Туган якның җыр-моңнары
Күңеленә нурын сызган?

Аяз төннең йолдызларын
Күзәткәндер авылында.
Киек казлар җырларыннан
Моң алгандыр язарына.

Шигырьләрен тоткынлыкта
Ничек шулай яза алган?
Эзләдем дә таптым җавап:
Туган илне сагынганга,
Балаларны яратканга,
Алиш шулай шигырь язган.

***Сабирова Алисә***
*ТР Арча районы «Утар-Аты төп ГББМ*
*7 сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Сабирова Ильмира Морат кызы*
*туган (татар) тел укытучысы*

## *Алиш турында шигырь*

Ямьле Көек буйларында
Туган нәни Абдулла.
Бик кечкенә чакларыннан
Яраткан ул укырга.

Өйрәткән аны әтисе
Танырга хәрефләрне
Яратып тыңлаган малай
Шигырь һәм бәетләрне.

Төрле хезмәт башкарса да,
Каләм алган кулына.
Матур сүзләр тезмәләрен
Салган шигырь юлына

Сугыш башлангач язучы
Яу кырларына киткән.
«Туган җирем, саклармын!» – дип
Ил алдында ант иткән.

Яшьлек гомерен кызганмаган,
Илен сатмаган солдат.
Авылыкларга түзгән ул
Күрсә дә бик куп газап.

Шпандау, Вустрау төрмәләре
Тоткыннар белән тулган.
Яшерен  оешма  эшләре
Бер көн килеп фаш булган.

Соңгы сулышына кадәр
Тугры булган халкына.
Куркып калмаган егетләр
Палач балтасыннан да.

Алиш, Җәлил батырлыгын
Без көйләргә салабыз.
Туган җирнең лачыннарын
Зурлап искә алабыз!

***Сагдиева Язилә***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең*
*8 нче А сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе:Сагдиева Илсөяр Миргазиз кызы,*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

## *Әниемә*

Безнең өчен бу дөньяда
Җан ата бит Әниләр!
Ничә яшь булса да безгә
Аларга без нәниләр...
Бишек җырларын көйлиләр
Иң тәүге көннән алар
Янда булмасак уйлыйлар:
«Нишли икән балалар?»
Һәйкәл куер идем һәрбер
Әнигә мин бу җирдә
Гомер буе бирә безгә
Алар киңәш тәрбия!
Китап язырга була ул
Һәрбер Әни турында.
Хөрмәткә лаек Әниләр
Тормыш алар кулында.

***Сафина Азалия***
*ТР Казан шәһәре Мәскәү районы Г. Ибраһимов исемендәге*
*17 нче татар гимназиясенең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Абдуллина Рамилә Агзам кызы*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

# *Яратам туган җиремне*

Яратам туган җиремне,
Анның киң басуларын.
Офыкларга сузылган
Арыш-бодай кырларын.

Яратам риваятьләрнең
Бабалар турындагы.
Болгар, Зөя, Биләр кебек
Тарихи урыннарын.

Монда безнең бабайлар
Ирек өчен баш салган.
Халкымның үткән тарихы
Таш диварларда калган.

Бүген илем зур үсештә,
Алга таба бара ул.
Үткән белән киләчәккә
Ныклы күпер сала ул.

***Сәмигуллина Азалия***
*ТР Казан шәһәре*
*«Г. Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясе»,*
*8 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Фәсләхова Азалия Рависовна,*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*

## *Туган ил*

Туган илне яратырга
Өйрәтте әти-әни,
Туган җирдән кадерлерәк
Юк җирдә миңа берни.
Туган илне саклап кадерләргә
Тиештер җирдә һәркем,
Аяз булсын туган илнең күге,
Дан җырлыйк аңа һәр көн.

***Тухватов Ислам***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*169 нчы УГББМ 7 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Корбанова Люция Әнвәр кызы,*
*Саликиева Валентина Михаил кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Мин солдат, имеш*

Күзем йомып, хыялланып
Уйга чумып, басып торам.
Имеш, мин солдат булганмын
Билемә чын каеш буган.

Әти-әни, туган илне
Саклап, яклап сакта торам.
Чын егет ул куркып калмас
Чыкса давыл, көчле буран.

Бу тик хыял, бүген әле
Мин тик мәктәп укучысы.
Сеңлем белән энемнең мин
Яклаучысы, саклаучысы.

***Фазылов Ранил***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*169 нчы УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Фассахова Разидә Исламутдин кызы,*
*Вафина Эльмира Махмут кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## *Казаным*

И Казаным, Казаным,
Син минем туган ягым.
Нурлы да син, якты да син,
Туган җирем, бала-чагым.

Ерактан үзенә чакыра,
Үзәктәге нурлы театрың.
Айлы манаралы мәчетеңдә,
Яңгырый изге азаның.

Барлык җирләрдән дә,
Син яктырак, моңлырак.
Зур үскәч тә синдә калам,
Туган ягым якынрак.

***Фахрутдинова Мәдинә***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районының*
*«6 нчы гимназия»нең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Фахрутдинова Гөлназ Фаил кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Кышкы матурлык*

Нинди сихри матурлык –
Кар ява тышта.
Бу мизгелне күзәтәм
Ел саен кышта.
Күңелемә якын минем
Салкын көннәре.
Беркайчан да онытылмас
Айлы кичләре.
Аеруча ошый миңа
Агач бәсләре.
Алмаз кебек ялтырыйлар
Бозның өсләре.

***Халикова Исламия***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районының*
*16 нчы гимназиянең 8 нче Б сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гинәтуллина Айгөл Рашид кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Рәхмәт*

Бер рәхмәт коткара бәладән,
Бер рәхмәт йөрәкне җылыта.
Ихластан әйтелгән теләкләр
Барасы юлымны яктырта.

Елмаеп биргәндә сәламем,
Дустыма, танышка, чит-ятка.
Ярдәмгә ашыгам кирәксә,
Файдалы булыйм дип тормышта.

Көнемнең уңышы игелек,
Юктан да уңганда эшләрем.
Яхшылык бәладән коткара, –
Кабатлыйм әнием сүзләрен.

***Ханова Илсинә***
*ТР Казан шәһәре Мәскәү районының*
*64 нче УГББМ 6 нчы А сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Сабитова Гөлия Султан кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Җиңү бәйрәме*

Җиңү көне, олы шатлыгыбыз,
Безнең йөрәкләрдә чагыла.
Казан күген бизи ал байраклар,
Тантаналы бәйрәм чагында.

Ветераннар килә әкрен атлап,
Тере чәчәк тотып бу көнне,
Күкрәкләре орден-медаль тулы,
Карашлары көләч, сөйкемле.

***Хисамиева Ландыш***
*ТР Арча районы Г. Тукай исемендәге*
*Ашытбаш УГБМ 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хисамиева Рәсилә Рәүф кызы,*
*рус теле һәм әдәбият укытучысы*

## *Ана һәм мәңгелек солдат*

Һәйкәл яны, һәр яз саен ана
Чәчәк сала солдат каршына.
– Җиңәрмен дә, кайтырмын мин, – диден
Кайтмадың бит, балам, яныма.

Җыерчыклы куллар назлый сынны
– Салкын түгелме соң, бәбкәем?
Танидыңмы мине, әби булдым
Агарды бит көтеп чәчкәем.

Җиңү таңы атты, балакаем,
Бик тә матур гомер итәбез.
Һәр яз саен җырчы кошлар кайта,
Сез дә кайтыр диеп көтәбез.

Йомшак кына язгы җил шулвакыт
Сыйпап узды ана йөзеннән.
Әйтерсең лә ярь-яшь солдат улы
Аваз салды йөрәк түреннән.

– Мөмкин булса әгәр, әнкәй сине
Кочагыма алыр идем мин,
Ләкин күзләрем дә, кулларым да тимер
Мәңгелеккә солдат инде мин.

Меңнәр генә түгел, миллионнар
Бу көрәштә салды башларын.
Ишетелмәсен сугыш тавышы дип,
Түкмәсеннәр диеп яшьләрен.

Басмасын дип дошман аяклары
Гөлбакчадай туган җиремә,
Сузылмасын диеп чит-ят куллар
Туып-үскән газиз илемә.

– Рәхмәт, балам, – диде ана, яшен сөртеп,
– Урыныгыз булсын җәннәттә,
Килер буын сезнең батырлыкны
Кабатлар ул, иле эндәшсә!

***Хидиятуллина Камилә***
*ТР Арча районы Иске Чуриле УГБМ*
*6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хидиятуллина Зульфия Марсил кызы,*
*рус теле һәм әдәбияты укытучысы*

## *Авылым чишмәләре*

Җәй җиткәнне көтеп алам,
Зур туземсезлек белән.
Җәйләр белән, авылымның,
Бар матурлыгын күрәм!!!

Челтерәп аккан чишмәсеннән,
Яратам су эчергә.
Салкын чишмә суын эчкәч,
Кергән кебек көчләр дә.

Учларыма аламын да,
Карап торам сокланып.
Тиз агып бетә учымнан,
Шаянланып, шукланып.

Кояш нурында уйнаклап,
Чәчерәшә тамчылары.
Җәй көне бигрәк тәмле бит,
Татлы, чишмә сулары.

Кайда бар шундый гүзәллек,
Ургылып акан чишмәләр?
Юллар ачып, уйнаклашып,
Еракларга китәләр.

***Хәмидуллин Адель***
*ТР Апас районы Борнаш авылының*
*УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Хәмидуллина Гөлнара Наил кызы,*
*озайтылган көн тәрбиячесе*

## *Балыклы кич*

Әти урамнан керде дә,
Киенегез, киттек ди.
Мондый матур, җылы кичне,
Без күптәннән көттек ди.
Төялешеп машинага,
Чыгып киттек юл буйлап.
Әти безне алып барган,
Балык тотарга уйлап.
Кармакларны җайлап кына,
Суга салдык һәммәбез.
Тын да алмый, тавышланмый,
Балыкларны көтәбез.
Күз дә алмый күзәтәбез,
Кемгә беренче каба.
Гаиләм белән бергә-бергә,
Балык тоттык бер таба.

***Хәйруллин Рөстәм***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче*
*15 нче УГББМ 7 нче Б сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Леронова Фидания Нургаян кызы,*
*туган (татар) тел укытучысы.*

## *Әнигә бүләк*

Әти-әни эштә чакта,
Сеңелем белән бергә
Тотындык җыештырырга –
Туктатып булыр, димә!

Бөтен киштә һәм өстәлләр
Торалар инде көлеп,
Пыяла шкафлардан да
Нурлар сибелә кебек.

Бер бөртек тузан калмады,
Ялтырады идән дә.
Чүт егылыплар китмәде
Әни өйгә кергәндә!

***Һадиуллина Дилә***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*43 нче УГББМ сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Җиңү паркында*

Бала-чага чаба, яшьләр йөри,
Әнә читтә бер карт күренә.
Горур торган танкларга карап,
Сугыш чорын уйлап моңлана.

Сугыш кырын күз алдында тотып,
Авыр гына куя көрсенеп.
Кырда ятып калган иптәшләрен
Искә ала, күзе яшьләнеп.

Имин булсын еллар, балалар да
Ачы күз яшьләрен күрмәсен.
Безнең ветераннар бүгеннән соң
Дары исен бүтән сизмәсен.

***Шәрифуллина Сабина***
*ТР Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге*
*20 нче гимназиянең 7 сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре:Фәхретдинова Гөлшат Мөхәммәт кызы,*
*Зарипова Миләушә Гаделҗан кызы, татар теле, әдәбият укытучылары*

## *Дәү әнием*

Авылга бик еш кайтабыз
Дәү әнием янына
Атна буе көтеп йөрим,
Җитсен диеп ял гына.
Без кайтышка дәү әнием
Тәмле ашлар пешерә.
Шифалы догасы белән
Безне һәрчак өшкерә.
Безне сагынып көтә ул
Тәрәзәдә күзләре,
Үзе уңган, үзе булган
Тимәсен дим күз генә.
Озын булсын гомерләре
Ул безгә иңзур терәк.
Дәү әниләрнең кадерен
Белеп яшәргә кирәк.

***Шайхиева Агилә***
*ТР Казан шәһәре Вахит районы*
*1 нче УГББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Галиева Алсу Эрки кызы*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## *Мамык кар*

Иртән чыксам мин шаккаттым.
Дөнья яктырып калган,
Ап-ак мамык кар яуган да
Бөтен җирне каплаган.

Кечкенә кыз өй яныныда
Урамга карап тора.
Абый монда килмә ди,
Мамык таптап йөрмә ди.

Нәни көрәк кулында.
Мамык карны җыям да,
Таучык ясап куям ди,
Шунда чана шуам ди.

Мин дә аңа булыштым
Бер тау ясап куештым.
Һәр көн кичен чыгабыз,
Шунда чана шуабыз.

***Ямаева Альбина***
*ТР Казан шәһәре Совет районының*
*169 нчы УГББМ 7 нче В сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Зайнагутдинова Флюза Фарид кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## *Көчек*

Безнең мәктәп янында
Үсә бик күп көчекләр.
Карасы бар, агы бар
Йомшак, мамык кебекләр.

Килә алар йөгерешеп,
Без килгәнне күрсәләр.
Шатланабыз, сөенәбез
Безгә карап, өрсәләр.

Ундүрт көчек, беләсезме?
Ләң-ләң килеп, өрәләр.
Ашарларына бирәсен,
Әллә каян беләләр.

Кесәбездән ипи алып,
Ыргытабыз еракка.
Чабып барып талашалар,
Кызык, безгә шул чакта.

Барсының да исеме бар
Исем белән дәшәбез.
Тиз үссеннәр әле диеп
Конфет та өләшәбез.

Киңәшләштек әле дуслар,
Алып кайтып бәйләргә.
Тәмле ашлар да бирергә
Кайткач, безнең өйләргә.

## «ЭКИЯТЛӘРДӘН ОЛЫ ТОРМЫШКА» УКУЧЫЛАРНЫҢ ҮЗЛӘРЕ ЯЗГАН ӘКИЯТЛӘРЕ

**_Адиятуллина Адилә,_**
_ТР Казан шәһәре Яңа Савин районы_
_91 нче мәктәпнең 5 нче сыйныф укучысы_
_Җитәкче: Нәҗипова Зөлфия Наил кызы_

### _Миләүшәләр эзләүче Миләүшә_

_Борын-борын заманда,_
_Урман-таулар артында,_
_Ерак түгел авылда_
_Яшәгән ди бер бала!_
_Әкият сөйлим – тыңла!_

Менә шул авылда яшәгән ди, булган ди Миләүшә исемле бик матур бер кыз. Аңа алты яшь булган. Һәр кич саен, йокларга ятканда, әбисе аңа кызыклы әкиятләр сөйли икән, чөнки Миләүшә аларны бик яратып тыңлаган.

Ә берсендә, әбисе кыр-яланнарда үсә торган чәчәкләр, аларның исемнәре турында тылсымлы әкият сөйләгәндә, Миләүшә уйга баткан:

«Карале, ул чәчәкләрнең исемнәре-е-е – нинди генә юк икән бит! Күбесе кызлар исеме белән аталган. Әллә инде кызларга шул матур чәчәкләрнең исемнәрен куштылар микән?!»

Әйе, кечкенә генә булса да, Миләүшә бик зиһенле, аңлы кыз булган, ул бик нык хыялланган, уйларга яраткан, күп нәрсәне белергә тырышкан.

Әбисе әкиятне сөйләп бетергәч тә, Миләүшә аннан үз исеме турында да сорарга булган:

– Әбекәем, ә Миләүшә исемле чәчәк бармы соң?

– Бар, әлбәттә, балам! Әйтергә дә онытканмын икән әле үзеңә! Бик матур чәчәк ул Миләүшә... Менә нәкъ синең кебек матур, кызым!

– Ә нинди соң ул Миләүшә чәчәге, әбием?

– Шундый гөл бар, кызым. Яфраклары түгәрәк, зур түгел. Ә чәчәкләре төрле-төрле була: алсу, зәңгәрсу, шәмәхә, куе кызыл да булырга мөмкин. Менә зур үскәч, син миңа шул гөлне табып алып кайтып бирерсең, кызым, ярыймы?! Ә хәзер йокларга вакыт, йом күзләреңне, Миләүшә! – дигән әбисе.

Кайда инде ул йоклау – күзләре йомылса да, күңеле ап-ачык Миләүшәнең, башында уйлар бөтерелә: әле кайчан үсеп җитә ул, кайчан зур була, ә миләүшә чәчәген хәзер үк күрәсе килә бит! Тик ничек?

Иртәнгә кадәр кыз Миләүшә чәчәген эзләп табарга дигән ныклы карарга килә: әбисе тавык-чебешләргә ашарга биргән арада, кечкенә генә сумкасын ала да, урманга таба юл тота. Җәйге матур аяз көн! Кошлар сайрый, Миләүшәнең дә аларга кушылып җырлап барасы килә. Тизрәк шул чәчәкне эзләп табып әбисенә алып кайтып бирергә, аны куандырырга тели! Тик шундый кечкенә кызга бер ялгызы урманга барырга ярамавын гына онытып җибәрә шул Миләүшә!

Урман бик ерак түгел, Миләүшә йөгерә-чаба тиз килеп җитә. Урман аланын эзләп таба да, башта андагы чәчәкләрнең күплегенә, матурлыгына хозурланып йөри: нинди генә төрләре, нинди генә төсләре юк бит, ә исләре-е-е! Аландагы чәчәкләргә хозурланып, агачлар арасыннан килеп чыккан аюны күрми дә кала кыз.

– Минем җиләклекне кем таптап йөри монда? – дип, Миләүшәне куркытып җибәрә аю.

– Миңа Миләүшә чәчәге кирәк иде! – дип, калтыранып кына җавап бирә кыз.

– Син кем соң? – дип сорый аннан аю.

– Миләүшә...

– Аңламадым, Миләүшә миләүшә чәчәге эзли... Ничек соң инде ул алай?

– Минем исемем Миләүшә, миңа чәчәк исеме кушканнар.

– Кызык! Ничек шулай килеп чыккан соң ул?! Алайса аю дигән чәчәк тә бар микән? Менә сиңа мә! – дип гаҗәпләнгән аю.

– Аю дускай, минем әбием чәчәкләр турында барысын да белә, мин аннан сорармын, ярыймы! – ди Миләүшә. – Син миңа Миләүшә чәчәген эзләп табарга булыш!

– Мин чәчәкләрне түгел, ә андагы балны күбрәк яратам шул! Ә син тизрәк кит минем җиләкле урыннан, үләннәрне таптап йөрмә, – дип, аю Миләүшәне куып җибәрә.

Үксеп елап, кыз урман эченә кереп китә. Ә анда чәчәкләр бик сирәк очрый.

– Ник елыйсың син, кызчык? – дигән сорауга кабат сискәнеп китә Миләүшә.

Шыпырт кына артыннан килгән төлкене сизмәгән дә икән бит. Кыз төлкегә үз хәлен аңлатып бирә.

– Син бик тиз еларга керешкәнсең икән. Әле бит ул чәчәкне эзли башлагансың гына. Борчылма, бергәләп табарбыз, әйдә, мин сиңа булышам! Тик башта мине тыңла!

Төлкенең хәйләкәрлеге турында да онытып җибәрә шул Миләүшә. Ул аңа үзләренең авыллары, авылдагы йортлары, тавыклары турында барысын да түкми-чәчми сөйләп бирә. Кичен әбисенең ишекләрне ничек бикләвен дә, ул ишекләрне ничек ачып булуын да әйтә... Ә төлкегә шул җитә кала, Миләүшәне урман уртасында алдап бастырып калдыра да, үзе авылга таба китә...

Миләүшә төлкене көтә-көтә арып бетә һәм, аптырап, алга таба юлга кузгала. Әмма ул урман эчендә адашкан булып чыга. Кабаттан еларга тотына. Өенә кайтасы килә, әбисен сагына... Агачлар арасына кояш нурлары да үтеп керми, барган саен урман караңгылана гына бара.

– Аууу, ярдәм итегез миңа! Мин адаштым, булышыгыз миңа урман ияләре! – дип кычкыра Миләүшә.

Аның тавышын тиен ишетеп ала да, тизрәк ярдәмгә ашыга. Ярый әле Миләүшәнең юлында менә шушы үзе кечкенә генә, тик олы йөрәкле тиен очрый. Ул Миләүшәне авыл юлына таба чыгарып куя. Кыз аңа рәхмәтләр әйтеп, кайтырга кузгала. Аның инде миләүшә чәчәген күрәсе килми, тизрәк өенә кайтырга хыяллана.

Миләүшә өенә кайтып керсә, әбисе дә оныгын югалтып елап утыра икән. Ул аны көне буе эзләп йөргән, тик таба алмаган. Миләүшәне ачуланып та, кочаклап яратып та ала әбисе. Олылар сүзен тыңламыйча шулай урманга чыгып китәргә ярамавын кабат-кабат искәртә. Миләүшә әбисенә барысын да аңлатып бирә, миләүшә чәчәген эзләп табып, аны сөендерергә теләвен сөйли. Кыз белән әби шулай аңлашалар да, утырып тәмләп чәйләр эчәләр һәм йокларга яталар. Миләүшәгә әбисе кабат тылсымлы әкиятләрен сөйли.

Тик иртән кош-кортларына җим сибергә чыкса, әбисе шакката, тел шартлата – бер тавык та, әтәч тә калмаган!

Яңа гына йокысыннан уянган Миләүшә ачык тәрәзә аша әбисенең:

– Төлке тоткан! Харап иткән кошкайларымны, – дигән тавышын ишетеп ала да, шунда ук барысын да аңлый. Төлкегә ишекләрне ничек, кайдан ачып буласын ул сөйләгән иде бит...

Бу эштә үзенең гаебе барлыгын яхшы белгән Миләүшә нишләргә дә белми, шыпырт кына кабат юрган астына кереп ята да, уйлана башлый: әбисенә дөресен әйтергәме-юкмы?

Ә сез ничек уйлыйсыз, дуслар, Миләүшә әбисенә дөресен сөйләп бирер микән?

***Бухарметова Амирә,***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районы 88 нче мәктәпнең*
*6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хидиятуллин Рифат Тәлгать улы*

## *Төлке һәм Керпе әкияте*

Борын – борын заманда
Зур каланың берсендә
Дәрәҗәсен белеп кенә
Яшәгән ди бер Төлке.

Туннарның да иң матурын,
Кыйммәтлесен кигән ул.
Көннәр буе эшләмичә
Гулять итеп йөргән ул.

Ә күршедә тыйнак кына
Бер Керпе гомер иткән.
Буш вакыты булу белән
Урманга бара икән.

Үзе кечкенә булса да
Зур кәрзин ала икән.
Кәрзиненә гөмбәләрне
Пөхтәләп сала икән.

Ике күрше озак еллар
Бик дус гомер итәләр.
Бер – берсенең шатлыгын,
Кайгысын бүлешәләр.

Бер көн шулай урамда
Алар кабат очраша.
Керпе күреп күршесенең
Хәл – әхвәлен сораша.

Төлке никтер горур гына
Хәлләрем әйбәт, – дигән.
Яңа дустым көтә, – диеп
Ашыгып киткән икән.

Төлке шулай ашыгып
Светофорны күрмәгән.
Әллә инде күрмәгән,
Әллә инде белмәгән.

Кызыл төскә чыкканда
Машинага бәрелгән.
Башым каты авырта дип
Елап утыра икән.

Машиналар кычкыртканга
Керпе борылып караган.
– Нәрсә булды, дустым, диеп
Төлке янына барган.

Керпе шунда, әкрен генә
Дустына киңәш биргән:
Горур булып, кыланып,
Көлкегә калма! – дигән.

***Гизатуллина Айсылу,***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең*
*4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Корбанова Лидия Николай кызы,*
*Зиннурова Наилә Зәйнетдин кызы*

# *Нәни дуслар*

Борын-борын заманда яшәгән ди бик матур һәм бик тату кәҗәләр гаиләсе. Бу гаиләдә өч кәҗә бәтие булган. Аларның берсе – Батыр, икенчесе – Шаян, ә өченчесе Зирәк исемле булган. Бәтиләр бик дус булганнар.

Җылы җәйнең ямьле бер көнендә болар өчәүләшеп болынга үлән ашарга чыкканнар. Болын бик матур булган икән. Төрле чәчәкләр исен исни-исни, аллы-гөлле күбәләкләрне куа-куа уйнап йөри торгач, бәтиләр урман кырыендагы бер сукмакка килеп чыкканнар икән. Уйнарга, төрле кызыклар уйлап табарга яраткан Шаян исемле бәти энеләрен урман эченә чакырган, аларның әле урманда булганнары булмаган икән, урман эчен бик күрәселәре килгән билгеле.

Чыннан да урман бик ямьле һәм серле булган. Бәтиләр туйганчы яшел, сусыл үлән ашаганнар. Куыш-куыш һәм качышлы уйнап алганнар. Рәхәтләнеп шаярышканнар.

Кошлар сайравын тыңлый-тыңлый барганда бәтиләр каршысына Бүре баласы очраган, бәтиләр аны да үзләре белән ияртkәннәр. Бүре баласы белән дә төрле уеннар уйнаганнар. Вакыт бик тиз үтеп киткән. Инде кич тә җиткән, караңгы төшә башлаган. Бүре баласы үзенең яңа дусларын өненә кунакка чакырган.

Шул чагында Зирәк исемле кәҗә бәтие яңа дуска болай дигән:

– Бик аз таныш булган дусларга ияреп китәргә ярамый! Син дускаем безнең

Әни сөйләгән усал Бүрегә дә ошагансың. Туктагыз! Беркая да бармыйбыз! Саубуллашык та, өйгә кайтыйк! – дигән.

Бүре баласы өненә йөгергән.

Күктә ай калыккан. Йолдызлар җемелдәшә башлаган. Бәтиләр куркуга төшкәннәр. Әти-әниләрен сагынып елый да башлаганнар. Батыр исемле бәти ничек юл табыйк икән дип баш вата башлаган.

Шул чагында бер шомлы тавыш ишетелгән. Бәтиләр бер-берсенә тагын да ныграк елышканнар. Елаудан да туктап калганнар. Алар каршысына салмак кына янып торган зур сары ике шар очып килгәнен күргәннәр.

Өчесе дә чытырдатып күзләрен йомганнар. Тавыш тынып калгач, бәтиләр күзләрен ачып карасалар, каршыдагы агач ботагында дуслары Ябалак утыра икән. Бәтиләр бик сөенгәннәр. Алар Ябалакка ничек адашканнарын сөйләп биргәннәр. Ябалак дусларын өйләренә кадәр озата барган. Саубуллашканда Ябалак бәтиләргә болай дигән:

– Дусларым, менә белдегезме инде үзегез генә урманга керергә ярамагын! Урманда адашырга мөмкин! Әле ярый мин очрадым. Урманда бит төрле хәлләр булырга мөмкин. Усал җәнлекләр дә юлыгызда очрап куюы бар иде...

Бәтиләр Ябалакка рәхмәт әйтеп өйләренә йөгергәннәр. Урамда инде кап-караңгы төн булган. Әти-әниләре улларын эзләп, елый-елый инде аптырап беткән булганнар. Кәҗә бәтиләрен күреп алар бик сөенгәннәр. Бәтиләр алардан гафу үтенгәннәр, башка болай эшләмәскә сүз биргәннәр. Шушы хәлдән соң алар һәрвакыт өй тирәләрендә генә уйнап йөргәннәр, үзләре генә болын-урманнарга бармаганнар.

***Исламов Алим,***
*ТР Казан шәһәре Идел буе районының «35 нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» МБГББУ 4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гыйләҗева Гөлнара Фаил кызы,*
*Ханнанова Миләүшә Хатип кызы*

## *Озын сакаллы кәҗәнең язмышы*

Борын-борын заманда яшәгән ди бер озын сакаллы кәҗә. Кәҗәнең булган ди бик акыллы, бик тәрбияле хатыны. Алар бик тату гына гомер иткәннәр ди.

Офыкта кояш күренүгә, кәҗә базарга барырга яраткан. Җанварларны күзәтеп, аларны өйрәтеп йөри торган бер гадәте дә булган. «Минем сакалым юкка гына озын түгел, минем белемем дә бик күп...» – дип тирәяктагы күршеләрен интектергән. Базарга килү белән ул башта барысына да кызыксынып карап торган. Барлык җанварлар да эш белән мәшгуль икән: кемдер ашамлыклар сата, кемдер тәм-том пешерә, кемдер вак-төяк әйберләр ясый икән. Аларның эшләүләрен күреп, түзеп тора алмыйча, барысыннан да гаеп табып йөргән. Янәсә аннан да оста пешерүче юк, аннан да әйбәт эшләүче юк, дип тегеләрне гел өйрәткән. Шулай вакытын бушка сарыф итеп йөри торгач, бу күрше-күләннәрен тәмам интектереп бетергән. Шул вакыт күршесе түзә алмыйча, кәҗәгә сорау биргән:

– Карале, күршем, синең өйдә бер эшең дә юк мәллә? – дигән куян.

Кәҗә дә югалып калмаган, минем бит өйдә бик акыллы, эшчән хатыным бар, – дип җавап кайтарган. Ул өйдәге барлык эшләрне дә җиренә җиткереп башкара. Мин үзем шундый булган кәҗә, минем тормышым да җитез дип, и мактанган, и мактанган икән. Бу мактанулары белән, хәтта, А. Алишның Сертотмас үрдәген дә уздырып җибәргән (*әлеге әкияттә сер тотмау турында булса да)*. Шулай мактанып йөри торгач, вакытның узганын да, кич булганын да сизми калган...

Аның болай мактанып йөрүеннән, вакытын бушка уздыруын-нан кәҗә хатыны да тәмам туйган. Шулай бер көнне ул ирен акылга утыртырга дип, бер хәйлә корган һәм көндәлек эшләрнең берсен дә эшләмәгән...

Кояшлы көннәрнең берсендә кәҗә уфтанып, бик арган һәм бик күп эш эшләгән кыяфәтләр чыгарып, өенә кайтып кергән ди. Өй ишеген ачып җибәрсә, өнсез калган. Кәҗә хатыны аякларын бөкләп, кәнәфидә тәмләп чәй эчеп утыра икән. Кәҗә хәләл җефетен күреп бик гаҗәпләнгән. Аның бит гомердә дә болай эшләгәне юк иде. Нәрсә булды икән? – дип, үз-үзенә сорау арты сорау яудыра башлаган. Ул шуның кадәр кызыксынучан булганга күрә, үзенең сорау биргәнен сизми дә калган.

– Нәрсә булды сиңа, кадерлем? Нигә өй эшләрен эшләнмәдең соң? Берәр нәрсә булдымы әллә? – дигән озын сакаллы кәҗә.

– Булды шул, кадерлем, булды, – дип җавап кайтарган кәҗә хатыны. Менә син югында башыма бик күп фикерләр килде. Аларны синнән башка эшлисем дә килмәде дигән. Бәлки, син минем бу фикерләр белән дә килешмәссең дип эшләмичә тордым, шуңа күрә синең өйгә кайтуыңны көттем. Карале, аппагым, син бит бикКк акыллы, бикКк белемле кәҗә. Синнән башка аларны ничек итеп башкарыйм соң, миңа бит синең акыллы киңәшләрең дә, синең ярдәмең дә кирәк. Менә өй эшләрен дә бергәләп, киңәшләшеп эшләсәк, тагын да тизрәк башкарылыр һәм күңеллерәк тә булыр иде, – дигән кәҗә хатыны. Юкка гына синең сакалың озын түгел бит инде, дип тә өстәгән зирәк кәҗә...

Менә шушы көннән алып, озын сакаллы кәҗә хатыны белән бик күп эшләрне бергә башкара торган булган. Базарга барырга вакыты да калмый башлаган, күрше-күләннәрен дә башка ялыктырып та, интекереп тә йөрмәгән. Аның болай үзгәрүенә җанварлар да таң калган. Кәҗә хатынының, чынлап та, зирәк булуына да инанганнар, бу үзгәрешләрнең үзәгендә ул торганлыгын да аңлаганнар алар. Менә бит зирәклелек сыйфаты бик күп бәлалардан коткара алуына инде ышанганнар. Аның асыл сыйфатларын – тырышлык, эшчәнлек, хезмәт сөючәнлек, ярдәмчел булу,

һәр эшне җиренә җиткереп эшләүдә күргәннәр. Төп асылы да нәкъ менә нәрсәдә икән бит, ә сакалның озын булуында түгел...

Бу әкият чынбарлыкта булдымы икән яисә бу минем иҗат җимешем генә микән? Ни булса да булган... без дә бит йоклар алдыннан шундый әкиятләр тынлый-тыңлый тәмле йокыга китәбез. Мондый матур әкиятләребез булуына без шатланабыз. Аларны шундый гади һәм аһәңле итеп иҗат итүче әкиятчебез – А. Алиш белән горурланабыз. Ул иҗат иткән әкиятләрне укып, без матур гадәтләргә өйрәнәбез. Ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү, гаделлек, намуслылык, батырлык, тыйнаклык һәм башка күркәм сыйфатларны булдырырга тырышабыз, гыйбрәт алабыз.

***Исламшина Ализа,***
*ТР Казан шәһәре Мәскәү районы Галимҗан Ибраһимов исемендәге*
*17 нче татар гимназиясенең 6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Абдуллина Рамилә Әгъзәм кызы*

## *Шерлок Холмс булмасам да...*

Беркөн әти миңа уенчык эт, ә әниемә бик тә тәмле кәнфәтләр күтәреп кайтты.

– Бу эт үтә сизгер, югалган, яшерелгән әйбәрләрләрне бик тиз таба, дип шаяртты. Минем күзем әнинең кулындагы кәнфитләргә төште. Моны күреп, әни:

– Кәнфитләрне хәзер ашамыйбыз, яшереп куям, – диде.

Кәефем бераз төшсә дә сер бирмәдем, бүлмәмә кереп киттем. Ми- нем яңа этем, чыннан да, бик сизгергә охшаган: борыны да кабарынкы, күзләре дә үткен. Шуңа күрә аңа Ватсон дип кушамат та тактым.

Әти белән әни эшкә чыгып китүгә, мин Ватсон белән өебезнең планын сыздым, бергәләшеп, кәнфитнең кайда булырга мөмкинлеген уйладык. Шуннан соң эшкә керештек. Аш бүлмәсендәге бөтен шкафларны актардык, микродулкынлы мичне дә ачып карадык, газ плитәсендәге кәстрүл эчләренә күз салдык – кәнфитләр табылмады. Безнең план буенча кәнфит залда да булырга мөмкин – анда да кәнфит юк иде.

Шулай эзли торгач, арып йоклап киткәнбез. Әти белән әни эштән кайткан. Мине өстәл әзерләшергә, кичке аш ашарга чакырдылар. Ват- сон да миннән калмады, өстәлгә ук менеп кунаклады. Аш бүлмәсендәге өстәлдә ризык өстендәге ашъяулыкны ачып җибәрсәм, бүген безнең ду

китереп эзләгән кәнфитләребез ята иде. Ашъяулык астына кәнфитне әни көндез үк куеп киткән булган. Барыбыз да, көлешә-көлешә, тәмләп чәй эчтек. Артур Конан Дойлның оныгы булмасам да, миннән Шерлок Холмс чыкмаса да, этем, һичшиксез, Ватсон бит әйеме?

***Кадирова Адилә,***
*ТР Казан шәһәре Совет районы 175 нче гимназиянең*
*4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Галиуллина Диләрә Әхмәдулла кызы,*
*Габделвәлиева Рәмзия Наил кызы*

## *Матур бүләк*

Дөньяда бик матур бер кыз яшәгән. Аның дуслары ел фасыллары булган. Бер көнне ул дусларын туган көненә чакырган. Дуслары бик шатланып бүләк әзерләгәннәр. Бүләккә яз-тал песие, җәй-аллы-гөлле чәчәкләр, көз-тук башаклар алып килгән. Ә кыш һаман да юк, ул нәрсә бүләк итәргә дә белмәгән, бүләксез килергә оялган, бик борчылган. Уйлый-уйлый башы катып беткән. Бик озак уйлаганнан соң, рәсем ясап алып килергә булган. Пыялага суыктан бик матур кар бизәкләре төшергән һәм дуслары янына туган көнгә килгән. Рәсем кызга да, ел фасылларына да бик ошаган. Шул көннән башлап, кыш үз вакыты җитү белән, дусты хөрмәтенә тәрәзә пыяларына, су өсләренә матур рәсемнәр ясый башлаган.

***Кадыров Илназ,***
*ТР Казан шәһәре Совет районы*
*111 нче мәктәпнең 5 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Досимова Гөлназ Рәхимҗан кызы*

## *Күбәләк кызы*

Борын-борын заманда бөҗәкләр патшалыгында яшәгән ди бер бик матур күбәләк кызы. Ул бик кызыксынучан булган, һәр нәрсәгә гаҗәпләнә, соклана икән. Шулай җәйнең бер матур көнендә күбәләк кызы әнисе белән болынга чыккан. Мондагы матурлыкка аның исе киткән. Нинди генә төстәге чәчәкләр юк икән болында! Күбәләк кызы гаҗәпләнә-

гаҗәпләнә бер чәчәктән икенчесенә кунган, хуш исләрен иснәгән, әнисен бөтенләй истән чыгарган. Чәчәкләр дә аның матурлыгына сокланганнар. Шулай оча торгач, ул әнисен күздән югалткан, караңгы төшә башлаганда гына үзенең адашканлыгын аңлаган. Бик озак елаган күбәләк кызы. Елаудан туктап күзләрен ачып җибәрсә, тораташтай катып калган. Аңа бер бик котсыз үрмәкүч карап тора икән. Менә ул күбәләккә таба якыная да башлаган. Бар табигать бу күренештән өнсез калган, бөтенесе дә күбәләк кызын бик кызганганнар. Күбәләк кызы куркудан күзләрен йомган. Менә җәтмәсенә эләктерәм дигәндә генә, каяндыр кәлтә килеп чыккан һәм үрмәкүчне кабып та йоткан. Күбәләк кызы курка-курка гына бер чәчәктә төн үткәргән. Әнисен бик сагынган. Хәзер инде ул дөньяның аллы-гөлле матур чәчәкләрдән генә тормавын, ә куркыныч та булуын аңлаган.

Менә иртә җиткән, кояш чыккан, һәм ниһаять, күбәләк кызын әнисе эзләп тапкан. Алар кочаклашканнар, елашканнар. Шул көннән башлап күбәләк кызы әнисеннән бер дә калмый ди.

***Кашапов Азат,***
*ТР Арча районы Иске Чүриле мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Камалова Гөлнар Илдар кызы*

# *Әти – әни сүзе*

Борын-борын заманда, моннан бик күп еллар элек Казан арты авылларының берсендә яшәгән ди, булган ди бер ир белән бер хатын. Аларның дүрт балалары булган, ди: өч малайлары һәм бер кызлары. Гаилә игенчелек һәм терлек асрау белән шөгыльләнгән. Ул заманнарда бар эш тә кулдан башкарылган. Алар ат, сыер, үгез, сарыклар һәм кош-кортлар асраганнар. Аның өчен күп көч кирәк булган. Малайлар бик кечкенәдән эшләп, әти-әниләренә булышып яшәгәннәр. Малайларның иң олысы-на ундүрт яшь, икенчесенә – унбер яшь, өченчесенә – сигез яшь, кыз- ларына өч яшь булган ди. Олы малайларның икесе гел әти-әнисе белән эштә басуда булганнар: сука сукалаганнар, чәчү чәчкәннәр, урганнар, җыйганнар. Кич белән йокларга гына кайта торган булганнар. Сигез яшьлек малай сеңлесен караган, өйдә хуҗалык эшләрен башкарган. Шулай эшләп көн күргән ди бу гаилә. Көннәрнең берсендә олы малайлар, әтиәнисенә әйтмичә бераз эшләгәч, урманга барып урман белән хозурланып, чикләвек җыеп, әти-әнисен, энеләрен – сеңелкәшен чикләвек белән сыйларга уйлаганнар. Шул уй белән урманга киткәннәр болар. Урман хәйран

ерак булган, бик озак барганнар. Барып җиткәннәр ди болар урманга. Көн көзге якка авышкан инде бу вакытта: август ахырлары, сентябрь башлары булган. Урманда инде кошлар да бик сайрамый, анда-санда гына кош тавышлары ишетелеп торган. Малайлар бик күп чикләвекле җир тапканнар, җыя-җыя гел эчкә кергәннәр. Җыя торгач, арып киткәннәр, ял итәргә диеп утырганнар икән, йоклап киткәннәр. Көн дә караңгылана башлаган. Анда барып карыйлар, монда барып карыйлар, кайтыр юлны таба алмыйлар болар. Йөри торгач, бер малайның күргән төше исенә төшә. Ул төшендә ак сакаллы бер бабайны күрә. Бабай малайга төшендә юл күрсәтә. «Шушы юлдан тайпылмыйча барсагыз, өйгә юлны табарсыз», – дип әйтә дә, юкка чыга. Малай абыйсына теге бабай әйткән сүзләрне әйтә һәм болар юлга кузгалалар. Шул юлдан бара торгач, урман кырыена килеп чыгалар. Кайтасы юлларын белеп алалар да, шул юл белән өйләренә кайтып җитәләр. Әти-әнисе дә бик борчылып көтеп торганнар, кочаклашып елашалар болар. Моннан соң әти-әнидән сорамыйча, аларга әйтмичә, беркая да бармаска дип сүз бирәләр.

Айлар, еллар үткән. Малайлар үсеп җитеп, үзләре әти булгач та, әти-әниләрен тыңлап яшәп яталар, ди. Әти-әни сүзен тыңласаң, беркай- чан да туры юлдан тайпылмассың, тормыш юлында адашмассың диеп, экиятемне тәмам итәм, дусларым!

***Мөхәммәтҗанова Адилә,***
*ТР Питрәч районы Ф. А. Сафин исемендәге Шәле мәктәбенең*
*6 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Җамалеева Тәнзилә Сәлим кызы*

## *Ике кыз һәм бер малай*

Борын-борын заманда, яшәгән, ди, ике кыз һәм бер малай. Боларның әниләре үги булган, ди. Шуңа да ана аларны бер дә сөймәгән. Эшсез тотмаган, бер дә рәхәт көн күрсәтмәгән. Ул аларны гел кыерсытып яшәгән. Кызларның түзәрлекләре калмагач, алар үги анадан качарга уйлаганнар. Боларның китәселәрен белгәч, энеләре бик елаган, ләкин әнисенә апалары турында берни сөйләмәгән. Апалары да энекәшләрен бик яратканнар, әмма үзләре белән алып китәргә ярамаганлыкны аңлатканнар. Кайчан да булса, энекәшләре янына кайтырга ышадырганнар.

Кызлар көн барганнар, төн барганнар. Юлларында бик биек тау очраган. Кызлар әлеге тауны бик авырлык белән үтеп чыкканнар. Тау

артында бик матур сарай күргәннәр. Тау астында сарайны җимеш агачлары әйләндереп алган. Ул агачлар гади түгел икән. Аларда җимешләр урынына төрле конфетлар үсәләр икән. Кызлар тау куышына кереп урнашканнар да һәр кичне качып кына конфет ашарга чыкканнар. Бу бакча патшаныкы булган. Ул, агачлардагы конфетларның югалганын күреп, бик борчылган һәм аны сакларга кешеләр куйган. Кичен кызлар бакчага чыгуга, сакчылар аларны тотып алып патшага китергәннәр. Патша кызларны күрүгә олысына гашыйк булган. Кече кызны исә энекәше ошаткан.

Кызлар матур гына яшәп киткәннәр. Әмма алар бертуктаусыз елаганнар, борчылганнар. Шуннан соң патшага үзләренең энеләре барлыгын, аның үги ана кулында яшәвен сөйләгәннәр. Патша үзенең ярдәмчеләрен алып кызларның туган авылына барып энекәшләрен алып кайткан. Чыннан да, үги ана малаен гел кыерсытып яшәгән, кечкенә булса да, бар эшне аннан эшләтә торган булган.

Кызлар энекәшләрен күргәч бик шатланалар. Энеләре патшаның сеңлесе белән кавыша Алар бергә-бергә матур гына яшиләр.

***Мөхәммәтова Динара,***
*ТР Арча районы В. Ф. Ежков исемендәге*
*1 нче мәктәпнең 4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Ибраһимова Ләйсән Фердинант кызы*

## *Буш хыял*

Борын-борын заманда түгел, безнең заманда, әллә кайда түгел, безнең якларда яшәгән ди, бер кыз. Әти-әнисе һәм кечкенә энесе белән матур гына гомер иткәннәр.

Бу кыз күктәге йолдызларны күзәтергә, хыялланырга яраткан, ди. «Шул балкып янган йолдызлар янында очып йөрсәң иде!.. Мәктәпкә дә барасы булмас иде», – дип уйлаган ул.

Шулай бер кичне, аның уйларын белеп, бер якты йолдыз кызны үзе белән күккә алып менеп китә. Кыз бик шатлана. Матурлыкны күзәтеп, йолдызлар белән очып йөри.

Ләкин бу рәхәтлек озакка бармый. Никадәр матур булмасын, җем-җем янган йолдызлар да салкын икән, иксез-чиксез күк йөзе дә шыксыз икән...

Кызның өенә кайтасы килгән. Йолдыз аны җиргә төшереп куйган. Кыз сөенеп, гаиләсе янына ашыккан. «Иң рәхәте үз өеңдә икән!» – дип уйлаган ул. Шулай шул!

***Наздекова Арина,***
*ТР Совет районы Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче*
*15 нче мәктәпнең*
*4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Сафина Талия Шәвәли кызы*

## Мактанчык бака

Көннәрдән беркөнне Бака су ярында мактанып утыра икән.

– Карагыз мине, мин нинди җитез, өлгер, шәп Бака!Телим икән – сикерәм, телим икән – суга чумам, телим икән – йөзәм!

Яр буеннан Ташбака үтеп бара икән. Бака аны күргәч, шаркылдап көлгән:

– Кара инде, ничек әкрен йөри бу Ташбака! Мин моны ике сикереп, бер атлап узам ич! Ха-ха-ха!

Шул чак камыш арасыннан бер Челән килеп тә чыккан, яр буенда мактанып торган Баканы кабып та йоткан!

Ә Ташбака үзенең каты күлмәгенә кереп качкан һәм исән калган.

***Сабирова Әминә,***
*ТР Балык Бистәсе районы Биектау мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хәбибуллина Зөмәрә Таһир кызы*

## Тылсымлы алмалар

Элек заманда бер авыл читендә бакчачы бабай яшәгән, ди. Аның алмала -ры бик сихәтле, тылсымлы булуы белән тирә– юньдә макталган. Көннәрнең берендә, бабайның өйдә булмавыннан файдаланып, бер усал малай бик күп итеп алма җыеп чыккан, ботакларын да сындырган.

Малай урлаган алмаларны ашаган. Тылсымлы алма ашап көчле, куәтле буласы килгән икән аның. Өенә кайтып керсә, өйдәгеләр ах иткәннәр. Көзгегә караса, күзе зурайган, кызарган, битләре каралган, колаклары тимгел– тимгел булып, черегән алма кебек ямьсезләнән, маңгаена ботак үсә башлаган. Әтисе белән малай тиз генә бабай янына килгәннәр. Бабай алдында малай башка бер дә урлашмаска сүз биргән, гафу үтенгән. Бабай малайга тылсымлы алма суы эчерткән. Малай элеккеге хәленнән дә матураеп, йөзе алсуланып калган.

Шуннан соң малай беркайчан да кеше әйберенә кул сузмый икән.

***Саттарова Сафия,***
*ТР Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге*
*20 нче гимназия укучысы*
*Җитәкче: Гарифуллина Ләйсән Шәукәт кызы,*
*Миңнуллина Гүзәл Сәхибҗан кызы*

## *Кар бабай*

Тышта ап-ак кар ява. Балалар кар бабай ясарга керештеләр. Кечкенә Дилә дә булышты. Ул өйдән кишер алып чыкты. Аны борын итеп куйдылар. Айдар күзләренә күмер ябыштырды. Кар бабайның кулына себерке тоттырдылар. Көлкеле килеп чыкты Кар бабай.

Кыш булды, караңгы төште. Балалар өйгә кайтып киттеләр. Бары тик Дилә генә китмәде. Ул Кар бабайны кызганды.

– Берүзе калгач, куркыр, – дип уйлады ул.

Дилә кардан эт баласы ясады.

– Икәү булгач, курыкмаслар, – диде дә Дилә өенә кереп китте.

***Фәхретдинова Ләйсән,***
*ТР Казан шәһәренең 6 нчы гимназия укучысы*
*Җитәкче: Фәхретдинова Гөлназ Фаил кызы*

## *Әтәч белән Тавык*

Әүәл заманда яшәгән, ди, Әтәч белән Тавык. Тавык бик мактанчык булган, ди.

Шулай беркөнне Тавык урманда җиләк чүпләп йөргәндә, каршысына Керпе очраган:

– Ни хәл, Тавык дустым? Урманда бер үзең нишләп йөрисең?

– Йомыркаларым тагын да тәмлерәк булсын өчен җиләк ашыйм, – дигән.

– Кара аны, Төлке эләктереп алмасын, – дип Керпе китеп барган.

– Мин беркемнән дә курыкмыйм, -дип Тавык урман эченәрәк кереп киткән.

Бу вакытта аларның сүзләрен куак артына посып, Төлке тыңлап торган. Шунда ук хәйләкәр генә каршысына килеп чыккан.

– Тавык дустым, бик вак кына җиләкләр чүпләп йөрисең икән. Минем өемдә бик эреләре бар, әйдә, миңа кунакка, – дигән.

Ә Тавыкны читтән күзәтеп йөргән Әтәч, Төлкенең хәйләсен бик тиз аңлаган. Каршысына батыраеп килеп чыккан да үзенең җырын сузып җибәргән:

– Көлә-көлтә койрыгым,
Тарактай кикригем,
Үткен минем томшыгым,
Дустымны кем кыерсыта,
Шуның күзен чукыймын!

Әтәчнең җырын ишеткәч, Төлке куркуыннан урман эченә качкан. Шул көннән башлап әтәч тавыкны гел саклап йөртә башлаган, ди.

**_Шәкурова Азалия,_**
_ТР Казан шәһәре Совет районы_
_156 нчы мәктәпнең 4 нче сыйныф укучысы_
_Җитәкче: Хафизова Лидия Хамзовна_

## _Песи баласы белән күбәләкләр_

Борын-борын заманда булган, ди, яшәгән, ди, бер песи баласы. Ул күбәләкләр белән бик дус булган. Алар белән көне буе уйнарга да риза икән. Бервакыт шулай күбәләкләрне куа-куа, әнисе яныннан бик еракка киткән. Яшел урман янына килеп чыккан. Ә күбәләкләр песи баласын онытып урман эченә үк очып кереп киткәннәр. Песи баласы һаман алар артыннан барырга тырышкан. Ләкин ул аларны күздән югалткан.

Менә кич җиткән. Песи баласы караңгы урман эчендә бер үзе калган. Куркуыннан нишләргә дә белмәгән.

– Әни! Әни! Әнием! – дип кычкырган.

Әнисе генә аны ишетмәгән.

Песи баласының елаганын ишетеп куян аның янына килгән. Ни өчен урман уртасында елап утыруын сораган. Куян аны бик кызганган һәм әнисе янына кайтырга булышкан.

Әнисе баласын күреп бик сөенгән. Куянга рәхмәтләр әйткән.

Шушы вакыйгадан соң, песи баласы күбәләкләргә үпкәләгән. Алар белән уйнамый башлаган. Әнисеннән рөхсәт сорамыйча еракка китмәгән.

# «АЛИШ ЭЗЛӘРЕННӘН» ЮНӘЛЕШЕ

## *Алиш мәхәббәте*

***Вәлиуллин Искәндәр,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*171 нче мәктәпнең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Гарәпшина Лилия Альберт кызы,*
*Вәлиуллина Әлфинур Вакил кызы, туган тел укытучылары*

Абдулла Алишның исеме дә зур хөрмәт белән искә алына, әсәрләре яратып укыла. Алиш иҗаты... Кемнәр өчен, нинди аудитория өчен күбрәк язган соң ул?

Безне аның өлкәннәр өчен язган әсәрләре бармы икән дигән сорау борчыды. Электрон челтәрләрне карап, шул сорауга җавап эзли башладык. «Сөембикә» журналында (Илсөяр Сөнкишева, «Сөембикә» №8, 2008. Тулырак: http://syuyumbike. ru/news/istoriya/alish-mkhbbte) чыккан «Алиш мәхәббәте» язмасында «Ул төшне мин кабат күрерменме?» шигырен укыдык һәм фәнни-эзләнү хезмәтебездә шушы шигырьгә тукталарга булдык. Бу теманы шәхсән үземә һәм минем яшьтәге егет-кызлар өчен актуаль дип саныйм.

Эшемнең максаты: Шагыйрьнең күңелен борчыган хисләрне табу, билгеләү. Кешене өч хис – мәхәббәт, ышаныч, өмет яшәткәнен анализ этапларында күрсәтү. Шушы максатымны тормышка ашыру өчен, мин түбәндәге бурычларны куйдым:

1. Абдулла Алишның сугышка кадәр һәм сугыш чорындагы иҗаты белән танышу.
2. Тема буенча кирәкле әдәбият, чыганаклар өйрәнү.
3. Шигырьгә анализ ясау аркылы автор әйтергә теләгән фикерне табу.

Өйрәнү объекты һәм предметы: Абдулла Алишның «Ул төшне мин кабат күрерменме?» шигыре.

Эзләнү-тикшеренү методлары:

1. Интернеттан, фәнни китаплардан, көндәлек матбугаттан мәгълүмат җыю.
2. Мәгълүматны эзләү, анализлау, чагыштыру методлары кулланылды.

Фәнни-эзләнү эше эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгаклау һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Эшемнең әһәмияте – бу шигырь яшьүсмерләр күңеленә үтеп керә. Лирик геройның үз тормышы мисалында гашыйк булу, гаилә кору, проблемалар туу, Ватанны саклау максатыннан аерылу һәм үткән хатирәләр белән яшәүне шигырь юллары аша күрсәтүе куәтле тәрбия чарасы булып тора. Минем уйлавымча, Абдулла Алиш кечкенә балалар күңеленә экиятләре аша үтеп керсә, өлкән буыннарга тормышы мисалында үрнәк кеше.

Эшемнең яңалыгы: шигырьне видео форматта уку.

Фәнни-эзләнү сыйныф сәгатьләрендә, тарих, әдәбият, туган якны өйрәнү дәресләрендә региональ компонент буларак файдаланырга мөмкин.

## *Абдулла Алиш әкиятләренең әһәмияте*

***Вахитова Алинә,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы*
*147нче рус-татар УББМ 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Шакирова Фәридә Исхак кызы,*
*туган теле һәм әдәбияты укытучысы*

Әкият – ул бөек могҗиза. Ул – халыкның рухи хәзинәсе, күңел сафлыгы, хисләр матурлыгы, изге хыяллары, фикер үткенлеге, зирәклеге чагылышы, иң асыл сыйфатлары тупланмасы.

Абдулла Алишның әсәрләре, бигрәк тә экиятләре бүгенге җәмгыятьтә бик актуаль булып кала. Аларны укып, һәркем я гыйбрәт ала, я чын күңеленнән соклана. Язучы-экиятчебезнең күпсанлы экиятләре гади, балаларга аңлаешлы тел белән язылган. Әкиятләре аша Абдулла Алиш балаларны табигать һәм тормыш-көнкүреш шартлары белән таныштыра, кечкенәдән үк бала характерында уңай сыйфатлар формалаштыру бурычын куеп, аларны төрле матур гадәтләргә, ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү, гаделлек, намуслылык, батырлык, тыйнаклык һәм башка күркәм сыйфатларны булдырырга тырыша.

Балалар өчен табигатьтәге һәр күренеш – серле һәм кызыклы, һәрнәрсә – яңалык. Алиш экиятләренең төп геройлары да – бөҗәкләр, кош-кортлар, җәнлекләр... Аның иҗатындагы табигатькә соклану, аңа мәхәббәт уяту табигатьне, мохитне саклау темасы белән бергә үрелеп бара. Ә бу проблема – хәзерге чор проблемаларының көн кадагына суга торганы, иң актуале, иң әһәмиятлесе.

# *А. Алиш геройлары мульфильмнарда һәм сәхнәләрдә...*

***Галеева Мәликә,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*7 нче гимназиянең 7 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Нәбиуллина Тәслимә Гыйниятовна,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

А. Алиш – балалар әдәбиятын үстерү юнәлешендә зур тырышлык куйган, төрле жанрларда эшләгән һәм татар әдәбиятында югалмас эз калдырган әдип. А. Алиш бөтен көчен, сәләтен, талантын балаларны тәрбияләүгә бирә. А. Алиш экиятләре сурәт һәм образларга бай, уку өчен җиңел әсәрләр. Бүгенге көндә А. Алиш экиятләрен китаптан укып та, мультфильм карап та өйрәнеп була. Татармультфильмы Г. Тукай, А. Алиш һәм халык экиятләре буенча безнең өчен мультфильмнар төшерә башлады. Татар теле дәресләрендә татар мультфильмнарын еш карыйбыз. Без аларны дискта, интернет аша да карый алабыз. Ул мультфильмнар безгә эти-әниләребезнең сүзен тыңларга, сер сакларга, тугры булырга өйрәтә. Шулай ук аның геройлары бездә хезмәткә, белемгә омтылыш уята. Әбибабаларыбыздан ишетеп, дәреслекләрдән укып белгән геройларын җанлы итеп күрү бездә бетмәс тәэсир калдыра. «Сертотмас үрдәк» экиятебелән китап, мультфильм аша гына түгел, сәхнәдә дә күреп, танышып була. «Әкият» курчак театрына барып, «Сертотмас үрдәк» спектаклен карадык**.** Ул музыкаль, күңелле спектакль, безгә бик ошады. Баш режиссер Зиннуров И. Н. белән әңгәмә кордык.

Күпме генә выкыт үтмәсен, тормыш ничек кенә узмасын, Абдулла Алиш үзенең гаҗәеп дәрәҗәдәге гүзәл әсәрләре белән һәр яңа буынны тәрбияләргә ярдәм итәр. Аның әсәрләрен укып үскән яңа буын һәрдаим үзенең рәхмәтен әйтер. А. Алиш – бүгенге һәм киләчәк буыннарның да тәрбиячесе булып калачак кеше.

# *Пчела – общественное насекомое*

***Гилаев Динар,***
*студент 1 курса 120гр. ГАПОУ «МЦК-КТИТС»*
*Руководитель: преподаватель ГАПОУ МЦК-КТИТС Шириева Г. М.*

После прочтения произведения «Пчела и оса» А. Алиша, я заинтересовался природой существования пчёл. Невольно начиная понимать их абсолютную противоположность, а также вдохновляясь прочитанным рассказом, мной было принято решения осветить одну из самых важных тем, по моему мнению, в нашем мире и миру будущего – это история обитателей нашей планеты.

Изучив разные источники литературы по данной теме, я выяснил, что пчёлы приносят пользу для народного хозяйства. Опыляя растения, они повышают, а часто целиком формируют их урожай. Также пчелы производят очень много разных пищевых продуктов (прополис, маточное молочко, перга, пчелиный воск, цветочная пыльца и другие) которые использует человек в качестве пищи и лекарств. О пчелах и продуктах пчеловодства на протяжении многих веков писали великие умы.

Пчела несет в себе тайну, тайну Природы. Изучая литературу, я не задумывался, что жизнь в пчелиной семье может быть устроена по каким – то законам и подчинена каким-то правилам. Мне казалось, что так живут только люди. Меня очень заинтересовало, как же устроена жизнь пчёл внутри одно пчелиной семьи, каким законам она подчиняется. Все это стало основой для моего исследования. Чтобы ответить на возникшие вопросы я решила провести собственное исследование.

В ходе выполнения данной исследовательской работы была изучена литература, содержащая информацию по данной теме. В моей работе я постарался использовать сведения из жизненного опыта пчеловодов-любителей и, полученные лично мною, при посещении пасек в разных деревнях. Изучение литературных источников позволило более полно изучить жизнь пчёл и в ходе наблюдения выяснить организацию жизни пчелиной семьи. В ходе выполнения экспериментальной части работы было доказано, что жизнь внутри одной пчелиной семьи носит четко организованный характер: каждой пчеле отведена своя роль и жизнь каждой отдельной особи в какой-то степени зависит от деятельности другой пчелы.

По возможному использованию результатов своего исследования могу сделать следующие выводы и рекомендации:

1. Довести до сведения учеников и их родителей результаты наших исследований.

2. Важным условием организации жизни пчёл внутри улья является четко организованный характер деятельности каждой пчелы.

3. Каждому виду пчёл внутри улья отведена своя роль.

4. Пчела не может жить в одиночку. Она – общественное насекомое.

5. Продукты, производимые пчёлами, разнообразны и приносят человеку пользу с древних времен.

Я узнал, что пчелы – это удивительные насекомые, вероятно, самые полезные насекомые на нашей Земле. Их жизнь подчинена строгим законам и направлена на построение и непрерывное развитие пчелиной семьи.

## *Абдулла Алиш – татар халкының батыр улы*

***Назмутдинова Язиля,***

*Казан (Идел буе) Федераль Университетының Алабуга институты*

*«Университет» ГББМ, 5 нче сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкчесе:Сахабиева Гөлфия Хафизовна,*

*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Абдулла Алиш нәни балалар өчен бик күп хикәяләр һәм әкиятләр иҗат итә. 1937 елдан алып А. Алиш «Пионер каләме» журналында – «Нәниләргә бүләк», «Яшь ленинчы» газетасында «Ана әкиятләре» сериясен башлап җибәрә. «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык», «Песиләр һәм күселәр», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык», «Куян кызы» [1] кебек әкиятләр балаларның танып-белү сәләтен үстерү, аларда уңай сыйфатлар, матур гадәтләр тәрбияләү, балаларны табигать күренешләре һәм хайваннар дөньясы белән таныштыру максатыннан язылганнар.

Абдулла Алишның әкиятләре бай эчтәлекле һәм тематикалы, ре-аль чынбарлыкка – кешеләр тормышына якын. Әкият геройлары булып хайваннар һәм кошлар, бөҗәкләр тора. Аларда кешегә хас сыйфатларны да күреп була (уяулык, сизгерлек, хәйләкәрлек, сер тотмау һ. б.). Мондый алым әкиятнең тәрбияви көчен арттыра, укучыга, вакыйгалар һәм персонажларның эш-гамәлләре турында фикер йөртеп, тиешле нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә.

1941 елда башланган коточкыч сугыш А. Алишны әкият иленнән ераккарак – фронтка алып китә, тоткынлыкта була.

*Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,*
*Әгәр югалтмаса вөҗданын;*
*Алтынны ул чүпкә санар,*
*Иң кыйммәтле күрер Ватанын.*

Сугыштан соң А. Алишның берничә шигыре хәрби әсир Н. Терегулов белән туган якларга кайта. А. Алиш белән әсирлектә булган һәм аның кайбер шигырьләрен хәтерләрендә саклап кайткан Г. Кадыйров һәм Т. Гыймрановларның күчермәләрен дә әйтергә мөмкин.

Абдулла Алиш үзенең якын дусты, көрәштәше М. Җәлил белән берлектә әсирлек шартларында җаваплы эшләр башкара. 1943 елда яшерен оешма эше ачылганнан соң, җәлилчеләр кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә. 1944 елның 25 августында унике татар каһарманы фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.

Шулай итеп, үзенең кыска гына иҗат гомере дәверендә А. Алиш киләчәк буыннар өчен шактый бай һәм кыйммәтле мирас – төрле жанрларда күп әсәрләр язып калдырырга өлгерә. Язучының «Сертотмас үрдәк», «Капкорсак патша», «Нечкәбил», «Бикбатыр белән Биккуркак» һ. б. әкиятләре татар һәм рус телләрендә дистәләрчә тапкыр басылып киләләр, балаларны тормышка, Ватанны сөяргә өйрәтәләр, дуслык хисе, яхшы сыйфатлар тәрбиялиләр. А. Алишның тоткынлык шартларында йөрәк каны белән язылган шигырьләре халкыбыз күңеленә мәңгегә кереп калган. Халык аның әкиятләрен бүгенге көндә дә яратып укый, шагыйрьне зурлый, хөрмәт итә, горурлык белән искә ала. Хәзерге вакытта туган авылы Көектә бөек шагыйрь Абдулла Алишның һәйкәле тора, мемориаль музей эшләп килә, Казанда Республика балалар иҗаты үзәге әдипнең исемен йөртә.

1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе карары белән балаларга атап язылган иң күренекле әсәрләре өчен Абдулла Алиш исемендәге еллык бүләкләр булдырылды.

Абдулла Алиш – халык мәңгегә онытмас батыр да, кыю язучы да.

# *Абдулла Алиш һәм аның көрәштәшләре*

***Сәгъдиева Язилә,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*Абдулла Алиш исемендәге 20 нече гимназиянең*
*8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Сәгъдиева И. М., Фәрхетдинова Э. М.*

Бөек Ватан сугышы... Бөек Җиңү... Бу вакыйгалар, андагы батырлыклар 70 еллык тарих катламы астында калды. Ләкин әнә шул катламнар астында югалмыйча, кешелек дөньясын юкка чыгудан саклап калган, бүгенге көннәргә кадәр халык күңелендә, ил йөрәгендә онытылмаган каһарманнарыбызның батырлыклары әле исән, дөнья тарихында алтын хәрефләр белән язылган.

Бөек Ватан сугышы Татарстан халкы өчен дә зур сынау була. Республикабыздан гына да **700 мең** кеше сугышка алына. Татарстаннан **200 гә** якын кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Алар арасында А. Алиш, М. Җәлил, П. Гаврилов, М. Девятаев, М. Сыртланова, Г. Гафиятуллин кебек исемнәре батырлык символына әйләнгән кешеләр бар. Бөек Ватан сугышы башлануга, күп кенә язучылар, шагыйрьләр, бөтен халык белән бердәм булып, илне басып алучыларга каршы күтәрелделәр, зур көрәшкә килеп кушылдылар. Алар, кулларына корал алып, сугышка киттеләр, фронт газеталарында эшләделәр, турыдан-туры сугышта катнаштылар: Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Шамов, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Ә. Еники, Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, М. Җәлил, А. Алиш һ. б. Кызганычка каршы, 30 дан артыгы сугыш кырларында яисә әсирлектә һәлак булдылар.

Кеше кайчан халык күңеленә мәңгегә кереп урнаша соң? Зур батырлыклар эшләсә, аның өчен яшәсә, аның мәнфәгатьләрен һәм хәсрәтләрен чагылдырып иҗат итсә... Әйе, язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез явыз дошманны җиңү өчен изге сугышта катнашып кына калмадылар, искиткеч батырлыклар күрсәтеп, үлмәс әсәрләр дә иҗат иттеләр.

Эзләнүле-тикшеренү эшен, сугыш чоры әдәбиятының солдат образын төгәлрәк ачу өчен, сугышның үзәгендә булган герой-шагыйрь Абдулла Алиш тормышына һәм иҗатына нигезләнеп тәкъдим итәбез. Чөнки бу шәхеснең батырлыкларына сокланабыз, әсәрләрен укып хисләнәбез. Бу чордагы солдат образын, аның күңелен, аннан да яхшырак, аннан да якынрак белүче һәм укучыга җиткерүче юктыр кебек. Аның белән беррәттән, Кама Тамагы районы Чаллы авылында яшәүче Гайнан бабай Насыйров истәлекләренә нигезләнәбез.

Кешелек дөньясын юкка чыгудан саклап калган, бүгенге көннәргә кадәр халык күңелендә, ил йөрәгендә онытылмаган каһарманнарыбызның батырлыклары әле исән, дөнья тарихында мәңге онытылмас булып ташка уелган. Шуңа күрә без аларны онытмаска, сафлары сирәгәя барган сугыш ветераннарын, тыл батырларын хөрмәт итәргә, зурларга, батырлыкларын киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез.

## *Балалар язучысы – Абдулла Алиш*

***Сошникова Диана,***
*Казан (Идел буе) Федераль Университетының Алабуга институты*
*«Университет» ГББМ, 5 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе:Мухутдинова Руфия Ралифовна,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Халык иҗатында игътибар арту, алдынгы рус һәм Европа әдәбияты белән бәйләнешләр ныгу – болар барысы да XX йөз башы татар балалар әдәбиятында әнә шундый билгеләрнең өстенлек алуыннан килә.

Балалар әдәби әкиятләренә килсәк, аларның күбесе, нигездә, халык иҗаты сюжетларына таянып иҗат ителә. А. Алиш, Р. Батулла, Р. Хафизова, Н. Сәйяр һәм башкалар чын мәгънәсендә әкият осталары. Бу жанрда иҗат итү язучыдан бөтен көчен, сәләтен бергә туплауны сорый, сюжет нигезенә куелган тирән мәгънәне тар гына калыпка салуны таләп итә. Әкиятләр бит 6-7 яшьлек сабыйлар белән янәшә олылар, ягъни аларның ата-аналары һәм әби-бабалары өчен дә языла.

Татар милләте үзенең татар теле, әдипләре аркасында көчле. Чиксез зур өлеш керткән балалар язучыларының берсе – Абдулла Алиш. Балаларны ярата, алар белән аралаша, алар белән сөйләшә, аларның телен, теләкләрен, дөньяга үзенчәлекле карашларын яхшы белә торган кеше ул.

А. Алишның татар әдәбиятында, беренче чиратта, балалар әдәбиятында тоткан үз урыны бар. Ул балалар күңеленә үтеп кергән, аларның телен аңлаучы, балаларга тәрбия бирүче язучылардан. Әкиятләрен бик яратып бүгенге көндә дә укыйлар. Мәктәп программасына аның «Чукмар белән Тукмар», «Сертотмас үрдәк», «Нечкәбил», «Мактанчык Чыпчык һәм тыйнак Сыерчык» кебек әкиятләре кертелгән.

Абдулла Алиш үзенең әкиятләре белән балаларда туган халкына тугырылыклы булу, батырлыкка һәм хезмәткә әзер тору хисләрен тәрбияли; табигый образлар, кош-кортлар, җәнлек-хайваннар тормышы аша эколо-

гик проблемаларны хәл итәргә омтыла. «Сертотмас үрдәк»кә күз салыйк. Теленә хуҗа булалмаган үрдәк, башка хайваннар белән чагыштырган, оча, йөзә, чаба белүенә карамастан, һәлакәткә дучар була. Ул изге бурычын – йорт-ватанының иминлеген һәм тынычлыгын тәэмин итүне оныта, аны куркыныч астына куя. «Нечкәбил» кечкенәләргә кош-кортлар турында мәгълүмат бирү белән бергә «хәзмәт кешесе – хөрмәт кешесе» фикерен җиткерә. Нәни генә бал корты күрсәткән эш, һичшиксез, барыбызны да сокландыра, хезмәткә өнди, хикмәтнең гәүдә зурлыгынада түгеллеген тагын бер кат раслый.

Абдулла Алиш... Дөньяда аз гына яшәп тә, үзенең гүзәл тормыш юлы, фидакарь эшчәнлеге, Ватанга тугрылыклы булуы һәм батырлыгы белән халык күңеленә кереп калган кешеләр рәтендә тора ул. Ватан иминле- ген саклауда җанын да кызганмаган, соңгы сулышына кадәр сөйгән халкына тугры калган олы җанлы каһарман ул Алиш. Гомүмән алганда, А. Алишның гади генә сюжетка корылган әсәрләре югары художестволы образлар аша олы фикерләргә китерә, кешенең гражданлык сыйфатын үстерә.

## *По следам «Прерванной песни»*

***Хабибрахманова Амалия,***
*ученица 6 класса МБУДО ДДЮТиЭ «Простор»*
*Ново-Савинского района г. Казани*

Нам, живущим в 21 веке, нельзя забывать о том, как важно сохранить для большой истории всё то, что сегодня кажется не таким значительным, историю повседневности, так как нет будущего без прошлого. На занятиях мы побывали в музее детской литературы, познакомились с обстановкой, в которой жили писатели прошлого века. В год 75-летия Победы участвовали в проекте «Книга памяти». В этом году исполняется 115 лет со дня рождения поэта-героя Мусы Джалиля, 110 лет со дня рождения Сибгата Хакима и Абдрахмана Абсалямова, 100 лет Паушкину Г. А., 105 лет детскому писателю, журналиста Шамилю Гарая. На основе его архива создан музей детской литературы в ДДЮТиЭ «Простор». Он родился 31 декабря 1916 года в Казани. В нашем семейном архиве сохранился богатый материал (письма, фотографии, документы, книги) о Шамиле Гарае. С раннего возраста у него была большая тяга к знаниям, способность к поэзии, любил рисовать и играть на гармони и пианино.

В ходе поисково-исследовательской работы мы обнаружили, что в 1931 году было опубликовано первое стихотворение «Октябрятлар жыры» в газете «Яшь ленинчы». Работая в архиве и Национальной библиотеке РТ, мы узнали, что до войны у него издано 6 книг, переводил стихи Лермонтова, Барто, Квитко, Чехова и др. В 1936 году с Абдуллой Алишем был в творческой командировке в Харькове и Москве. С началом Великой Отечественной войны поэт уходит на фронт 26 июня добровольцем, попадает в плен около г. Великие Луки. Находится на лечении в госпитале в Гливице (Польша). Умер 22 марта 1946 года и похоронен на красноармейском кладбище в Гливице.

Вот как вспоминала журналистка Марьям Дибаева, которая работала в редакции журнала «Азат хатын»: Он заходил в нашу редакцию, читал свои произведения. Я часто встречала его с Абдуллой Алишем. Прошло много лет, многое забылось. Шамиль остался в моей памяти в плен, не испытал всех ужасов войны и вернулся бы живым, он стал бы таким же известным поэтом как Сибкат Хаким. К сожалению, мы его очень рано потеряли…»

## *Абдулла Алишның тоткынлыктагы иҗаты*

**_Шигабутдинова Зәринә,_**
*МБОУ « Казан шәһәре Совет районының*
*«124 нче рус-татар ГУБМ» 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Чукурова Лариса Ивановна,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

А. Алишның үз шигырьләрен, язмаларын укыганда да безнең күз алдына Ватаны һәм халкы өчен үлемне дә батырларча каршыларга әзер булган көчле рухлы кеше килеп баса. Берлин төрмәсендә язган хатындагы: «Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга турылыклы булып калабыз», – дигән сүзләр үзләре генә дә ни тора!

Сөекле әкиятчебез А. Алиш үзенең әкиятләре белән дошманга каршы көрәш алып барган. Газаплы әсирлек шартларында да ул дошман алдында тез чүкмәгән, көрәшчеләр сафында булган, тирән лирик кичерешләр белән сугарылган шигырьләр, әкиятләр иҗат итәргә дә үзендә рухи көч тапкан. А. Алишның «Өметем зур минем киләчәккә» дигән шигырендә, легионга хәтле үк, аның нинди уйлар, кичерешләр белән януын тулырак аңларбыз.

*Язмыш миңа усал караса да,*
*Бирешмәскә телим аңарга.*
*Яфраксыман үзем саргаймыймын,*
*Тик чәчләрем генә агара.*

А. Алиш тоткынлыкта шигырьләр, әкиятләр, проза әсәрләре, нәсерләр дә язган. Шундыйларның берсе, «Сандугач» исемлесе, туган ягының табигате турында булган. Абдулла Алиш шигырьләрендә Туган илгә чиксез мәхәббәт, аны сагыну, Ватанга һәм халыкка тугрылык идеяләре чагыла һәм алар бу яктан Муса Җәлил шигырьләре белән аваздаш яңгырый. Андагы: «Мин теләмим андый исәнлекне...» дигән сүзләрдән дә шул фи- кер аңлашылып тора бит. «Дуска» шигырендә М. Җәлил һәр икесе өчен дә бу үлемнең Ватан алдында тугрылык билгесе булачагын әйткән... ул шигырьләренең бер өлеше генә булса да кайтып ирешүен теләгән, алар аша үзенең вөҗданы сафлыгын, иленә һәм халкына, якыннарына булган эчкерсез хисләрен, тугрылыгын белдерергә өметләнгән.

Шунысы да билгеле: Алиш туган илгә юллаган блокнотына үз шигырьләренең кайберләрен генә язган, калган битләренә М. Җәлилнең дә 15 шигырен сыйдырган. Бу факт А. Алишның фикердәш дусты Муса Җәлилнең иҗатын югары бәяләп, ничек тә аны саклап калырга тырышкан. Алиш шигырьләренең бер өлеше генә булса да туган илгә кайтып ирешүен теләгән, алар аша үзенең вөҗданы сафлыгын, иленә һәм халкына, якыннарына булган эчкерсез хисләрен, тугрылыгын белдерергә өметләнгән. Абдулла Алишның бу теләге үтәлде: шигырьләренең кайберләре әледән-әле басылып тора. Рафаэль Мостафин Алишның озак еллар буе архивта яткан шигырьләрен рус теленә тәрҗемә иттереп, «Три поэта-воина» дигән җыентыкка кертте. Алишның әсирлектә фашизмга каршы шәхси көрәше батырлык, фидакарьлек үрнәге буларак халкыбыз күңелендә яши бирә, әдәби мирасы татар балалар әдәбиятының җуелмас рухи хәзинәсен тәшкил итә.

# *Сугыш чоры иҗаты – Туган илгә тугрылык билгесе*

***Шириева Иллария,***
*Арчаның 5 нче гимназиясе МБГБУ 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Гыйлаҗиева Лилия Фатыйх кызы,*
*татар теле әдәбияты укытучысы*

Абдулла Алиш – татар балалар әдәбиятында зур хезмәт күрсәткән язучыларның берсе. Илебезгә дошман яулары басып кергәч, ул да Ватанны саклаучылар рәтенә баса, фашизмга каршы көрәштә үз-үзен аямыйчакөрәшә һәм батырлыгы аша исемен данга күмә. Аның иҗаты – туган илгә тугрылык билгесе. Чөнки Алиш нинди генә шартларда да кулыннан каләмен төшерми, үзенең ялкынлы иҗаты аша иленә тугрылыклы булып калуын раслый. Аларның язмышы бүгенгесе көндә дә әдәбият белгечләре, галимнәр тарафыннан өйрәнелгән иң актуаль темаларның берсе булып тора.

Дошман алдында тез чүкмәгән, әсирлек шартларында да иҗат белән шөгыльләнергә үзендә көч тапкан шагыйрь тормышы һәм иҗаты миндә кызыксыну уятты һәм әлеге хезмәтемне язарга этәргеч тудырды. Төп максатым – Абдулла Алишның тоткынлык шартларындагы иҗатын өйрәнү.

Шушы максаттан чыгып үзалдыма түбәндәге бурычлар куйдым:

– А. Алишның сугыш чоры тормышын өйрәнү.

– Бу чордагы иҗатына күзәтү ясау.

– Өйрәнгәннәрдән чыгып бигеле бер нәтиҗәләргә килү.

– А. Алишның сугыш чоры тормышын, иҗатын өйрәнгән шәхесләрнең хезмәтләренә күзәтү ясау.

Куелган бурычларны тормышка ашыру максатыннан миңа китапханәләрдә булырга, шагыйрьнең китаплары, аның иҗаты турында язылган тәнкыйть мәкаләләре белән танышырга туры килде. Күзәтәләрем аша аерым нәтиҗәләр ясадым.

Шулай итеп, мин үземнең «Сугыш чоры иҗаты – Туган илгә тугрылык билгесе» исемле хезмәтемдә шагыйрьнең бу чордагы газаплы, авыр тормышына, иҗатына, аның белән аралашкан шәхесләр эшчәнлегенә, аның иҗатында күтәрелгән темаларга һәм дәфтәрләренең Туган илгә кайту тарихына күзәтү ясадым. Күзәтүләремнән чыгып, билеле бер нәтиҗәләргә килдем. Дөрестән дә, А. Алиш – чын мәгънәсендә татар халкының батыр исеменә лаек булган шагыйре. Нинди генә авыр шартларда да дошман алдында тез чүкмәгән, әсирлек тормышының иң авыр шартларында да көрәшчеләр сафында калган, җиңүгә булган ышанычын югалтмаган,

Ватанына һәм халкына тугрылыкны соңгы сулышына кадәр саклаган. Шундый мәсхәрәле тормышта да иҗат итәргә көч тапкан, үзенең ялкынлы шигырьләре аша иптәшләренә юаныч биргән. Ләкин иҗатының күп өлеше Туган илебезгә кайтып җитмәве кызганыч. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән бергә, шагыйрьнең батырлыгы, ихтыяр көче һәркемдә соклану хисе уята. Фашистларның үлем лагерьларында да, салкын кысан төрмәләрендә дә бары тик иле, халкы турында уйланаһәм тоткынлыкта язган шигырьләре аша моны бөтен дөньяга ишетелерлек итеп әйтә:

*Көрәш белән тудык, көрәш белән*
*Керәбез дә, ахры, кабергә.*
*Язган икән соңгы сулышыбызны*
*Илебез бәхете өчен бирергә!*

Минемчә, илебез бәхете өчен көрәшкән А. Алиш һәм җәлилчеләр «батыр» исеменә мең тапкыр лаек! Соңгы сулышларында да Коръәнгә кулларын куеп, моңлы татар җырын җырлап саубуллашулары бу каһарманнарның туган илләрен өзелеп сөюен, аңа тугрылыклы булуларын раслый бит.

## *Ветеран в моей семье*

***Юсупов Рамис,***
*ученик 11 класса*
*МБОУ «Гимназия №9» Московского района г. Казани*
*Руководитель: Ахметова Л. Г., учитель родного языка и литературы*

Победа в Великой Отечественной войне досталась нам дорогой ценой.

Во многих семьях стали реликвиями письма военных лет.

**В чем же актуальность моей исследовательской работы?** Дата 75-летия Великой Победы является особенной для каждого жителя Рос- сии. Изучение биографий дорогих нам людей, их фронтовых писем позволяет представить реальные события войны, увидеть яркие иллюстрации того времени, восстановить подлинную картину сражений глазами солдат, принесших Победу.

**Новизна исследовательской работы** обусловлена тем, что данный подлинный материал позволяет проследить судьбу участника Сталинградской битвы на фоне исторически значимых событий второй мировой войны.

**Главная цель моей исследовательской работы** – на основе рассказов детей участника Великой Отечественной войны восстановить историю своей семьи, сопоставить её с исторически значимой датой. Начиная работать над исследованием, я поставил перед собой следующие задачи:

– выяснить, кто мой прадед;

– понять, каково его место в хронологии Великой Отечественной войны 1942 – 1943 гг;

Личные воспоминания дедушки Юсупова Табриса Гарифзяновича и на единственное письмо моего прадеда Юсупова Гарифзяна Юсуповича.

**Объект исследования** – биография участника Сталинградской битвы:личные воспоминания дедушки Юсупова Табриса Гарифзяновича и на единственное письмо моего прадеда Юсупова Гарифзяна Юсуповича.

При изучении использованы ***практические*** **методы:** опрос, беседа, анализ.

По ходу работы были изучены и проанализированы фотографии, хранящиеся в личном архиве семьи Юсуповых, проведено интервьюирование сыновей и дочерей Юсупова Г. Ю., изучены материалы, посвященные Сталинградской битве в Великой Отечественной войне.

Подводя итоги своей работы, я могу сказать, что я достиг той цели, которую поставил в начале своей работы. Я собрал и систематизировал материал об участии моего прадеда в Великой Отечественной войне. Результаты проведенной работы оформлены в виде печатного документа.

Когда я первый раз увидел Книгу Памяти и прочитал там фамилию и данные прадедушки, меня охватили чувства, которые нельзя выразить одним словом: это и боль, и слёзы, и радость. Боль и слёзы за украденное детство моего родственника, радость за тех людей, которые прошли страшное пекло войны и возвратились домой с победой. Я очень горжусь своим родственником.

Выполняя эту работу, я узнал еще больше о жизни моей семьи.

## «ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА БАТЫРЛЫК ТЕМАСЫ» ЮНӘЛЕШЕ

# *Шагыйрь Фатих Кәрим тормышында кызыклы фактлар*

***Алиакберов Фәнис,***
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*24 нче мәктәпнең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Шәйхетдинова Люция Хәбир кызы,*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Безнең татар поэзиясе фронтовик шагыйрьләргә бай. Иң популяр шагыйрь кем дип сорасалар, Фатих Кәрим дияр идем мин. Бөек Ватан сугышы башлангач, ул, кулына корал алып, туган илебезне якларга китә.

*Сөйләр сүзләр күпләр алар, иренмичә сөйләсәң;*
*Озын сүзнең кыскасы шул: күп яшәргә теләсәң,*
*Үлем турында уйлама, илең турында уйла,*
*Илең турында уйласаң, гомерең озын була.*

Талантлы шагыйрь һәм батыр сугышчы Фатих Кәрим бу сүзләрен үзенең тормышы һәм иҗаты белән раслый. Аның исеме бик күп сугыш корбаннары арасында югалып калмады. Сугыш елларында Ф. Кәрим150 гә якын шигырь, 8 поэма, 2 чәчмә әсәр, 5 пәрдәле драма, җырлар иҗат итеп калдыра. «Разведчик язмалары», «Язгы төндә» повестьлары проза әсәрләре арасында аеруча әһәмиятле урынны алып тора. Аларда сугышларның җиңүебезгә олы ышаныч белән яшәүләре, шушы изге максат өчен бөтен көч-ихтыярларын туплаулары сурәтләнә.

Фатих Кәрим иҗатын, катлаулы язмышын тулырак өйрәнү өчен аның тормышы белән бәйле кызыклы фактларны җыярга булдым. «Тамчылардан күл җыела» – ди халык мәкале. Һәрбер яшь кеше үзен кызыксындырган бер генә теманы өйрәнсә дә, әдәби мирасыбыз югалмаячак дип уйлыйм. Шушы проблемалар мине уйланырга мәҗбүр итте**.** Татар шигърриятенең горурлыгы булган җырчы һәм солдат Фатих Кәрим тормышыннан кызыклы фактлар туплау һәм башка укучыларга да җиткерү өчен актуаль тема булуы бәхәссез.

Мәктәпне тәмамлап, зур тормышка аяк баскан һәрбер укучы кайда гына булса да, шагыйрь иҗаты белән кешеләрне таныштыра, кызыксындыра алырга тиеш. Безнең эзләнү эшебез дәресләрдә файда китерердәй һәм булган материалларны тулыландырырдай мәгълүмат булып туплануы күз уңында тотыла. Мин генә түгел, башка татар әдәбияты белән кызыксынучыларга да әһәмияте зур булыр дип уйлыйм.

# *Фатих Кәрим сугыш елларында*

***Асылгәрәев Ильяс,***
*Казан шәһәре Вахитов районы*
*13 нче мәктәпнең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Губайдуллина Фидания Рифкатовна,*
*туган тел укытучысы*

Сугыш. Бу коточкыч сүзне бөтенләй ишетәсе килми. Күпме гүзәл тормышны җимергән, бабасыз, әтисез, абыйсыз калдырган Бөек Ватан сугышы. Шушы сугышта һәлак булган Фатих Кәрим кайларда булган, ниләр кичергән, нәрсәләр язган? Әлеге сорауларга җавап табу өчен, мин эзләнү-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә булдым.

Фатих Кәрим (1906-1945) – танылган татар шагыйре, язучысы, әдәбият хезмәткәре, йөзләгән шигырь, 12 поэма, 2 повесть, 1 драма, унлаган публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләренең авторы.

Урынсызга рәнҗетелгән, 1937-1941 елларда төрмәдә утырган шагыйрь 1941 елның 1 декабрендә ireккә чыга. Ирекке чыккан көннәрендә күбрәк гаиләсе белән бергә булырга тырыша. Гаиләсен сагынып кайтса да, Фатих Кәрим сугышка тартыла, Ватаны турында кайгыра, үзен фронтка җибәрүне тизләтә.

1941 елның 28 декабрендә Фатихка сугышка чакыру кәгазе килә, ә январь башында ул сугышка китә.

Фатих Кәрим сугыш елларында 150 гә якын шигырь, 8 поэма, 2 повесть, 1 пьеса язган. Аның мондый иҗади эшчәнлеген әдәбият галимнәре тиңдәшсез дип атыйлар. Ә күңелендә һәм уенда эшләнеп тә кәгазьгә төшерергә өлгермәгән әсәрләре бихисап күп булган аның. Кадрия Ишуковага – сугыш кырларыннан, госпитальләрдән язган хатларында ул иҗатка мөмкинлек булмавы турында бик еш сыкранып хәбәр итә. Әмма ул язган. Дәфтәрен кирза итек кунычына куеп та, автомат прикладын өстәл итеп тә, немец өе подвалларында да, окопларда да язган. Шагыйрьнең илһамы язгы елга кебек тыелгысыз булган.

Язган әсәрләрендә фашистларга карата нәфрәтен, туган илгә мәхәббәтен, якты киләчәкне күрсәтергә тырышкан. Һәрвакыт күтәренке күңелле булып, иптәшләренең дә кәефен төшермәгән. Әдәбияттан бервакытта да ераклашмаган, гаиләсен, туган илен кайгырткан.

Сугыш елларында Фатих Кәрим үзен кайгыртучан әти, яратучы ир, талантлы шагыйрь һәм язучы, туган иле өчен көрәшүче солдат буларак күрсәткән.

Үлгәннең икенче көнендә үк, Фатих Кәримгә наградной лист билгелиләр. Ватан сугышының беренче дәрәҗәдәге ордены белән бүләклиләр.

Киләчәктә Фатих Кәримнең шигырьләренә, поэмаларына тулырак тукталып, анализ ясарга уйлыйм.

## *Габдрахман Әпсәләмов иҗатында сугыш темасы*

***Газизова Азалия,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*43 нче мәктәпнең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Баһабиева Лилия Данис кызы, туган тел укытучысы*

Ватан, туган ил, туган җир... Бу төшенчәләр эти – әни кебек үк якын, кадерле. Тыныч тормышта без үз туган җиребезнең кочагында иркәләнеп үсәбез һәм аның кадере, яшәешебезнең бер өлеше булуы турында бик үк уйланмыйбыз да. Дәһшәтле сугыш вакыйгалары турында без китаплардан укып, кинофильмнардан карап, әби – бабайлар сөйләгәннән генә беләбез.

Сугыш елларында татар халкы беренче булып, явыз дошманга каршы батырларча көрәште. «Татар сугышчылары» сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын – Ватанга бирелгәнлек, үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык сыйфатларын гәүдәләндерделәр.

Күп язучылар, кулларына корал алып, сугышка китәләр, фронт газеталарындаэшлиләр, турыдан-туры сугышта катнашалар:Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Шамов, Ф. Кәрим, М. Җәлил, А. Алиш, Ш. Ман-сур, Ш. Мөдәррисһ. б.. Дәһшәтле сугыш елларында язылган шигырьләр, хикәяләр киләчәк буыннарга шул җиңү юлының Изгелеге һәм Бөеклеге хакында искәртеп тора.

Сугыш елларында поэзия, проза, драматургиядә, гомумән, әдәбиятнең барлык жанрларында да изге Ватан өчен көрәш һәм батырлык темасы үзәктә торды. Сугышның башлангыч чоры һәм аның хәлиткеч вакыйгалары, Бөек җиңүгә килүнең авыр юллары – болар барысы да әдәбиятта үзәк темалар буларак чагылыш тапты.

Г. Әпсәләмовның тормыш һәм иҗат юлы белән кызыксыну мине фәнни-эзләнү эшенә этәрде. Ул татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган зур язучы.

Хезмәтебезнең объекты – Габдрахман Әпсәләмов эшчәнлеге. Предметы исә Габдрахман Әпсәләмовның батырлык темасын яктырткан хикәяләре.

Фәнни эшебезне язганда түбәндәге максатны куйдык: күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмовның сугыш чоры хикәяләрен уку һәм геройларының батырлыкларын билгеләү.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

1) Габдрахман Әпсәләмовның тормыш юлына һәм эшчәнлегенә караган материалны барлау, туплау, системалаштыру;

2) Сугыш темасына язылган хикәяләрен уку һәм анализлау.

Үз максатыма ирешү өчен, мин Г. Әпсәләмовның иҗатын өйрәндем, әсәрләрен укыдым, аның турында язылган газета – журнал мәкаләләренә күзәтү ясадым.

Теманы яктыртканда Г. Ахунов, Г. Мөхәммәдева хезмәтләре, Г. Әпсәләмовның үз әсәрләре файдаланылды.

Хезмәт кереш, төп өлеш, йомгаклау, кулланылган әдәбият бүлекләреннән тора.

Г. Әпсәләмов әсәрләрен өйрәнеп түбәндәге нәтиҗәләр ясадым. Язучы әдәбиятта Бөек Ватан сугышы чоры вакыйгаларына нигезләнеп яза. Һәрбер әсәрендә язучы кыю йөрәкле, батыр, үз тормышларын туган як, туган ил азатлыгы өчен кызганмый торган геройлар тасвирлый. Егерме беренче гасыр да яшәсәк тә: «Сугышларсыз гына яшәсәк иде киләсе елларда!» – дигән изге бер теләк уяна. Алдагы гасырларда яу кырында һәлак булган батырлар бөтенләй булмасын иде. Безгә, моңа кадәр булган каһарманнарыбызны данлап һәм хөрмәтләп, сабан тургайлы ямьле тормышта рәхәтләнеп гомер итәргә язсын иде!..

## *Әдәбиятта батырлык темасы*

***Гараева Эльвина,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 147 нче рус-татар урта ГББМ,*
*9 нчы сыйныф укучысы Җитәкчесе: Идиятуллина В. А.,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Абдулла Алишның илгә унбишләп шигыре күптәннән билгеле. Әмма А. Алиш тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләрнең болар белән генә чикләнмәве дә мәгълүм. Берлин төрмәсендә язган соңгы хатында бу турыда ул үзе дә әйтеп китә: «Бик күп уйланылган һәм язылган әсәрләр безнең белән мәңгелеккә китәләр.»[4, 35]

Шулай да әсирлектә булган кайбер кешеләр ятлап кайткан шигырьләр һәм истәлекләр аның тоткынлыктагы иҗатын тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. Шулар арасында Алиш белән бергә Польшадагы Седльце лагеренда булган Газыйм Кадыйров истәлекләре һәм ул тапшырган шигырьләр аерым әһәмияткә ия.

Кеше хәленә керә белү, башкалар турында кайгырту – Алиш характерының иң күркәм сыйфатларыннан берсе – тоткынлыкта аеруча ачык чагылган. Көрәштәш дусты Рәхим Саттар Берлиннан китәр алдыннан, ул, аның шигырьләрен үзенә алып калып, ышанычлы кулларга тапшырган. Билгеле булганча, бу шигырьләр туган илгә кайтып ирештеләр һәм аерым китап булып басылып чыктылар.

Без Алишны көрәшче, батыр кеше, Муса көрәштәше буларак хөрмәт итәбез. Эштән соң ул еш кына мәктәпләргә йөргән, аны күрү белән укучылар: «Әкият сөйли торган абый килгән», – дип, янына йөгерешеп килә торган булганнар, төрле сораулар биргәннәр, әкият сөйләткәннәр.

Әдәбиятка Алиш балалар язучысы булып керә һәм шушы өлкәдә тиз арада дан казана. Аның зурлар өчен язылган «Якты күл» повесте заманы өчен бик зур һәм җитди тема күтәргән һәм аны шактый уңышлы чишә алган әсәрләр рәтендә тора. Алишның бай һәм матур таланты бигрәк тә нәниләр өчен язылган әкиятләрдә тулысынча чагыла. Батырларыбызның күп булуы күңелле күренеш. Егерме беренче гасыр да яшәсәк тә: «Сугышларсыз гына яшәсәк иде киләсе елларда!» – дигән изге бер теләк уяна.

## *Историко-культурный проект «Вечная память»* *(по творчеству М. Джалиля, соратника А. Алиша)*

***Кадиров Булат,***
*ученик 8 класса,*
*МБОУ «Многопрофильная школа №181» г. Казани*
*Руководители: Кадирова Айгуль Фагимовна, учитель родного языка,*
*Кадиров Ринат Монирович, учитель истории*

Тема проекта, с одной стороны, веление времени информационных технологий, реализации проекта информатизации, с другой стороны, осознанная необходимость, ощущаемая творческим коллективом школы, работающим на протяжении последних лет в инновационном режиме.

Проект «ВЕЧНАЯ ПАМЯТЬ» предусматривает изучение истории города, республики, своих земляков, где реализуется мировоззренческая

направленность, рассматривается философские аспекты развития истории. Этот проект создания короткометражных анимационных фильмов с использованием исторического материала о настоящих героях раз-ных эпох, разных профессий, с разными судьбами. Это анимационные фильмы о тех, кто вопреки человеческой природе поставили на кон собственную жизнь ради спасения других. В своих повествованиях авторы проекта не только расскажут настоящие истории о героических людях и их поступках, но и попробуют ответить на сложные вопросы: Какова природа подвига? Почему только немногие из нас могут противостоять инстинкту самосохранения, рискуя собой ради других? И как работает механизм выбора значимости неочевидного результата действия и собственной жизни?

Цель проекта:

Формирование у подрастающего поколения любви и уважения к историческому и культурному наследию родного края на примере произведений выдающихся сынов Отечества (на примере М. Джалиля и его творчества).

Задачи:

• рассказать, «оживить» и показать подвиги героев, как литературных, так и реальных людей во время Великой Отечественной войны.

• Техническое и методическое изучение и организации проекта

Данный проект рассчитан на создание атмосферы заинтересованности в среде подростков к проблемам войн, к жизни участникам воинам-интернационалистам, нашим землякам.

**Ожидаемые результаты: -**

1. Обогащение содержания гражданско-патриотического воспитания в образовательно-воспитательном пространстве школы;

2. Развитие творческих способностей обучающихся;

3. Осознание ответственности за судьбу Родины, формирование гордости за сопричастность к деяниям предыдущих поколений;

4. Осознание обучающимися высших ценностей, идеалов, ориентиров, способность руководствоваться ими в практической деятельности.

**Успешность выполнения проекта обеспечивается:** заинтересованностью всех участников в совместном диалоге по обсуждению поставленных проектом вопросов.

**Вывод:** Любовь к Родине – это главное, составляющее патриотического воспитания, являющегося основным качеством нравственного стержня человека. Нам необходимо решать задачи первостепенной важности:

• формирование духовно-нравственных качеств личности;
• воспитание патриотизма;
• формирование толерантного отношения к миру;
• способствовать реализации индивидуальных, творческих, личностных и деловых качеств подрастающего поколения.

## *Сыртланова –батырлык үрнәге, милләт горурлыгы*

***Кашапова Зәмирә,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Фахрутдинова Г. М., Зарипова М. Г.*
*туган тел укытучылары*

Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы темасын чагылдырган язучылар бик күп. Безне Шамил Рәкыйпов иҗаты үзенә җәлеп итте, чөнки аның әсәрләре чын булган вакыйгаларга нигезләнгән, ягъни документаль әсәрләр. Ш. Рәкыйпов иҗатын яктыртырга алынуыбызның максаты:

1. Яшьтәшләремдә Бөек Ватан сугышын чагылдырган документаль әсәрләргә карата кызыксынуны арттыру;
2. Туган ил, туган җирнең, тыныч тормышның кадерен аңлау.

Ш. Рәкыйповның барлык әсәрләрендә дә диярлек геройлары яшәү белән үлем мәсьәләсе хәл ителгән мизгелдә сыналалар. «Кызлар-йолдызлар» һәм «Кипарислар җыры» әсәрендә очучы кызлар төн җиткән саен үлем белән күзгә-күз очрашып торалар. Бу повестьларда халыкның очучы батыр кызлары, безнең илгә басып кергән фашистларга каршы аяусыз сугышы, онытылмас батырлыклары күрсәтелә. Кыю һөҗүмнәре белән дошманга һәм аның сугыш техникасына сизелерлек зыян китергәне өчен гитлерчылар аларны «төнге убырлар»дип атыйлар. Повестьларның үзәгендә татар кызлары – хәрби очучылар, Советлар Союзы Геройлары Мәгүбә Сыртланова һәм Ольга Санфирова образлары тора. Повестьта сугыш уты эчендә кабынган һәм шунда ук сыналган мәхәббәт, олы дуслык хисләре дә киң урын ала. « Утта янып, суны кичкән мәхәббәт чыныккан корыч кебек була», – ди Мәгүбә Сыртланова дусты Ләйләгә. «Фронт сызыгы өстенә шомлы сугыш төне төшә. Менә түбәннән, җирне ялагандай, По-2 самолёты очып үтә. Ул немец ракеталарының нурларында бер генә секундка чагылып ала да, яңадан төн караңгылыгына кереп югала. «Бакчачы», безнең «бакчачы» оча! – ди аңа сугышчылар, сөеп. Чөнки ул һич

көтмәгәндә генә тырылдап, бакчалар арасыннан, карчыга сыман, немец траншеялары өстенә корыч, кургашын яудыра һәм, күз ачып йомган арада, беренче очраган тыкрык эченә кереп югала.

Батыр Мәгубә үзенең салкын канлылыгы, нинди авыр шартларда да каушамавы, куркынычның күзенә туры карый белүе, очуда кыюлыгы һәм осталыгы белән мактала. Аны иптәшләре дә: «Мәгубәдә Чкалов батырлыгы, Молотов төгәллеге бар», – дип бәяли

«Севастополь өчен барган сугышларның берсендә аның самолёты унике җирдән зарарланды, моторның бер цилиндры тишелде. Шулай да очучы Мәгубә Сыртланова һәм штурман Татьяна Сумарокова сөекле самолётын үз аэродромына алып кайтып җиткерде», – дип яза фронт газетасы.

Мәгубә – төнге очучы. «Төн караңгылыгы – минем ярдәмчем», ди ул. Аңа һаваның иң кыен шартларында: җилдә, яңгырда, томанлы төннәрдә дә сугышчан очышлар ясарга туры килә. Канатлы кошлар оча алмастай төннәрдә дә Мәгубә үзенә юл таба. Юлны гына түгел, картада кара нокта белән генә күрсәтелгән цельләрне дә таба. Татар халкының тугрылыклы кызы Мәгубә бөек Ватан өчен шулай сугыша...

Ш. Рәкыйповның «Кызлар– йолдызлар,»Кипарислар җыры» әсәрләрен өйрәнеп түбәндәге нәтиҗәләрне ясадым. Чынбарлыкта булган вакыйгаларны һәм реаль шәхесләрне чагылдыруы белән аның әсәрләре әдәбиятыбыз өчен кыйммәтле мирас. Әдип үзенең әсәрләрендә батырлык үрнәге күрсәткән халык вәкилләренең тулы канлы әдәби образларын тудыру, сәнгати чаралар ярдәмендә реаль каһарманнарның характерлары формалашуын, батырлыкка этәргән сәбәпләрнең социаль-психологик асылын эзлекле рәвештә ачыклауны максат итеп куя һәм куйган максатына тулысынча ирешә. Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» әсәрләрендә татар уллары һәм кызларының батырлыгын чагылдыру да күңелләрдә горурлык хисе уята

# *Хатларда йөрәк җылысы...*

**Нәҗмиев Рамазан,**
*Казан шәһәре Яңа Савин районы,*
*«Лицей-интернат №7»9 сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Гәрәева Ф. К.*

Без бүгенге көндә яңа технологияләр заманында яшибез. Тормышның һәр өлкәсенә информатизация килеп керә. Минутлар, секундлар эчендә үзеңә кирәк мәгълүматны табарга мөмкин. Шуның белән бергә киләчәк буынга, үзебезнең балаларыбызга, оныкларыбызга күп кенә әйберләрне, сүзләрне, хис-тойгыларыбызны белдерүдән мәхрүм дә без. Сүзләрем хатлар турында. Көн дәвамында кемнәргә нинди генә хатлар язсак та, алар киләчәкә бармаячаклар. Ни кызганыч?! Фәнни эшебезнең тема-сы – «Йөрәк каны белән...» Максатыбыз – әдипләребезнең хатлары аша алар турында күбрәк белү. Кулымда Рамил Сарчинның «Жизнь и судь- ба Фатиха Карима» дигән китап. Китапта мине аеруча шагыйрьнең ха- тыны Кадрия ханымга язган хатлары тетрәндерде. Никадәр сөю-ярату аларда! Әйтерсең, йөрәк каны белән язылганнар... Фатих Кәрим белән Кадрия ханымның мәхәббәт тарихы берәүне дә тетрәндерми калмас. Ф. Кәримнең язмышы гаять катлаулы була. Тормыш аны ерак Себергә, тайгаларга да илтеп сыный. Менә шундый авыр минутларда Фатих өчен күңел таянычы да, иң ышанычлы дусты да Кадрия ханым була. Ул ярат- кан кешесеннән йөз чөерми. Хат арты хат язып, үзенең аны азат итәр өчен нәрсәләр эшләвең, кайларга барып, кемнәрнең ишеген шакуын хәбәр итеп тора. Кадрия Ишукованың ышаныч, хөрмәт тулы хатларын укыгында, аның сабырлыгына, түземлелегенә исең китә. Бер үлемнеисән-сау кичеп, ялган яладан арына алган ирне ул тагын ут эченә – икенче үлемгә – сугышка ташлый. Кадрия ханым бер генә мизгелгә дә үзенең Фатихын сагынудан, аның кайтуына ышанудан туктамый. Иренә язган хатлары – йөрәгенең иң түреннән чыккан сагыш, аңа яратып дәшү,аны тынычландыру, өметләндерү ул. «Фатих, минем ике күземдәй якы- ным Фатих, сиңа синекедәй әрнүле йөрәктән чыккан сәламнәрем......
Син безне сагынасың, ә без сине синнән дә бигрәк сагынабыз шикелле». Ф. Кәрим дә һәр хатында диярлек ул гаиләсенең материаль ягын белешә, ягарга утын, өсләренә кияргә кием, ашарга ризык булу-булмау турында кайгыртып сорый.. Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Фатих Кәрим ту- ган илен сөюче патриот шагыйрь дә, гаилә җанлы эти дә, хатыны өчен сөя – сөелә белүче ир дә.

Хәсән Туфан белән Луиза Салиәскәрованың мәхәббәт тарихын белмәгән кеше юктыр. 1940 нчы елның 18 нче ноябрендә Хәсән Туфанны кулга алалар. 16 елга сузылган тоткынлык башлана. Мөмкинлек булу белән Луиза хатлар гына түгел, азык-төлек тә җибәрергә тырыша. Һәр хатында Хәсәнгә нык булырга, үзен якларга, көрәшергә әйди. «... Хәсән, хәлеңне Мәскәүгә яз. Кирәк булса, мин защитник алырмын. Гаепсезгә шунда яту – үзе бер булдыксызлык бит. Безнең өчен кайгырма, үзеңнең сәламәтлегеңне кара». Ниндидер могҗиза белән сакланып калган бу хатларның кыймммәте чагыштыргысыз. Аларда бөтен бер тарих, рәхимсез чорның тирән фаҗигасе чагыла.

Аяз Гыйләҗев белән Нәкыя ханымның да мәхәббәтләре хатлардан башланаКыз күңелен яулау җиңел түгел. Әгәр арада тимер чыбыклы, рәшәткәле озын-озак юллар-еллар булса, бигрәк тә... Иплəп-иплəп хыяллары хакында сөйли, кыз баланың күзен ачарга тырыша, үзенә башка караш ташлауны өмет итә ул... Өметләре бушка китми. Кыз егетне көтеп ала, бергәләп университетка укырга керәләр, тормыш сукмагын парлашып атлыйлар.

Әлбәттә, әдәбият дәресләрендә без әдипләрнең тормыш юлларын өйрәнәбез, иҗатларына күзәтү ясыйбыз. Ә менә бу шәхси хатларны укыгач, безнең күз алдында алар бөтен барлыклары, борчулары, кайгыхәсрәтләре белән тагын да тулырак ачылалар. Минем дә хатлар язасым килә... Ап-ак кәгазьгә каләм белән...

## *Мин – гуманист, сөям дөньяны...*
## *(Фатих Кәрим турында истәлекләр)*

***Сәләхетдинова Ралия,***
*Казан шәһәре Киров районы*
*182 нче политехник лицееның 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Хәева Фәнүзә Җәүдәт кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Быел Бөек Җиңүнең 75 еллыгы билгеләп үтелде. Россия Президенты Владимир Путин указы белән ул «Хәтер һәм дан елы» дип игълан ителде. Шуңа бәйле рәвештә Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган каһарман язучы, шагыйрьләребезне барлап, аларга дан җырлауны кирәк дип таптык.

Бөек Ватан сугышы бетәргә санаулы гына көннәр калгач, 1945 елның 19 февралендә Көнчыгыш Пруссия фронтында 36 яшендә батырларча

һәлак булган халкыбызның патриот шагыйре, катлаулы язмышлы шәхес Фатих Кәримнең батырлыгы һәм аянычлы язмышы турында искә төшерү, аңа дан җырлау безнең бурычыбыз дип саныйбыз. Бу язучы һәм аның шәхесе шактый өйрәнелгән, әмма аның рухи кичерешләре, тормышны чиксез яратуы һәм батырлыкка юл ярганда аңа көч биргән гаиләсе турында эзләнүләребез урынлы булыр дип ышанабыз.

**Тикшеренү предметы** булып шагыйрьнең гаиләсе – төпчек кызы Ләйлә апа истәлекләре һәм Фатих Кәримнең «Соңгы дәфтәр» дип исемләнгән Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулуга багышланган факсималь басмасы тора.

**Тикшеренү гипотезасы:** шагыйрьнең рухи кичерешләре, тормышны чиксез яратуы һәм батырлыкка юл ярганда аңа көч биргән гаиләсенең йогынтысы.

**Тикшеренү максаты:** Фатих Кәримнең язылып бетмәгән «Соңгы дәфтәр» дип исемләнгән факсималь басмасы белән танышу, аның гаҗәеп бай күңел дөньясын, кешелеккә булган чиксез мәхәббәтен ачарга тырышу.

Төрле чыганакларны барлау, Фатих ага Кәримнең төпчек кызы Ләйлә апаның әтисе турындагы истәлекләре безгә аның гаҗәеп бай күңел дөньясын, кешелеккә булган чиксез мәхәббәтен ачарга ярдәм итте. Ф. Кәрим иҗатының тәэсирлелеге татар укучысын гына түгел, дөнья халкын әсир иткәнлеген дәлилләдек.

Халкыбызның зур шагыйре, катлаулы язмышлы шәхес Фатих Кәримнең фронтта язган шигырьләрен туплап барган дәфтәре ул – «Соңгы дәфтәр». «Бу дәфтәрдә әтиемнең йөрәк җылысы сакланып калган кебек, чөнки ул аны үз куллары белән ясаган. Бу дәфтәрдә канлы сугышлар төсе, дары һәм янгыннар исе, чөнки ул әтиемнең куенында атакаларга барган», – дип язган Фатих Кәримнең төпчек кызы Ләйлә апа. Бик кадерле һәм истәлекле дәфтәр шагыйрьнең тууына 100 ел тулган көннәрдә факсималь басма рәвешендә укучыларга тәкъдим ителгән. 1943 ел дип күрсәткән автор һәм тәмамланмаган килеш өзелеп калган ул.

Фикерләп карасаң, соңгы булган һәрнәрсәнең кайдадыр башы да булган бит. Безнең күңелләрне тетрәндерә алган бу данлы шәхес һәм аның иҗаты нинди юллар үткән? Батырлыкның чишмә башы кайдан башлана? Әлеге сорауларга җавап эзләп карарга булдым.

Ни аяныч, 2020 нче елның 5 ноябрендә каһарман-шагыйрь Фатих Кәримнең кызы, әтисенең тормыш юлын, иҗатын өйрәнүгә, пропагандалауга, мирасын туплауга зур өлеш керткән Ләйлә Фатих кызы Кәримова арабыздан китеп барды. Татар җәмгыяте өчен тагын бер зур югалту булды бу.

# *Каһарман йөрәкле очучы кыз тормышта һәм әдәбиятта*

***Хәйретдинова Йолдыз,***
*Балтач урта ГББМ 9 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Хәйретдинова Г. М., Нигъмәтуллина Т. Х.*

Татар халкы кебек авыр сынауларга дучар ителгән бер генә халык та юк. Бөек Ватан сугышы халкыбызны яңа фаҗигаләргә дучар итте: бәхетле булырга туган йөз меңләгән ир-егетләрне кара гүргә кертте, җиләктәй кызларны мәңге тол калдырды. Сугышта барлыгы 2 миллион хатын-кыз катнаша. Шуларның 50 меңнән артыгы – Татарстаннан. Аларның 41 проценты – табиблар, 40 проценты – санинструкторлар һәм санитаркалар... Тамань хатын-кызлар авиация полкы очучылары арасында татар халкының курку белмәс атаклы кызлары Ольга Санфирова һәм Мәгубә Сыртланова да була. Мәгубә Сыртланова төнге бомбардировщик По-2 дә 780 сугышчан очыш ясый, дошман өстенә 140 тонна бомба ташлый, ә Ольга Санфирова исәбендә исә – 630 сугышчан очыш. 1942 нче ел ахырыннан 1944 нче елның декабренә кадәр Мәгубә командалык иткән эскадрилья 3270 сугышчан очыш ясый. Ул үзе генә дә дошманның 4 эшелонын, 6 елга кичүен, 12 танкын, йөк төягән 62 автомашинасын, 7 складын юкка чыгара. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен, аларның икесенә дә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

**Эшнең максаты һәм бурычлары**: батыр очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланованың тормыш юлы һәм Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары белән танышу, аның образы гәүдәләндерелгән әсәрләрне өйрәнү. Максатка ирешер өчен түбәндәге мәсьәләләрне ачыклау зарур:

1) Мәгубә Сыртлановага хас булган булган сыйфатларны ачу, Бөек Ватан сугышы тарихында ул күрсәткән батырлыклар белән танышу;

2) батыр очучы кыз М. Сыртланова образының әдәби әсәрләрдә сурәтләнүен өйрәнү.

Язучы Шамил Рәкыйпов «Кызлар-йолдызлар» (1973-1976) һәм аның дәвамы буларак язылган «Кипарислар җыры» (1976) әсәрләрендә сугыш елларында хатын-кызлардан гыйбарәт булган 46 нчы җиңел бомбардировщиклар полкының сугышчан батырлыклары турында яза. Бу очучы кызлар арасында 23 Советлар Союзы Герое, шул геройларның икесе татар кызлары була. Берсе – гүзәллеген берни белән дә чагыштырып булмый торган Ләйлә (Ольга) Санфирова, икенчесе – Мәгубә Сыртланова. Ш. Рәкыйпов бу әсәрләрендә батыр очучы кызларның безнең илгә басып

кергән явыз фашистларга каршы аяусыз көрәшен, онытылмас батырлыкларын җанлы вакыйгалар аша күрсәтә.

Ләбибә Ихсанованың «Лачын кыз» хикәясе дә – халкыбызның легендар кызы М. Сыртланова турындагы әсәр. Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис тә М. Сыртлановага багышлап «Кыз-лачын» исемле шигырен язган.

Мәгубәләр, Ләйләләр... Алар күпләр, алар миллионнар... Алар үз бурычларын тулысынча үтәделәр... Кеше күтәрә алмаслык зур михнәтләр кичергән, соңгы көчләрен биреп безнең азатлыгыбызны, бәйсезлегебезне һәм тормышның үзен яклап һәм саклап калган бу шәхесләргә карата без йөрәкләребездә тирән ихтирам һәм олы рәхмәт хисләре йөртәбез.

## *Фатих Кәримнең «Шомырт куагы» һәм «Кичке җыр» шигырьләрендә шомырт образының символик мәгънәсе*

***Харисова Эльвина,***
*8 класс укучысыКазан шәһәре МБГББУ «10 нчы гимназия»*
*Фәнни җитәкчеләре: Саляхова З. Г. филология фәннәре кандидаты,*
*Низамова Р. Р., туган (татар) тел укытучысы*

Фатих Кәрим шигырьләрендә үзенең хисләрен символлар ярдәмендә сурәтләргә ярата. Ә символ итеп табигать күренешләрен, агач– куакларны һәм чәчәкләрне ала.

Хезмәтебездә Ф. Кәримнең «Шомырт куагы» (1942) һәм «Кичке җыр» (1943) дигән ике генә шигырен карап үттек.

Минем фикеремчә, Ф. Кәрим иҗатының асылын өйрәнү, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләренең күп кырлы булуына игътибар итү бүген дә **актуаль** тема булып калуын дәвам итә. Шунлыктан әлеге темага мөрәҗәгать иттем.

Минем **максатым** әлеге шигырьләрдәге шомырт куагы һәм шомырт чәчәге образларының символик мәгънәсен табу һәм аның әсәрдәге әдәби – эстетик вазифасын ачыклау. Шул максаттан чыгып, үз алдыма шомырт образының символик мәгънәсен ачу белән бергә, аны бүгенге көн күзлегеннән чыгып аңлату **бурычын** куйдым.

«Шомырт куагы» шигырендә лирик геройның яраткан кешесе өчен кайгыру дәрәҗәсе шомырт куагы белән бәйләнештә яктыртыла. Лирик герой куакны яраткан кешесенең төсе булсын дип үстергән, ул үзенең хисләреннән ак чәчәкләр балкып торуын тели. Димәк, куак лирик

геройның мәхәббәте, хыялы буларак гәүдәләнә. Ф. Кәрим шигырендәге шомырт куагы аша сурәтләнгән мәхәббәт өмет, хыял белән бергә кушыла, шунлыктан шомырт өметне гәүдәләндерүче образ буларак та ачыла. Без шомырт куагын лирик геройның хыялын чагылдыра, – дидек. Ә куакның киселеп ташлавы аның хыялының, өметенең юкка чыгуы булыр иде. Шуңа да Ф. Кәрим шигырьне лирик геройның күңелендә сөйгәне белән кавышуга өмет чаткысы калдырып тәмамлый.

Димәк, шомырт куагы әсәрне тулысынча үзенә җыеп торучы образ буларак сурәтләнә. Ул борчылу нәтиҗәсен дә, мәхәббәт дәрәҗәсен дә, хыялны да чагылдыра.

Шомырт символын файдалану «Өй артында шомыртым бар», «Шомырт бәйләме» кебек татар халык җырларыннан ук килә. Шулай ук шомырт куагына карап, сөйгән ярын искә төшерү Шамил Маннаповның «Шомырт чәчәкләре хәтерле», соңрак Шәүкәт Галиевнең «Шомырт чәчәкләре ак кына» дигән шигырьләренә дә килеп керә.

«Кичке җыр» (1943) шигырендә дә Ф. Кәрим символ буларак шомырт куагын файдалана. Аерма шунда: алдагы шигырьдә шомырт әле чәчәк атмаган булса, биредә исә шомырт инде чәчәкләрен коя. Әдәбият белгече А. Яхин билгеләгәнчә, шомырт чәчәге, лирик геройның чәчәк кебек матур яшьлеге ул. Җил чәчәкне койган кебек, сугыш та геройның яшьлеген алган. Биредә шомырт чәчәкләре халкына тугрылыклы булып калган һәм аның азатлыгы хакына гомерен дә кызганмаган егетләргә бәя булып та килә. Ә талгын җилдә шомырт чәчәкләренең коелуы, сугышта илләрен саклап батырларча һәлак булган меңәрләгән яшь гомерләрне чагылдыра.

Без Ф. Кәримнең сугыш елларында иҗат иткән ике генә шигырен карап үттек. Шигырьләр сугыш турында булса да, анда сугыш вакыйга буларак сурәтләнми. Әсәрләрнең эчтәлеген өмет, хыял, сагыну, мәхәббәт һәм батырлык хисләре тәшкил итә. Әлеге хисләрне укучыга җиткезү өчен автор шомырт куагы һәм шомырт чәчәге образларыннан уңышлы файдалана.

## *Батырлык кыяфәттә түгел, йөрәктә*

***Шагиева Лэйсэн,***
*Сәламәтлек мөмкинекләре чикләнгән балалар өчен*
*4 нче Казан интернат-мәктәбе, 11нче сыйныф*
*Җитәкчеләре: Шайхутдинова Гөлфия Сахибетдин кызы, Саматова Фирая Газиз кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Нәрсә ул батырлык? Батырлык, минемчә, беренче чиратта мәхәббәт төшенчәсе белән бәйле. Әйе, чөнки бары тик туган илен, гаиләсен яраткан чын патриотлар гына үз иле өчен гомерен кызганмый, бары тик туган телен яратканнар гына аның азатлыгы, сафлыгы өчен көрәшә, бары тик тормышны яратканнар гына һәр көн саен физик һәм рухи авыртуларга карамыйча, яшәвен дәвам итә.

Әдәбиятыбызда батыр рухлы иҗатчылар шактый. Алар – үзләренең тормыш юлында бик күп сынауларга дучар булуларына карамастан, рухи югарылыкта кала алган кешеләр. Бары тик рухи яктан камил булган кеше генә иҗат итү сәләтенә ия дип уйлыйм. Мондый язучы һәм шагыйрьләр арасында мин татар әдәбиятында үзеннән соң тирән эз калдырган классик әдипләребез – Фатыйх Әмирхан һәм Фәнис Яруллинны әйтә алам. Бу шәхесләр физик мөмкинчелекләре чикләнгән булса да, рухи яктан сынмаган иҗатчылар. Аларның оптимистик рухта язылган әсәрләрен укыган чакта, үз-үзеңә булган ышаныч арта, шул әсәр геройлары кебек кыю, гадел һәм максатчан буласы килә башлый.

Безнең көннәрдә дә мондый көчле рухлы геройларны иҗат итүче язучылар бар. Шундыйларның берсе – Ландыш Әбүдарова. Язучының «Чуар тавык» хикәясендәге Алмаз исемле герое минем күңелдә аеруча матур хисләр уята. Алмаз кебек кыю һәм көчле рухлы кешеләргә мин сокланам, алардан үрнәк алам. Шул рәвешле, Ф. Әмирхан, Ф. Яруллин, Л. Әбүдарова биографиясе, иҗат сәхифәләре белән берникадәр танышканнан соң, түбәндәге нәтиҗәгә килдем: һәр иҗатчының стиле формалашуга аның үз тормыш тәҗрибәсе бик зур йогынты ясый икән. Бу шәхесләрнең иҗаты шуңа күрәдер дә тормышка чиксез мәхәббәт хисе белән сугарылган.

## «ӘКИЯТЛӘРДӘН ОЛЫ ТОРМЫШКА»

# *Яшь буынны тәрбияләүдә Абдулла Алиш иҗатының тоткан роле*

***Гарипов Данияз,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы*
*9 нчы гимназиянең 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе:Абитова Язилә Сәлим кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Башка кешеләр хәтердә саклаганда, вафатлар да яши, ди халык. Гасырлардан гасырга, буыннардан буынга күчә-күчә, халык хәтерендә кемнәрнең исеме саклана соң? Бу сорауга мин: «Әлбәттә, барыннан да бигрәк, Ватан иминлеген саклауда җанын кызганмаган, соңгы сулышына кадәр сөйгән халкына тугры калган олы җанлы каһарманнар» – дияр идем. Бу исемлеккә татар халкының бөек улы Абдулла Алишны кертер идем.

Кем соң ул Абдулла Алиш? Ни өчен без аны легендар шәхес дип атыйбыз? Абдулла Алиш – бөтен иҗади гомерен балаларга багышлаган күренекле язучы; матур-матур әкиятләр, шигырьләр язып, яшь буында батырлык, рухи матурлык, дуслык, хезмәт сөючәнлек тәрбияләүче педагог. Кулына корал алып, Бөек Ватан сугышында фашизмга каршы сугышкан, әсирлеккә эләккәч тә, дошманның оясында аңа каршы батыр көрәшкән ватанпәрвәр, каһарман.

Абдулла Алиш өчен иң кадерле, иң изге нәрсә – Туган ил, ә аның иң төп максаты – Ватанга хезмәт итү. 1941 нче елның июль аенда язучы фронтка китә. Ләкин ул 1941 нче елның 12 нче октябрендә, Брянск шәһәре янында чолганышта калып, фашистлар кулына әсирлеккә төшә. Фашистлар, әсирлеккә төшкән сугышчылардан махсус армия төзеп, аларны Ватанга каршы көрәшкә күтәрергә мәкер коралар. Ләкин сугышчылар, астыртын гына эш алып барып, аларның бу явыз ниятен җимереп ташлыйлар. Тик бер хыянәтче аркасында алар кулга алына, үлемгә хөкем ителә. Илгә, Ватанга хыянәт итү барәбәренә аның исән калу мөмкинлеге булган. Бик авыр шартларда да Абдулла Алиш фашизмга каршы көрәшен туктатмый, аларның ерткычлыгын фаш итә торган шигырьләр яза. «Үзем турында җыр» шигырендә ул, Ватанын сөюче солдат булып, туган иле өчен көрәшергә ант итә.

*Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,*
*Дөньяның иң рәхәт җиренә,*
*Әйтер идем: кирәк түгел, дип*
*Кайтам мин, дип, туган илемә.*

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: Абдулла Алишның әкиятләре тирән мәгънәле, балаларны дөрес юлга алып керә, балаларда уңай сыйфатлар тәрбияли, гаделлеккә, тугрылыкка өнди торган, өлкәннәр сүзен тыңларга, аларга хөрмәт белән карарга кушучы, өндәүче әкиятләр. Алар барысы да балаларга дөрес тәрбия бирү максатыннан чыгып язылганнар. Аларның һәрберсендә дә гыйбрәт алырлык аерым мисаллар күрсәтелә.

Аналар үзләренең балаларын бик яраталар. Алар балаларын хезмәт сөючән, Ватан өчен чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләргә тырышалар. Моның өчен уңай сыйфатлардан файдаланырга кирәк. Ләкин баланың үзендә дә кире сыйфатлар булырга мөмкин һәм аларны бетерү юллары төрлечә. Абдулла Алиш менә шушы тискәре сыйфатларның нәниләр өчен зур күңелсезлекләр тудыруын әкиятләрендә бик яхшы күрсәтә, андый тискәрелекләрне эшләмәскә кирәклеген аңлата.

## *Татар әдәбиятында әкиятче – Абдулла Алиш*

**_Гатина Зилә,_**
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*24 нче мәктәпнең 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Шәйхетдинова Люция Хәбир кызы,*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Әкият – ул бөек могҗиза. Ул – халыкның рухи хәзинәсе, күңел сафлыгы, хисләр матурлыгы, изге хыяллары, фикер үткенлеге, зирәклеге чагылышы. Балаларның рухи тормышында әкиятләр үзенчәлекле урын алып тора. Бу әсәрләр белән һәркем сабый чактан ук таныша. Аларны балаларга теле ачылгач та сөйли башлыйлар. Бүгенге катлаулы заманда әкиятләрдә булган табигыйлек, сафлык бала күңеле өчен бигрәк тә мөһим. Әкиятләрдә тормыш тәҗрибәсе, халык акылы, зирәклеге чагыла. Милли телләрне камилләштерүдә, балаларның рухын баетуда, кешеләрне танып-белүдә әкиятләрнең роле гаять зур. Әкият уйландыра, гыйбрәтләндерә, миһербанлылыкка, батырлыкка чакыра.

Бөек әкиятче Абдулла Алиш үзе дә кече яшьтән халык әкиятләрен тыңлап, укып үскән. Язучы бу турыда үзенең бер истәлегендә түбәндәгечә

искә ала: «Безнең күрше Әсма әби әкият сөйләргә ярата иде. Ә мин, үз чиратымда яратып тыңлаучыларның берсе идем. Йокыга китәр алдыннан әллә ничәшәр башлы юха еланнарның, соры бүреләрнең, алтыннан эшләнгән сарайларның тарихын, вакыйгаларын, маҗараларын тыңлый, әллә нинди уйларга батып бетә идем.»

Алишның әкиятләре төзелеше ягыннан җыйнак, уку өчен кызыклы, җиңел, музыкаль аһәңле, ритмлы, эчке рифмалар белән тулы. Алар-ны укып, һәркем я гыйбрәт ала, я чын күңеленнән соклана. Язучы-әкиятчебезнең күпсанлы әкиятләре гади, балаларга аңлаешлы тел белән язылган. Шул ук вакытта аларда ниндидер серлелек тә бар. Ә серлелек балаларны һәрвакыт үзенә тарта. Шуңа күрә дә бөек әкиятчебезнең китаплары кибет шүрлекләрендә тузан җыеп ятмый, укучыларны үз дөньясына тарта, мавыктыра, балаларда халкыбызның борынгыдан килгән асыл сыйфатларын – тырышлык, эшчәнлек, хезмәт сөючәнлек, ярдәмчел булу, һәр эшне җиренә җиткереп эшләү кебек сыйфатларын тәрбияли. Әкиятләре аша Алиш балаларны табигать һәм тормыш-көнкүреш шартлары белән таныштыра, кечкенәдән үк балада төрле матур гадәтләргә, ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү, гаделлек, намуслылык, батырлык, тыйнаклык һәм башка күркәм сыйфатларны булдырырга тырыша.

Балалар өчен табигатьтәге һәр күренеш – серле һәм кызыклы, һәрнәрсә – яңалык. Алиш әкиятләренең төп геройлары да – бөҗәкләр, кош-кортлар, җәнлекләр... Аның иҗатындагы табигатькә соклану, аңа мәхәббәт уяту табигатьне, мохитне саклау темасы белән бергә үрелеп бара. Ә бу проблема – хәзерге көндә иң актуале.

Үзенең якты әкиятләре белән яшь буында батырлык, гаделлек үрнәкләре, туган илебезгә, туган халкыбызга һәм туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли; бердәм, тату булырга чакыра, горурлык хисләре уята.

# *Җәвад Тәрҗемановның «Күбәләк-җилбәзәк» әкияте – олы тормышка өйрәтүче әсәр*

***Гыймалетдинова Алинә,***
*Казан шәһәре Киров районы*
*70 нче урта гомуми белем мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләре: Хафизова Гөлия Самат кызы,*
*Якубова Наилә Габдрахман кызы*

Җ. Тәрҗеманов – матур әдәбиятка мәктәп партасыннан килгән язучыларның берсе. Прозада язучы кыска хикәяләре һәм бигрәк тә әкиятләре белән таныла. Минем эшемнең темасы: **«Җәвад Тәрҗемановның «Күбәләк-җилбәзәк» әкияте – олы тормышка өйрәтүче әсәр». Максатым** – Җәвад Тәрҗемановның «Күбәләк-җилбәзәк» әкиятен өйрәнү һәм олы тормышка өйрәтүче әсәр булуын исбатлау.

Гадәттә әкиятләр «борын-борын заманда...» дип башлана. Җ. Тәрҗемановның «Күбәләк-Җилбәзәк» әкиятнең башламы да кабат- лау белән башланып китә: «Кара! Кара! Елга суы кояш нурлары һәмҗил белән шаяра.» Мондый башлам миндә, мәсәлән, кызыксыну уятты. Эзләнү орлыгын салды дисәм дә ялгыш булмас.

Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Бу әкияттә сүз хайваннар турында барса да, чынлыкта кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр сурәтләнә, икенче төрле әйтсәк, бу әсәрдә читләтеп әйтү, киная өстенлек алган.

Җәвад Тәрҗемановның «Күбәләк-җилбәзәк» әкияте – гаять тәрбияви, гыйбрәт алырлык, олы тормышка өйрәтүче әсәр. Анда без күңелгә үтеп керә торган итеп бирелгән тәрбияви моментлар белән очрашабыз. Әкият тәртипкә, тәрбиягә этәрә, кешелек сыйфатлары тәрбияләргә ярдәм итә.

Әкияттәге – күбәләкнең җилбәзәк булуы, аның бөҗәкләр белән сөйләшүе дә реаль тормыш, реаль чынбарлык күренешләренең, шулай ук кеше тормышының чагылышы булып тора.

Җ. Тәрҗеманов әкиятендә мәкаль булып йөрерлек сүзләр әйтә: «Эш сөймәс, әйткәнне белмәс», «Йөрмә җил куып, каршыла кышны күп хезмәт куеп», «Ялкауларга һәркем начар карый, эш беткәч кенә уйнарга ярый», «Ут белән шаярма, ялкын янына барма», «Уйный белмәгәч – уйнамаска кирәк».

Җ Тәрҗемановның бу әкияте тормышта җилбәзәк бусаң, ягъни җиңел холыклы, һәрнәрсәгә дә җиңел, өстән генә карасаң, һәрнәрсәнең ахы-

ры начар тәмамлануы мөмкин икәнлеген раслый. Автор күтәргән проблема бүгенге көндә дә актуаль. Мине бигрәк тә ул ут белән уйнауның күңелсезлек китереп чыгару мөмкинлеге әсир итте. Автор куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныш булырга да чакыра кебек. Җ Тәрҗеманов үзенең әкиятендә безгә, балаларга фикерләү күнекмәләре алырга җирлек бирә. Әкият ярдәмендә дөньяны акыл белән генә түгел, йөрәк белән дә танып белергә өйрәтә, тәрбия бирә.

## *Абдулла Алиш әкиятләрендә хайваннарның холкы, үзенчәлеге*

***Кәримова София,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*7 нче гимназиянең 5 нче Б сыйныфы укучысы*
*Җитәкчесе: Мөбарәкшина Г. Р.,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Күренекле балалар язучысы, курку белмәс Абдулла Алиш. Мин аның тормышы, иҗаты белән күптәннән таныш. Әле балалар бакча-сына йөргәндә үк әкиятләре белән таныша башладык. Алиш чыгышы буенча мулла нәселеннән. Әтисе Габделбари хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән, иген иккән, умарта тоткан, ә әнисе Газизә укымышлы, нечкә һәм шигъри күңелле ханым булып әдәбият тарихына кереп калган. Шушы тату, хезмәт сөючән гаиләдә үскән Абдулла бик зиһенле, акыллы малай булып үсә. Мәктәптә укыган елларында, А. Алиш фәннәрне яхшы үзләштерә, әдәбият түгәрәкләре, концертлар оештыра, стена газеталары чыгару кебек эшләрдә башлап йөрүче була, үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.

Бөек Ватан сугышында катнашып, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Муса Җәлил белән иңгә-иң торган, фашизмга каршы аяусыз көрәш алып барган унбер батыр арасында Абдулла Алиш аерым урын алып тора Ул төрмәдә шигырьләр иҗат иткән, шигырьләренең күбесе Туган илебезгә әйләнеп кайткан. Аның язмышы аянычлы. Ул да Җәлил белән бергә, 1944 елның августында фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә. Абдулла Алишның бөек, намуслы исеме халкыбызга кайтты. Ул антына тап төшермичә, дошман алдында тез түкмичә, авыр әсирлек шартларында да фашизмга каршы көрәште.

Тирән лирик кичерешләр белән сугарылган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр язарга рухи көч тапты.

Эшебез «Абдулла Алиш әкиятләрендә хайваннарның холкы, үзенчәлеге» дип атала. Эшебезнең **төп максаты** – А. Алишның «Чукмар белән Тукмар», «Сертотмас үрдәк», «Куян кызы» әкиятләрен анализлап, аларның мәгънәсенә төшенү; бу әкиятләрнең балалар күңеленә үтеп кереп, тормышта безгә күп сөйләмәскә, акыллы булырга, сер саклый белү өчен этәргеч булуын ассызыклау.

**Эшемнең актуальлеге:** А. Алиш әкиятләрендә хайваннарны, аларның холыкларын өйрәнү, бу әкиятләрнең әһәмиятен ачыклау. Бүгенге авыр заманда тәрбия чаралары иң актуаль проблема булып тора. Яшь буынны тәрбияләүдә зур өлешне әти-әниләр белән бергә, күренекле язучы – әдипләребез дә кертә. Алар үзләренең иҗади каләмнәре аша укучы күңеленә үтеп керергә омтылалар. Яраткан шагыйребез, фронтовик әдип – Абдулла Алиш нәкъ шундыйлардан.

Дәһшәтле сугыш елларында шигырь, хикәяләр яуга чыккан халыкның көрәш коралына әверелә. Шундый авыр шартларда да кешенең күнелен күтәрә алырлыкәсәрләр иҗат ителә. Шагыйрьләр ут-ялкыннарда бик тиз чыныга. Мин үземнең эшемдә балалар язучысы Абдулла Алиш эшчәнлегенә зур игътибар иттем, иҗатын, әкиятләрен өйрәндем.

Абдулла Алишның бөек, намуслы исеме халкыбызга кайтты. Ул антына тап төшермичә, дошман алдында тез түкмичә, авыр әсирлек шартларында да фашизмга каршы көрәште. Тирән лирик кичерешләр белән сугарылган әсәрләр, әкиятләр язарга рухи көч тапты.

## *Абдулла Алиш әкиятләрендә дуслык темасы*

***Мингазова Раилә,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*161 нче рус-татар мәктәбенең 5 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Галяутдинова Лариса Анатолий кызы*

Минем ин яраткан язучым – Абдулла Алиш. Ул балалар әдәбиятына зур өлеш керткән әдип. Фәнни эшебезнең максаты – Абдулла Алишның әкиятләрен өйрәнү, аларда дуслык темасының бирелешен тикшерү.

Язучының күп әкиятләрендә дуслык темасы алга куела. Абдулла Алиш якын дусларны көнкүреш шартларында сыный. Кечкенәдән үк бала характерында дуслык кагыйдәләрен формалаштыру бурычын куя. Аларда төрле күркәм сыйфатлар булдырырга тырыша.

«Чукмар белән Тукмар» әкиятендә ике этәчнең дуслыгы сурәтләнгән. Алар бер-берсеннән аерылгач кына дуслыкның кадерен белә башлыйлар. Абдулла Алиш дуслыкның кадерен белергә өйрәтә. Нинди генә вакыйгалар булса да көнләшмәскә, зарланмаска, сугышмаска өнди, дусларны беркайчан да рәнҗетергә ярамаганлыкны искәртә. Автор дусларсыз бик күңелсез икәнлеген дә тасвирлый.

«Бикбатыр белән Биккуркак» әкиятендә автор дуслар бер-берсенә ярдәм итәргә тиеш дигән фикерне җиткерә. Дуслык, барыннан да элек, ярдәм кирәк чакта, авырлыклар аша сынала. Янәшәдә якын дуслар булганда, безне бернинди каршылыклар куркытмый. Куркак куян белән батыр песи вакыйгасы аша дусларга авыр минутларда ярдәм кирәклекне искәртә.

«Сертотмас үрдәк» әкиятендә язучы дусларга хас булган сыйфатларны беренче урынга куя. Дусларның сер тота белмәүләре үзенә генә түгел, башкаларга да зыян китерә ала дигән фикергә басым ясый.

Автор кызыклы геройлар аша, балаларны тормыш-көнкүреш шартларында, дуслыкның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеге белән таныштыра. Кечкенәдән үк балаларда яхшы дус була алырлык сыйфатлар тәрбияли, начар сыйфатларны фаш итә. Гаделлек, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли.

## *Абдулла Алиш әкиятләрендә әхлак тәрбиясе*

***Мөхетдинов Марсель,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*175нче гимназиянең 5 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Хәкимова Мәдинә Сагидулловна*

Бүгенге көндә тәртипсезлек, кешелексезлек очракларын еш күрергә була. Бу мине бик борчый. Нишләргә соң? Мондый күңелсезлекләрне ничек юк итәргә? Моннан чыгуның нинди юллары бар? Мин таптым! Балаларга кечкенә яшьтән Абдулла Алиш әкиятләрен укырга кирәк. Чөнки язучының әкиятләре безне тәрбияли, яхшылыкка өйрәтә.

Әсәрләрендә сурәтләнгән хайваннар, кош-кортлар, бөҗәкләр образы аша Абдулла Алиш тырыш, кыю, батыр, акыллы, сизгер, зирәк, белемле, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кешелекле, тәртипле, сер саклый белүче, тыңлаучан булырга чакыра. Аның һәр әсәре тормышчан. Без, укучылар, аның геройларында үзебезне күрәбез.

Абдулла Алиш иҗаты бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Минемчә, аның әкиятләре бүгенге көн белән аваздаш. Алар хәзер дә матбугатта басылып килә. Аның әсәрләре бүген дә балалар кулында. Әкиятләре гади, аңлаешлы, серле, кызыклы язылган.

## *Татар фольклорында һәм Р. Миңнуллин иҗатында шүрәле образы*

***Нәбиуллина Ләйлә,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*«124 нче рус-татар гомуми урта*
*белем мәктәбе»нең 6Б сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Мөслимова Кадрия Усмановна,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Быел, ягъни, 2021 нче елда әсәр иҗат ителгәнгә 114 ел була. Димәк, инде бер гасырдан артык әлеге герой укучылар арасында. Бу безнең хезмәтнең актуальлеген тагын да арттыра. Татар мифологиясендәге популяр образ шүрәлегә беренче фәнни билгеләмә К. Насыйриның 1880 елда рус телендә басылган «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дип аталган хезмәтендә бирелгән. Шүрәле образы турындагы кызыклы фикерләр XX йөз урталарында фольклор һәм әдәбият галимнәренең фәнни хезмәтләрендә урын ала. Фольклорчылардан Х. Ярми, Л. Җамалетдинов, И. Надиров, С. Гыйләҗетдинов, әдәбият галимнәреннәнИ. Нуруллин, соңгырак елларда басылган хезмәтләрдән С. Шәмси,Г. Гыйльманов, Л. Минһаҗева, Л. Җамалиеваларның фәнни мәкаләләреннән Шүрәле турында мәгълүматлар алып була. Шүрәле исеме белән бәйле мифологик хикәятләр, чыннан да, татар халкында киң таралган. Татар халык иҗатының риваятьләр һәм легендалар томында әлеге тема белән бәйләнгән «Шүрәле», «Былтыр кысты», «Шүрәле Яппар», «Шүрәле каргаган авыл» һ. б. мифологик хикәятләр урнаштырылган. Шүрәлеләрне хәйлә яисә тапкырлык белән җиңгән батыр егетләр хакында мифлар, легендалар күп. Әлеге милли мифологик персонаж турындагы беренче әдәби әсәр ул, әлбәттә, Г. Тукайның 1907 елда иҗат ителгән «Шүрәле» поэмасы. Татар укучысының шүрәле хакындагы тәүге күзаллаулары шушы әсәр белән бәйле. Әсәрнең беренче басмасына Г. Тукай «Өмит юк түгел әле: ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып,

Шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кылып чыгарырлар» дигән юлларны язган. Шагыйрьнең бу өметләре тормышка ашты. Бүген Шүрәле образын сәнгатьнең бөтен төрләрендә очратырга мөмкин.

Ике меңенче еллар башында иҗат ителгән әсәрләрдән Р. Миннуллинның «Шүрәләләр турында, Малайлар турында, Тылсынчы бабай турында һәм тагын Шүрәләләр турында кечкенә экият»тә шүрәле образы шактый тулы тасвирлана. Әкиятләрнең кыска күләмлеләре шактый булса да, фольклорда «кечкенәкият» дигән төшенчә юк. Р. Миңнуллин иҗатының фольклор белән бәйләнешен ачыклауга махсус хезмәт багышлаган фольклор һәм әдәбият галиме Фатыйх Урманче «әлеге жанр төрен дә, исемен дә Р. Миңнуллин үзе иҗат иткән» дип саный. Аның кечкенәкиятләрендә халык әкиятләре яки фольклорның башка төрләре белән бәйле аерым мотивлар, сүз тезмәләре очраса да, тулысынча халык әкияте сюжетына нигезләнгән әсәрләр булмавын билгеләп үтә. Матур әдәбиятта туган шүрәле халык иҗатындагы мифологик персонаждан тышкы кыяфәте, вазифасы яганнан шактый аерылып тора. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрдә шүрәле, урман чикләреннән чыгып йөри, авылга, шәһәргә килә, кешеләр белән сөйләшә, аралаша. Кайбер әсәрләрдә шүрәлегә табигатьне саклау вазифасы йөкләтелә. Шулай ук Шүрәле әхлакый кыйммәтләрне саклаучы буларак та хезмәт итә. Шүрәлене матур итеп, милли герой итеп популярлаштырырга кирәк. Шүрәле образын киләчәктә мин балаларга китап, мульфильмнар аша гына түгел, популяр чит ил мультфильмнары геройлары кебек киемнәр, канцелярия товарлары, милли герой дәрәҗәсенә күтәрелер дип уйлыйм.

## *А. Алиш әкиятләреннән олы тормышка*

***Рәхимова Самира,***
*6 сыйныф укучысы «Арча икенче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ*
*Җитәкчесе: Зәбирова Эльмира Шәфигулла кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге көндә балаларны әкият аша тәрбияләү зур сабырлык, түземлек сорый. Мәктәп укучылары көн-төн телефонда утыра, гаджетлардан аерыла алмый. Ата-аналар балалар ничек итеп тәрбияләргә, укытырга белмиләр.

Бала тәрбияләү – үзеңә алмашка килүче яңа буын тәрбияләү. Тәрбиянең иң олы чаткысы, иң кирәклесе, нигез булып торучысы кечкенәдән башлана. Бала нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген белеп үсәргә тиеш.

Яшь буынны тәрбияләүдә әдәбият зур урын тота. Баланы ата-ана кечкенәдән үк әкиятләр, хикәяләр аша тәрбияли. Кечкенә сабыйны йоклатканда әниләре җырлар җырлый, әкиятләр сөйли. Һәр кешенең өендә китап, газета, журналлар бар. Гаилә белән шуларны уку, фикер алышу бик кирәк. Китаплар, бигрәк тә, әкиятләр монда зур роль уйный. Балаларга әкият геройлары бигрәк тә якын.

Язучыларыбыз үз укучылары рәтендә кечкенә дусларын да күрәселәре килә. Әкиятләр язу бик җиңел дип уйламыйм, чөнки монда автор баланы кызыксындырырга да, тәрбия бирергә дә тиеш бит. Без Абдулла Алишны да, Фәнис Яруллинны, Рафис Корбанны, Дәржия Аппакованың әкиятләрен яратып укыйбыз.

Эзләнү эшемә Абдулла Алиш әкиятләре аша чынбарлыкка күчүне өйрәнүне максат итеп куйдым. Кулымда 1991нче елны чыгарылган «Абдулла Алиш. Хикәяләр һәм әкиятләр» дигән китап. Бу китапка язучының хикәяләреннән тыш 20 әкияте кертелгән. Бурычым: әкиятләрне укып чыгу, геройлар аша язучының безгә җиткерергә теләгән фикерен ачыклау, әкиятләр тәрбиянең кайсы өлкәләренә карый икәнлеген билгеләү.

А. Алиш әкиятләре – балаларның яшь үзенчәлекләрен, психологиясенең бөтен нечкәлекләрен белеп язылган, сурәт һәм образларга бай, уку өчен җиңел әсәрләр. Тәнкыйтьче Гази Кашшаф, язучының әкиятләренә югары бәя бирә: «Яшьтә язылган – ташка язылган», – ди халык, ул җуелмый да, кырылмый да. А. Алишның нәниләр өчен әкиятләр иҗат итүе нәкъ шул принцинка нигезләнеп, кайгыртучан ана омтылышыннан чыгып язылганнар. А. Алиш та, түземлек белән баласына тәрбия бирүче ана кебек, баланың рухын сафландыра, күңелен нурландыра торган фикерләрне әкият теленә салып бирә».

Әкиятләрнең барысын да карап чыккач, шундый нәтиҗәгә киләсең: автор үз әкиятләрендә хезмәт тәрбиясе, әхлак тәрбиясе, физик тәрбия, экологик тәрбия, акыл тәрбиясе, культура тәрбиясенең көче зур икәнлегенә ишарә ясый. «Киң күңелле абыйның әкияттә түгел, тормышта дөрес яшәргә өйрәткән, ялгыш адымнардан кисәткән, оста һәм кинаялап әйткән ихлас киңәш-теләкләре бар», – ди шагыйребез Шәүкәт Галиев.

# *Абдулла Алиш – әкиятләр остасы*

***Хисамиева Адилә,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*175 нче гимназиянең 6 сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Габделвәлиева Р. Н., Гафарова Г. Г.,*
*туган тел укытучылары*

Минем бу эшемнең темасы – «Абдулла Алиш – әкиятләр остасы». Мин бу эшемне язар алдыннан Абдулла Алишның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүне үз алдыма максат итеп куйдым. Шушы максатыма ирешү өчен түбәндәге бурычлардан чыгып эш иттем:

1. Абдулла Алишның тормыш юлын өйрәнү.

2. Абдулла Алишның әкиятләре белән танышу, язучының әкиятләр остасы икәнен исбатлау.

Ни өчен мин үземнең эшемә бу теманы сайладым соң?

А. Алишның әкиятләре бай эчтәлекле һәм кызыклы. Аның иҗатын үсмерләр дә, яшьләр дә, өлкән буын да бик яратып укый. Ул үзенең әкиятләре, шигырьләре аша кешеләрдә бары тик уңай сыйфатлар гына тәрбияләргә тырыша. Аның әкиятләрендә яхшылык белән начарлык капма-каршы куела һәм һәрвакытта да яхшылык җиңеп чыга. Ул үзенең әкиятләрендә киң күңелле кешеләрнең гаделлеген, мәрхәмәтлелеген, гомумән, иң матур сыйфатларын күрсәткән. Язучының әкиятләре яшь буынны тәрбияләргә ярдәм итә, укучыларга туры юлны күрсәтә. Ни өчен Абдулла Алишның әкиятләрен барлык балалар да яратып укый соң? Бу сорауга җавап табу өчен мин Рафаэль Мостафинның «Өзелгән җыр эзеннән» китабы белән таныштым, Абдулла Алишның «Әкиятләр» китабын укыдым һәм үземнең хезмәтемдә файдаландым.

Укучыларны олы тормышка әзерләүдә әкиятләрнең роле бик зур, дип уйлыйм. Әкиятләр безне гадел, шәфкатьле, мәрхәмәтле, намуслы, эшчән булырга өйрәтәләр. Ә бу сыйфатларны үзеңдә булдыру өчен бик тырышырга кирәк. Менә шул вакытта А. Алишның әкиятләре безгә ярдәмгә килә дә инде

Укучылары Абдулла Алишны саф йөрәкле, талантлы балалар язучысы булганы өчен ихтирам итәләр. Без бүген аны Җәлилнең көрәштәше, изге җанлы, һәрвакыт ярдәмчел булганы өчен зурлыйбыз. Алишның бай һәм матур таланты бигрәк тә нәниләр өчен язылган әкиятләрендә тулысынча чагыла. Бу өлкәдә ул чыннан да тиңдәшсез. Аның әкиятләре әллә нинди, телдән бирелмәслек сихри көчкә ия. Аларны укып чыккач, ма-

тур һәм гади телле, кызыклы, бераз гына шаянрак, нәниләрне әдәпкә өйрәтүче мондый акыллы әкиятләрне Алиш кебек олы җанлы кеше генә яза алыр иде, дигән фикергә киләсең.

Абдулла Алиш әкиятләрен балачактан кем укымаган да кем аларга сокланмаган! Аның «Капкорсак патша», «Чуар тавык», Нечкәбил», Сертотмас үрдәк», «Каз белән аккош», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» һәм башка әкиятләре нәниләр өчен төсле китап булып басылып килә, төрле телләргә тәрҗемә ителә. Абдулла Алишның әкиятләре бай эчтәлекле, тематикасы ягыннан төрле һәм реаль тормышка якын булулары белән аерылып торалар. Аларда вакыйгалар мавыктыргыч, кызыклы сурәтләнә, тиз укыла һәм җиңел хәтердә кала. Шуның белән бергә, алар балаларга тәрбия бирүдә зур урын тоталар. Абдулла Алиш әкиятләренең күбесендә хайваннар һәм кошлар, бөҗәкләр дөньясы сурәтләнә. Ан- дагы хайваннар, кошлар, бөҗәкләр үзләренә хас табигый сыйфатлары белән бирелгәннәр, шулай ук аларда кеше характерында була торган үзенчәлекләрне дә күреп була. Бу нәрсә әкиятнең тәрбияви көчен үстерә, вакыйгалар һәм персонажлар турында фикер йөртеп, укучы үзе тиешле нәтиҗәне ясый ала. хайван һәм кош-кортларны да куркыныч астына куя.

## *Абдулла Алиш әкиятләре дөньясында*

***Ялалов Аяз,***
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*19 нчы гимназиянең 5 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Гимадиева Диләрә Шириязддановна,*
*туган тел укытучысы*

Әкият, әкиятче, әкияти дөнья... Бу сүзләрдә тылсым, сихри көч, зирәклек һәм тапкырлык, батырлык һәм башка сыйфатлар чагыла. Әкиятләр бик күптән яшәп, гомер итеп килә. Буыннан буынга, чордан чорга күчеп, сакланып, баеп тора бу жанр. Әкиятләр белән без сабый чактан ук таныш: аларны безгә газиз әниләребез, әбиләребез кич утырганда яки йоклар алдыннан сөйли.

Әкиятләр балаларны яхшылыкка, батырлыкка, кешелекле булырга, зирәклеккә, тапкыр булырга өйрәтәләр. Дөреслекнең һәрвакыт җиңәсенә ышанырга өндиләр.

Әкият диюгә күз алдына Абдулла Алишның берсеннән-берсе матур әкиятләре килә. Ни өчен Абдулла Алиш диярсез, сез? Чөнки, аның

әкиятләре бай эчтәлекле, тематик яктан төрле, тормышка якын булулары белән аерылып торалар. Аларда вакыйгалар мавыктыргыч, кызыклы сурәтләнә, тиз укыла һәм җиңел хәтердә кала.

Абдулла Алиш әкиятләрендә эш ярату, тырышлык, батырлык, тапкырлык, олыларның сүзен тыңлау, аларга хөрмәт белән карау, туган илне ярату, әгәр аңа дошманнар ташланса, туган ил өчен батырларча көрәшү, кирәк булса, шул изге көрәштә җаныңны да кызганмау аеруча калку итеп күрсәтелә. Язучы балаларны табигать дөньясын, җир-су үсемлекләр, ерткыч һәм йорт хайваннары, кошлар, җәнлекләр белән таныштыра, аларның әһәмияте, халык өчен файдалы яки файдасыз булуы турында кызыксынып укырлык итеп тасвирлый.

Абдулла Алиш әкиятләренең күбесендә хайваннар һәм кошлар, бөҗәкләр дөньясы сурәтләнә. Андагы хайваннар, кошлар, бөҗәкләр үзләренә хас табигый сыйфатлары белән бирелгәннәр, шулай ук аларда кеше характерында була торган үзенчәлекләрне дә күреп була. Бу әкиятнең тәрбияви көчен үстерә, вакыйгалар һәм персонажлар турында фикер йөртеп, укучы үзе тиешле нәтиҗәне ясый ала.

Абдулла Алиш еш кына әкият исемнәрен халыкның мәкаль-әйтемнәренә нигезләнеп куя. Мәсәлән, «Ялкаулык – хурлык, тырыш- лык – зурлык», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык», «Аерыл- ганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар». Бу әйтергә теләгән фикерне тагын да үтемлерәк итеп әйтергә ярдәм итә. Кешеләргә хас сыйфатлар- ны Алиш төрле җәнлекләргә, кош-кортларга күчерә, ләкин аларның да төп үзенчәлекләрен саклый. Шулай итеп, оста рәссам буларак, автор кош-корт, җәнлекләрнең хәтердә калырдай образын тудыра. Шуңа күрә баланың геройлар белән бергә шатлануы яисә бәхәскә керүе, сөйләшүе гаҗәп түгел.

Абдулла Алишның әсәрләре, бигрәк тә әкиятләре әхлакый нормалар бик еш алышынып торган бүгенге көндә бик актуаль булып кала. Аларны укып, һәркем я гыйбрәт ала, я чын күңеленнән соклана.

Язучы дөньяда аз гына яшәсә дә, үзенең гүзәл тормыш юлы, хезмәте, кешеләрне, балаларны, гомумән, тормышны яратуы белән кешеләр күңеленә нык кереп калды. Аның «иҗат җимешләре « әле дә безнең арада, үз халкына хезмәт итә, якты образы белән, бездә, яшь буында батырлык һәм гаделлек үрнәкләре, туган илебезгә һәм туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли.

# *Татар халык әкиятләре һәм Абдулла Алиш әкиятләре геройларының төп сыйфатлары*

***Ямбаева Асель,***
*Казан шәһәре 37нче гимназиясенең 5 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләре: Фәхретдинова А. Р., филология фәннәре кандидаты,*
*Денисова Г. Р., туган тел укытучысы*

Халык авыз иҗатында борынгылыгы, мавыктыргыч дөньясы, сюжетлары, композициясе һәм башка үзенчәлекләре белән аерылып торган әкият жанры бар. Ул татар халык иҗатында да киң урын алган. Моннан тыш, язучыларыбыз да әкият жанрына ятатып мөрәҗәгать итүе мәгълүм. Шундыйларның берсе – батыр язучы Абдулла Алиш.

Әкиятләрнең төп сурәтләү предметы – ул әкият геройлары. Шуңа күрә дә аларны өйрәнү аша әкиятләрнең идеясын аңларга була дип исәплим. Абдулла Алиш әкиятләрендәге образлар татар халык әкиятләрендәге образларга хас булган сыйфатларга ия. Бу үзенчәлек Абдулла Алиш әкиятләрен халык әкиятләренә якын итә. Язучы һәм татар халык әкиятләрендәге геройларны анализлау һәм үзара чагыштыру эшен актуаль дип саныйм.

Татар халык әкиятләре һәм Абдулла Алиш әкиятләре геройларын ачыклау, алар аша татар халкына хас милли үзенчәлекләрне билгеләүне фәнни-эзләнү эшемнең максаты итеп куйдым.

Татар халык әкиятләренең геройларына хас сыйфатлар бөек татар язучысы Абдулла Алиш әкиятләрендә дә чагылыш таба. Шуңа күрәдер дә аның әкиятләре бүгенге көндә дә яратылып укыла, мәктәпләрдә өйрәнелә. Мәсәлән, А. Алишның күренекле «Сертотмас Үрдәк» әкиятен алыйк. Әкиятнең төп герое – Үрдәк. «Кем көчле?» татар халык әкиятендәге сыман, А. Алиш әкиятендә дә Үрдәк мактану, авызында сүзен тотмау кебек сыйфатларга ия.

Язучының икенче бер әкияте – «Куян кызы» дип атала. Бу әкияттә төп герой – Куян баласы. Ул әнисен тыңламыйча, җылы оекбашларын салып ыргыткан һәм аннары авырган. А. Алиш әкиятендәге Куян образы «Ике кыз» татар халык әкиятендәге Куянны хәтерләтә.

А. Алишның «Койрыклар» әкиятендәге җәнлекләр образлары күп кенә Хайваннар турындагы татар халык әкиятләрендәге җәнлекләр образларына хас сыйфатларга ия. Мәсәлән: Төлке – хәйләкәр, Куян – куркак, Бүре – явыз, Песи – юаш, ялкау, Эт – тугры һ. б. Әлеге үзенчәлек А. Алишның иҗатын халык авыз иҗатына якын тота. Бу исә язучының татар халкының фольклор традицияләренә таянып эш итүе, ата-бабаларыбызның рухи мирасын хөрмәт итүе хакында сөйли.

Шул рәвешле, татар халык әкиятләрендә һәм А. Алиш әкиятләре геройларның бирелеше югары дәрәҗәдә ачык һәм аңлаешлы. Бу, бер яктан, әкият жанрының спецификасы белән бәйле: уңай һәм тискәре образларга, яхшы-яманга бүленеш күзгә бәреп тора. Һәм, әлбәттә, әсәр ахырында геройлар нәрсәгә лаеклы, шуңа ирешәләр.

## *Абдулла Алиш –әкиятләр патшасы*

***Алекперова Эмилия,***
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*МБГБУ «88 нче мәктәбе»4 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче:Кудряшова Альбина Зөфәр кызы*

Балаларны ярата, алар белән аралаша, алар белән сөйләшә, аларның телен, теләкләрен, дөньяга үзенчәлекле карашларын яхшы белә торган кеше ул Абдулла Алиш. Аның әкиятләрен яратып укымаган кеше юктыр бу дөньяда. Әкиятләрен укыган саен укыйсы гына килеп тора, чөнки алар кызык та, аңлаешлы да.

Абдулла Алиш кайда яшәгән? Кемнәр белән аралашкан? Алиш бабасы Тау ягының Шонгаты авылыннан булган. Аның улы Әлмәт, шуннан күчеп килеп, Әлмәт авылына нигез салган. Алишның әтисен Көек авылына мулла булып килгән, шунда өйләнгән. Бу гаиләдә бер-бер артлы балалар туа, ләкин озак яшәми үлә торалар. Догалар укып, Алладан сорап алган ир бала 1908 нче елның 15 нче сентябрендә Абдулла Алиш дөньяга килә. Абдулла бик кечкенәдән әкиятләрне, төрле мәзәкләрне ярата.

Абдулла Алиш әкиятләрендә эш ярату, тырышлык, батырлык, олыларның сүзен тыңлау, аларга хөрмәт белән карау, туган илне ярату, әгәр аңа дошманнар ташланса, туган ил өчен батырларча көрәшү аерата калку итеп күрсәтелә.

**Хезмәтемнең максаты** – Абдулла Алишның әкиятләрен тикшереп, аларда туган җир темасының бирелешен, геройларының характерлы сыйфатларын ачыклау. Бу максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне күтәрдем:

– әдипнең язган әкият китапларын барлау, аларны өйрәнү;

– аларга бәяләмә бирү, үз мөнәсәбәтемне ачыклау;

**өйрәнү объекты һәм предметы** – Абдулла Алиш китаплары

**Тикшерү методы** итеп әдәби анализ һәм бәяләмә алымнарын файдаландым.

# *Абдулла Алиш әкиятләренең тәрбияви әһәмияте*

***Базгутдинова Эльвина,***
*4 нче сыйныф укусысы Казан шәһәре Идел буе районының*
*186 нчы күп профильле лицее*
*Җитәкчеләре: Вәлиева Диләрә Дилбәр кызы,*
*Фазлыева Алсу Фәрит кызы*

**Теманың актуальлеге:** Татар әдәбияты дәресләрендә укучылар татар әдипләренең тормыш һәм иҗат юлы белән танышалар. Мәктәп укучыларына аеруча акыл һәм тәрбия бирүче жанр булып әкиятләр санала. Аларда тормыш тәҗрибәсе, халык акылы, зирәклеге чагыла. Җәмгыяттьтәге катлаулылык балалар тормышына да кагылмый калмый. Шуңа күрә татар әдәбиятына зур өлеш керткән А. Алишның әкиятләрен оста төзелгән тәрбия дәресләре буларак кабул итәргә кирәк. Чөнки аның әкиятләре укучыларны үз дөньясына тарта, мавыктыра, балаларда тырышлык, эшчәнлек, хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатларны тәрбияли. А. Алишның балаларны тәрбияләүгә юнәлтелгән әкиятләре әхлакый нормалар бик еш алышынып торган бүгенге җәмгыятьтә бик актуаль булып кала.

**Максат:** Абдулла Алиш әкиятләренең үзенчәлеген ачыклау.

**Бурычлар:**

– язучының тормыш һәм иҗат юлын яктырткан мәкаләләрне барлау;

– әдипнең балалар әдәбиятында тоткан урынын, әкият жанрын үстерүдәге ролен ачыклау;

– язучының әкиятләрен өйрәнү, аларның үзенчәлеген билгеләү;

– Абдулла Алиш иҗатының әһәмиятен һәм актуальлеген күрсәтү

**Тикшерү нәтиҗәләре:** Абдулла Алишның эшчәнлеген бөек әкиятче буларак тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланды:

1. Язучының һәрбер әкияте – могҗизалы, серле бер дөнья;
2. Ул балалар күңеленә үтеп кергән, аларның телен аңлаучы, балаларга тәрбия бирүче язучылардан.

**Гомуми нәтиҗә:**

А. Алиш әкиятләре фикер һәм фантазиягә бай, алар әлеге гадилек белән сюжет барышында тыгыз үреләү. Ләкин аларда коры үгет-нәсихәт юк, фикер әдәби чаралар, сурәт, образ, пейзаж ярдәмендә җиткерелә һәм әкиятләрнең уңышын билгели. Бу талантлы язучының тормыш юлы һәм иҗаты барыбыз өчен дә үрнәк.

**Рекомендация:** Әдәбиятта үз урыны булган Абдулла Алишның тормыш һәм иҗат юлы кыен шартларда үтсә дә, ул әкиятләре белән балалар-

га кызыклы, мавыктыргыч дөньяга юл ача. Әдәбият укытучыларына Абдулла Алишның балаларны тәрбияләүгә юнәлтелгән әкиятләрен өйрәтү аеруча мөһим.

## *А. Алиш әкиятләрендә тел-сурәтләү чараларын тикшерү*

***Березкин Ранель,***
*Казан шәһәре Вахитов районы*
*«Татар телендә белем бирүче 27 нче гимназия»ГБМУ*
*4 нче Б сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче:Костюнина Гөлнара Радик кызы*

Әкиятләр сөйләм телен үстерүгә ярдәм итәләр, алардагы чикләнмәгән хыял байлыгы яшь кешенең акыл зирәклеген арттыра, тормыштагы төрле хәлләрне бәяли белергә өйрәтә

Абдулла Алиш әкиятләрен укыган саен укыйсы гына килеп тора. Кызык та, аңлаешлы да язган ул әкиятләрен. Дәү әни мин йоклар алдыннан «Кем иң көчле», «Чуар тавык», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык», «Бал корты һәм шөпшә»әкиятләрен сөйли иде. Мин аларны бүгендә беләм, сыйныфташларым белән аралашканда һәрвакыт искә төшерәм. Бүгендә үземә үрнәк итеп әкияттәге «Бал кортын» алам, ул һәркөн эштә, тырыш. Миндә укуда үрнәк булырга телим, тырышып укырга, һәр эштә үрнәк булырга тырышам.

Алиш әкиятләре һәркемне сокландыра, укучыларны үз дөньясына тарта, мавыктыра, балаларда тырышлык, эшчәнлек, хезмәт сөючәнлек, ярдәмчел булу, һәр эшне җиренә җиткереп эшләү кебек сыйфатларны тәрбияли. Шуңа күрә дә әлеге иҗатны, әлеге әкиятләрне тирәнтен өйрәнү таләп ителә.

Проектның **актуальлеге** шуның белән билгеләнә.

Проект эшенең **максаты** – Абдулла Алиш әкиятләрен уку һәм тел-сурәтләү чараларын өйрәнү.

Күрсәтелгән максаттан чыгып, түбәндәге **бурычлар** куелды:

– Абдулла Алиш әкиятләрен уку һәм анализлау. ;

– Тел-сурәтләү чараларын аерып алу һәм төркемләү;

– Тикшеренү эшенә нәтиҗәләр ясау.

**Тикшерү материалы:** Абдулла Алиш әкиятләре.

**Проект эшенең структурасы** кереш, төп өлеш, йомгаклау һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

А. Алиш егерме әкиятендә дә тел-сурәтләү чараларын кулланган, әмма аларны бертигез кулланмаган. Ун әкиятендә синонимнарны һәм антонимнарны тигез файдаланган – 50 шәр % тәшкил итә. Чагыштыру чарасын да кулланган ул – 40 %. Ә менә сынландыру чарасын бик аз файдаланган ул нибары – 10% тәшкил итә.

Гомумән, Абдулла Алиш – балалар әдәбиятын үстерү юнәлешендә зур тырышлык куйган, төрле жанрларда эшләгән һәм татар әдәбиятында югалмас эз калдырган әдип.

## *Мактану ул һәркемне хур итә, тыйнак булуга җитә!*

***Гатиятуллина Асилә, Иванов Сергей***

*Казан шәһәре Яңа Савин районы ГБМБУ»103нче мәктәп»*

*4нче сыйныф укучылары*

Абдулла Алиш әкиятләре безгә балалар бакчасыннан ук таныш иде. Гаҗәп матур шигъри телдә язылган бу әкиятләре аша Абдулла Алиш безне табигать дөньясына алып керә, җәнлекләр, кош-кортлар белән аралаштыра, тормыш-көнкүреш детальләре белән таныштыра. Безне төрле матур гадәтләргә, хезмәткә өйрәтү, гаделлек, намуслык, батырлык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатларны тәрбияләүне күздә тота. Шуңа күрә башлангыч сыйныфларда аның әкиятләрен, хикәяләрен яратып укыйбыз. Без Абдулла Алишның «Мактанчык чыпчык белән Тыйнак сыерчык»әкиятен укыдык. Бу әкият безне уйланырга мәҗбүр итте. Шул максат белән, эзләнү эшенә керештек.

Фәнни-эзләнү эшебезнең максаты: Абдулла Алишның тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк өйрәнү.» Мактанчык чыпчык белән Тыйнак сыерчык « әкияте белән танышу, әкият геройларының характерлы сыйфатларын ачыклау, алардан үрнәк һәм сабак алу.

Максатыбызга ирешү өчен, түбәндәге бурычларны куйдык: – әдипнең язган әкият китапларын барлау, аларны өйрәнү; – аларга бәяләмә бирү, үз мөнәсәбәтебезне ачыклау; – сыйныфташларыбыз алдында чыгыш ясап, Абдулла Алиш әсәрләрен таныту. Безнең уйлавыбызча, сайлаган темабыз бүгенге көндә дә бик актуаль.

«Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә!» Әйе, безнең арабызда да мактанчык кешеләр еш очрый. Мактану бит ул – урынсызга үз-үзеңне яки берәр эшеңне мактау, булмаганны арттырып сөйләү, шапырыну, масаю. Кайбер укучылар үзләренең матур киемнәре, телефоннары, юк кына эш-гамәлләре белән сөйләнеп йөрергә генә яраталар. Югыйсә, мактанчык кешеләрне беркем дә яратмый. Шуның өчен чыпчыкның тискәре сыйфатлары безгә дә ошамады. Чынлап та, мактану бит ул һәркемне хур итә!

Тыйнак булуга ни җитә?! Тыйнаклык бит ул кешеләрне бизи. Тыйнак кешеләр олыларга да, кечеләргә дә хөрмәт белән карыйлар, бервакытта да эшләгән эшләре белән масаймыйлар, матур, ягымлы итеп сөйләшәләр. Әби-бабайларыбыз да безгә тыйнаклык турында бик күп мәкальләр әйтеп калдырганнар:Тыйнакның кулы эшләр, мактанчыкның теле эшләр. Үз-үзеңне мактама, синнән акыллылар да бардыр. Үз-үзен мактаган – агач атка атланган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсебез килә:беркайчан да мактанырга ярамый. Әкият безгә «тыйнак сыерчыклар»дан үрнәк, ә «мактанчык чыпчык»тан гыйбрәт алырга ярдәм итте.

## *Абдулла Алиш әкиятләрендә сөйләм әдәбе үрнәкләре*

**_Сөнгатуллин Эмиль,_**
*Казан шәһәре Киров районы*
*«ХПБУ –67нче мәктәп»нең 4 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләре: Шәймәрдәнова Гүзәлия Әсхәт кызы,*
*Дәүлиева Нина Павел кызы*

Җәмгыятьтә яшәүче һәр кеше билгеле бер кануннарны үтәргә тиеш. Нәкъ шул кануннар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйли, төрле тәртипсезлекләргә юл куйдырмый, дип беләбез.

Адәм балалары алдында торган иҗтимагый таләпләрнең берсе – бер-береңне хөрмәт итү, аңларга тырышу, үзара әдәпле булу. Әдәпле булуның тиешле нормалары һәм кагыйдәләре кабул ителгән. Җәмгыятьтә кешеләр матур, үзара аңлашып һәм килешеп яшәү максатыннан уйланылган бу кагыйдәләрне этикет өйрәнә. Этикет (француз сүзе «**étiquette**»– этикетка) – теге яки бу җәмгыятьтә кешеләрнең үз-үзләрен тиешенчә тотуының кабул ителгән билгеле бер тәртибе, кагыйдәсе. Без мәктәптә, озынайтылган көн төркемендә, этикет кагыйдәләрен өйрәнәбез һәм бу тема миңа

бик якын булып тора. Кешенең әдәпле булуы аның теленнән күренә. Без барыбыз да тәмле телле булырга тиеш. Сайланган темабызның актуальлеге нәкъ боларда чагыла.

Сөйләм әдәбе – тәрбия әлифбасының беренче хәрефе ул, әдәпле булуның беренче күрсәткече. Безнең тәрбияле бала булуда – әдәбият зур урын алып тора. Безне әти-әни кечкенәдән үк әкиятләр, хикәяләр аша тәрбияли. Кечкенәләрне йоклатканда, әниләр җырлар җырлый, әкиятләр сөйли, төрле китаплар укый.

Фәнни-гамәли эшемне «Абдулла Алиш әкиятләрендә сөйләм әдәбе үрнәкләре» дип атадым. Тикшерену эшебезнең гипотезасы – Абдулла Алиш әкиятләре аша укучылар сөйләм әдәбе формаларын үзләштерәләр.

Тикшерү эшебезнең максатлары түбәндәгеләр:

– Абдулла Алишның балалар әдәбиятына керткән өлешен тикшерү;

– аның әкиятләрендә әдәпле сүзләрне барлау;

– «Уку китабы» дәреслекләре тәкъдим иткән әдәпле сүзләрне табу;

Билгеләнгән максатларга ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

– әкиятләрне укып чыгу, геройлар аша язучының безгә җиткерергә теләгән фикерен ачыклау;

– рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен тәкъдим ителгән «Уку китабы» (1– 4 сыйныфлар) дәреслекләренә күзәтү ясау;

– дәреслекләрдәге әдәпле сүзләрне өйрәнү, анализлау;

– аталган бурычлардан нәтиҗә чыгарып, йомгак ясау.

Тикшерену эшебезнең **өйрәнү объекты –** Абдулла Алиш әкиятләре һәм хикәяләре; **өйрәнү предметы** – аның әкиятләрендә урын алган әдәпле сүзләр.

Безнең телебездә әдәпле сүзләр бик күп. Кешеләргә шундый әдәпле сүзләр генә әйтик, авыр сүзләр әйтеп аларны рәнҗетмик. Тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Ә матур сүз әйтсәң, күңелгә рәхәт була. Ашый торгач, тәмле әйбер бетә, ә тәмле сүзне күпме генә кабатласаң да, кадере бетми.

Тикшерену эшебезнең гипотезасы дәлилләнде дип әйтә алабыз. Алиш әкиятләрендә сөйләм этикетының барлык очракларына да мисаллар табып булуын раcладык. Язучы үзенең укучыларын матур булырга, сөйләгәндә әдәпле сүзләр кулланырга өйрәтә, әкият геройлары аша балаларны тәрбияли.

Кешенең тышкы кыяфәте дә, сөйләме дә, үз-үзен тотышы да, уйлары да матур булырга тиеш. Матур, тәрбияле булыйк, дуслар!

# *Абдулла Алиш – әкиятләр остасы*

***Кадырова Асия,***
*Казан шәһәре Идел буе 6 нчы гимназиянең 4 д сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкчеләре: Закирова М. З., Гильманова Э. Х.*

Абдулла Алиш балалар язучысы. Ул балалар күңеленә үтеп керә алган, аларның телен аңлаучы, балаларга тәрбия бирүче язучы булган. « Абдулла Алиш – әкиятләр остасы « дип исемләнгән фәнни-тикшеренү эше чыганагы – А. Алиш иҗат иткән әкиятләр. Аларның һәрберсенең төп үзенчәлеге тәрбияви кыйммәткә ия булуда. Эшнең максаты – А. Алиш әкиятләренең тәрбияви кыйммәтен өйрәнү.

Абдулла Алиш әкиятләрендә эш ярату, тырышлык, батырлык, тапкырлык, олыларның сүзен тыңлау, аларга хөрмәт белән карау, әдәплелек күрсәтелә. Язучы балаларны табигать дөньясы, җир-су, үсемлекләр, ерткыч һәм йорт хайваннары, кошлар, җәнлекләр белән таныштыра. Аның әкиятләре балаларда танып белү сәләтен үстерә.

Аның әкиятләренең төп идеясы тәрбияви көчкә ия. Әсәрдә катнашкан персонажларның үз-үзләрен тотышында, эш-гамәлләрендә, сөйләшүләрендә, тәрбиялелек яисә, киресенчә, тәрбиясезлек сыйфатлары ачык чагыла. Абдулла Алишның әкиятләре бала күңелен белеп һәм нәрсә яратуларын аңлап язылган. Алишның әкиятләре сихри көчкә ия. Аларны укып чыккач, матур һәм гади телле, кызыклы, бераз гына шаянрак, нәниләрне әдәпкә өйрәтүче мондый акыллы әкиятләрне Алиш кебек олы җанлы кеше генә яза алыр иде, дигән фикергә киләсең. «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык» әкияте балаларны бал корты кебек тырыш, эш сөючән итеп тәрбияләргә ярдәм итсә, «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык» тыйнаклыкка, әдәплелеккә өстенлек бирә. «Чукмар белән Тукмар» әкияте балаларны татулыкка өйрәтә.

# *Әкиятләрдән олы тормышка*

***Туктаров Саид,***
*«Адымнар – Казан – белем һәм татулыкка*
*юл полилингваль комплексы» дәүләт автономияле ГББУ,*
*4 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе:Дәүләтшина Ильмира Габделәхәт кызы*

Мин нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген белеп үстем. Әле дә хәтерлим, һәр көнне кичен мине йокларга салганда әнием кулына китап ала иде. «Син, балам, мин укыганны бик игътибар белән тыңла. Күзләреңне йомгач, әкият геройларын күз алдыңа китер», – дия иде. Менә шуннан башлана иде инде... алар белән сөйләшәм, аларны оры- шам. Әкиятнең эчтәлеген үзгәртәм, узем дә чактан гына әкиятче булып китмәдем.

Гаиләбез китапханәсендә бик күп китаплар тупланган безнең. Еш кына шулар арасыннан Абдулла Алиш әкиятләрен кулыма алам, аларны укырга бик яратам. Сыйныфташларыма, дусларыма да укырга тәкъдим итәм.

Күптән түгел укытучыбыз безне республика китапханәсенә экскурсиягә алып барды. Кулыма 1991 нче елны чыгарылган «Абдулла Алиш. Хикәяләр һәм әкиятләр» дигән китапны алдым. Бу китапка язучының хикәяләреннән тыш 20 әкияте кертелгән. Минем теләгем: әкиятләрне укып чыгу, геройлар аша язучының безгә җиткерергә теләгән фикерләрен ачыклау, әкиятләре аша безгә нинди тәрбия бирергә теләгәнен билгеләү. Менә ул көн килеп җитте, ниһаять мин китапны тулысы белән укып чыктым. Сезгә дә укырга тәкъдим итәм!

Укыган барлык әсәрләрдә дә төрле вакыйгаларга төп фикерләр салына, нәтиҗәдә, гади генә күренгән деталь дә зур мәгънәгә, көчкә ия бу- лып чыга. Реаль тормыш әкияти күренешләр белән бергә үрелеп китүе, шигъри тел, ритм һәм аерым үзенчәлекләр Абдулла Алишның сюжет һәм композиция төзүдә генә түгел, гомуми оста булуын билгели.

Әкиятләр балаларга күп белем бирә, аларны тәрбияли. Әти – әниләр кечкенә балаларга, ә укучылар үзләре укысыннар иде бу әкиятләрне.

# *Резидә Вәлиева әкиятләрендә батырлык темасы*

***Хусаинов Ильназ,***
*Казан шәһәре Киров районы*
*МБГБУ «32 нче мәктәбе» 4 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Тимершина Сания Госман кызы,*
*Хәйдәрова Энҗе Якубкызы*

Р. Вәлиеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксыну мине фәнни-эзләнү эшенә этәрде. Ул– татар әдәбиятын баетуга зур көч керткән шагыйрә.

Әкиятләре аша автор балаларны табигать белән таныштыра, аларда тырышлык, ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү, гаделлек, намуслылык, батырлык, тыйнаклык сыйфатлары тәрбияли.

Хезмәтемнең объекты – Резеда Вәлиева эшчәнлеге. Предметы – Р. Вәлиеваның батырлык темасын яктырткан әкиятләре.

Фәнни эшемне язганда түбәндәге максатны куйдым:

– күренекле шагыйрә Резеда Вәлиеваның шигъри әкиятләрен уку һәм геройларының батырлыкларын билгеләү.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

1) Резеда Вәлиеваның тормыш юлына һәм эшчәнлегенә караган материалны барлау;

2) Батырлык темасы белән бәйле шигъри әкиятләрен уку һәм анализлау.

Фәнни-эзләнү эшебез кереште́н, төп бүлектән, йомгак һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Р. Вәлиева балаларны туган җирләрен якларга әзер булырга, авырлыклар алдында куркып калмыйча, батыр булырга өйрәтә. Батырлыкны күмәк эшләп тә булуын күрсәтә, кайчакта батырлык эшләр өчен хәйлә, тапкырлыкны да эшкә җигәргә кирәклеген ассызыклый.

Р. Вәлиева әсәрләре А. Алиш әсәрләре кебек үк аерым шәхесне тәрбияләүне генә күздә тотмый, ул гомумкешелек тәрбия мәсьәләләрен алга куя. Әсәрләрендә сурәтләнгән геройлар, хайваннар, кош-кортлар, бөҗәкләр образы аша ул кыю, батыр, акыллы, сизгер, зирәк, белем-ле, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кешелекле, тәртипле, тыңлаучан булырга өйрәтә, шул тормышта ничек яшәргә, ничек үз урыныңны таба белергә төшендерә, рухи азык бирә.

# ТУГАН ТЕЛ УКЫТУНЫҢ ПРОБЛЕМАЛАРЫҺӘМ ҮСТЕРҮ ЮЛЛАРЫ

## *Тел язмышы – милләт язмышы*

***Абитова Я. С.,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы 9нчы гимназиянең туган(татар) тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Җамалиева Т. С., Питрәч районы Сафин Ф. Ә. исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган(татар) тел һәм әдәбияты укытучысы*

Татарстан Республикасында төрле телләрдә сөйләшүче халыклар бердәм, тату, бер-берсен аңлап яшәсәләр, һәр милләтнең гореф-гадәтләре, мәдәниятләре алга китсә, димәк, бу халыкның киләчәге бар дигән сүз.

Иң беренче чиратта, һәр милләт кешесенең үз теле, язмышы өчен борчылу, аны саклау –иң изге бурычларның берсе. Һәр ата-ана баласын туган теле белән таныштырырга, шул телне бала күңеленә сеңдерергә бурычлы. Аннан соң гаиләдә телгә карата мәхәббәт уяту, аны яшәү коралына әверелдерү бик мөһим. Тел гаиләдә сакланып калсын өчен, әти-әни үзара балалары белән бары тик туган телдә аралашырга, туган телнең матурлыгын күрсәтә белергә, аны кадерләп сакларга кирәклеген, тирән мәгънәсен тоемларга өйрәтергә тиеш.

Ана теле – йөрәк теле, нәсел теле, рухи тамыр. Һәр милләт, һәр кеше үз телен сакларга, якларга тиеш. Әгәр дә халык үз ана телен саклмаса, ул халык, милләт булып яшәүдән туктый. Бу хакта К. Ушинский : *«Халык сөйләмендә тел яшәсә, халык үзе яши, халык сөйләмендә тел үлдеме, тел иясе буларак, халык үзе үлә»,* – дип язып калдырган.

Балалар бакчасында, мәктәп һәм башка уку йортларында да тел укытылырга һәм тәрбия чаралары татар телендә алып барылырга тиеш дип саныйм. Моннан чыгып, шул аңлашыла: телне дәүләти дәрәҗәгә күтәрергә кирәк, дәүләт, җитәкчеләр шул телдә аралашырга тиеш. Кызганычка каршы, бу эш әле тулысынча башкарылмый.

Икенчедән, рус мохитендәге милләттәшләремнең ана телләрендә сөйләшмәүләре мине бик нык борчый. Авылдан килгән яшьләр тиз генә рус телен үз итәләр.

Өченчедән, һәрбер ата-ана гаиләдә балалары белән туган телдә сөйләшергә тиеш. Әгәр дә татар телебезне балага гаиләдә сеңдермибез

икән, ул вакытта инде без телсез калачакбыз. Әти-әниләрнең төп бурычы – баласына телне өйрәтү. Ә шушы бурыч төгәл үтәлмәсә, димәк, милләт алдындагы изге бурычы үтәлмәде дигән сүз. Әгәр дә һәрбер кеше шушы эшләрне төгәл башкарса, телебез һичшиксез дәрәҗәле телгә әвереләчәк.

Дүртенчедән, һәрбер татар кешесендә милләтпәрвәрлек, горурлык, җаваплылык булырга тиеш. Ул кулыннан килгәнен эшләп, үз милли язмышын үзе хәл итәргә хаклы.

Бездә татар теленә ихтыяҗ житеп бетми. Телне белү кирәклеге һәрвакыт һәм һәр җирдә күзәтелергә тиеш. Элмә такталар, белдерүләр, эш кәгазьләре рус телендә языла. Төрле тармакларда эшләүче белгечләр һәрвакыт урыс телендә аралаша, шуның аркасында телнең әһәмияте югала һәм бу гадәти хәлгә әйләнеп бара. Гомумән алганда, татар теленә ихтыяҗ булмаса, телне өйрәнү, саклау дигән фикеребез үз көчен югалтырга мөмкин.

Дөрестән дә, хәзер татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды, укытучы алдында җаваплылык артты. Укытучы үз дәресен бала яратырлык һәм теләп өйрәнерлек итеп оештырырга, дәрестә заманча технологияләр кулланып эш итәргә тиеш.

Икетеллелек шартларында телне саклап калу өченкоммуникатив технологияләр куллану татар телен, аның культурасын, татар халкының тарихын өйрәнүдә зур мөмкинлекләр ача. Бу технологияне куллану укучыларда фән белән чынлап торып кызыксыну уята.

Укыту процессында инновацион технологияләрне куллану –белем бирү сыйфатын күтәрүдә бик нәтиҗәле чара булып тора. Алар укучыда кызыксыну, материалны тирәнрәк үзләштерү теләге уята.

Бүгенге көндә укучылар матур әдәбият әсәрләрен бик аз укыйлар. Алар күбрәк интернетта утыралар. Ләкин әдәби әсәрнең телен, анда яткан тирән фикернең мәгънәсен аңларга бары укытучы гына булыша, кызыксындыру уята һәм дөрес юнәлеш бирә ала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: тел өйрәнү өчен, иң беренче чиратта, укучының теләге булу шарт. Әгәр дә укытучы дәрестә уңай психологик халәт тудыра алса, нәтиҗәле эш алымнары кулланса, ул һичшиксез зур уңышка ирешәчәк.

## *Укыту һәм тәрбиянең заманча педагогик технологияләре*

***Афзалова Гөлназ Җәүдәт кызы,***
*МБГББУ ТР Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа УГББМ*

*«Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр».*
Р. Фәхреддин

Татар теле дәрес буларак укытыла башлаганнан бирле (XVIII гасырда Сәгыйть Хәлфин эшчәнлеге белән бәйле) һәр чор укытучылары һәм методистлары укытуны камилләштерү ысул һәм алымнарын булдырырга тырышканнар. Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Бу укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш – үзгәрешне тәэмин итә. Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп эшли белергә дә тиеш.

Дөньяның данлыклы «ABBYY» компаниясе яңа Lingvo электрон сүзлеген чыгарды. Инглиз, испан, алман, итальян, кытай, төрек һ. б. телләр белән беррәттән татарчасы да бар. Монда 12 телдәге 154 сүзлек кергән. Нигездә, урысча-инглизчә, французча-урысча һ. б. аңлатма, профессиональ, төзелеш, медицина, информатика өлкәләренә кагылышлы сүзлекләр кулланылган. Яңа электрон сүзлек нинди мөмкинлекләр бирә соң? Иң мөһиме – бу кул астында зур китапханә дигән сүз. Татар сүзенең рус теленә коры тәрҗемәсе генә бирелми монда. Нинди формада булуына карамастан, башка телләрдә аның тәрҗемәсен карарга мөмкин.

**Belem. ru** порталы – татар телендә белем бирүче укытучылар эшендә зур ярдәм. **Татарстан язучылар берлеге сайты –** татар теле һәмәдәбияты укытучыларына зур ярдәмлек. Әлеге сайтта яңа чыккан кита- плар; язучылар турында истәлекләр, интервьюлар; нәфис, документаль фильмнар; спектакльләр, тапшырулар, мультфильмнар урнаштырылган. Әлеге сайтны әдәбият дәресләрендә еш кулланам.

**LearningApps. org**сервисы укытучылар өчен шулай ук зур ярдәм. Әлеге серверда дәреснең төрле этапларында куллану өчен әзер күнегүләр бар. Иҗади эшләүче укытучылар әлеге серверда дәрес өчен, класстан тыш чаралар өчен яңа күнегүләр төзи алалар. Үземнең дәресләремдә мин күбрәк «Хәрефләрдән сүзләр», «Кроссворд, «Викторина» кулланам, шулай ук әзер күнегүләр дә дәрескә ярдәмлек булып тора. Әлеге күнегүләрне куллану укучыларда уйлау сәләтен үстерә һәм үзләштергән теманы ныгытырга да ярдәм итә.

**biouroki. ru**сайты татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә башваткычлар төзү өчен кулланырга мөмкин. Шәхсән үзем башваткычларны кабатлау, ныгыту һәм тикшерү максатында кулланам. Мәсәлән, 5 сыйныфта «Фонетика һәм орфоэпия» бүлеген үткәннән сон, мин әлеге башваткычны төзедем. (слайд) Моның өчен әлеге бүлеккә караган сүзләрне **biouroki**. **ru** сайтындагы «создать кроссворд»ка язып чыктым. Шуннан соң әлеге сайт башваткычларның төрле вариантын төзеп чыгарды. Сорауларны һәрбер укытучы үзенчә формалаштырырга мөмкин.

**Videouroki в Интернет** – укытучылар өчен сайт. Әлеге сайтта та- тар теле һәм әдәбияты дәресләре өчен тестлар төзеп була. Ә тестларга дөрес җавап бирү өчен, фәнне камил белү белән бергә, укучыларны кече класслардан ук тестлар белән эшләргә өйрәтү зарур. Кәгазьдә язып, аны укучыларга таратып, соңыннан җыеп алып тикшерү укытучыдан бик күп вакыт сорый. Компьютерга кертелгән махсус программалар тестлар төзү һәм чишү өчен укытучы хезмәтен күпкә җиңеләйтә. Әлеге программа белемне ни дәрәҗәдә үзләштерүне ачыклау өчен бик тә уңайлы. Тест нәтиҗәләрен шунда ук тикшерү һәм принтер аша чыгарып алу мөмкинлеге бар.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу.

# *Туган тел дәресләрен укытудагы проблемалар һәм перспективалар*

***Ахмадуллина Рәмзилә Фирдинат кызы,***
*Казан шәһәренең Совет районыны 141 нче гимназия*

Бүгенге көндә безнең төп бурыч– ана теле буларак татар телен сайлаган әлеге укучыларның санын саклап калу, милли тәрбия бирү. Укытучы дәрестә укучыда туган телгә кызыксыну уятырга, татарча бераз гына булса да аралашырга өйрәтергә, милли хисләрне тәрбияләүне дәвам итәргә тиеш. Шуңа күрә дәресләрне җанлы, кызыклы, иң мөһиме, гади һәм аңлаешлы итеп үткәрергә кирәк. Мин иң беренче чиратта телдән сөйләмгә игътибар итә башладым. Сыйныфтагы бала дәрес ахырын-да берничә җөмлә белән диалог һәм монолог төзи алса, мин моны уңай күренеш дип саныйм.

Кызганыч, бүгенге көндә татар телендә өйрәтүдә авырлыклар җитәрлек: методик әсбаплар, ФДББС таләпләренә туры килерлек дәрес эшкәртмәләре тупланган җыентыклар аз булуы борчый. Бигрәк тә татар телен сайлап укыту бик зур авырлык тудырды. Без 2016 нчы елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча коллегам Сөнгатуллина Р. Ф. белән берлектә укытучылар өчен И. Л. Литвинов уку әсбабына нигезләнеп «Укытучы китабы»н төзегән идек һәм ул Татарстан китап нәшрияте ярдәме белән басылып чыкты.

Минемчә, нинди генә дәреслек яки уку әсбабы белән эшләсәң дә, дәреснең ничек узуы укытучыдан тора. Әлеге методик әсбапны рус төркемнәрендә туган тел дәресләрендә башка дәреслекләргә дә җайлаштырып кулланырга мөмкин.

Мин беренче сыйныфларда бу методик әсбапны кулланам. Үзем башлангыч сыйныфларда һәр дәрестә 3-4 яңа сүз һәм дәрескә кирәкле сөйләм калыпларын гына өйрәтергә тырышам.

Мине тагын икенче мәсьәлә борчый: әдәбият дәреслекләре бик катлаулы, ләкин тәҗрибәле укытучы төрле юллар табарга тиеш дип уйлыйм. Хәзер интернеттан, Ютуб каналларыннан дәрескә кирәкле татарча төрле кызыклы мәгълүматны, язучыга кагылышлы презентацияне табарга һәм үзгәртеп кулланырга мөмкин. Әлбәттә бу бераз вакыт һәм иҗадилек сорый.

Кайбер дәресләргә дәреслектә бирелгән текстларны бераз гадиләштереп бирәм. Язучының биографиясен өйрәткәндә портрет, ә тектларны өйрәнгәндә рәсем белән эшләү алымын кулланам. Рус төркеме

икәнен исәпкә алсак, бу укучы өчен шактый авыр эш. «Рәсемдә нинди кеше? Аның чәче нинди ? Ул ничек киенгән?» кебек иң гади сораулардан башлыйм. Биографиягә, текстларга кагылышлы *(туган, белем ала, йөри, яза, укыта, иҗат итә)* сүзләрне сөйләмгә кертү өчен алар белән сүзтезмәләр, җөмләләр белән бирәм. *(Ибрагимов туган, 13 нче мартта туган, Солтанморатта туган, авылда туган, Солтанморат авылында туган һ. б.)* Мин текстларның һәр җөмләсен тәрҗемә иттермим. Кайбер җөмләләрне русча әйтәм, ә укучылар үзләре татарчасын табып укыйлар. Бүгенге көндә укучыларның уку грамоталыгы турында күп сөйләнелә. Текстны татарча аңлау дәрәҗәсен тикшерү өчен «Дөрес. Дөрес түгел» кебек уен ярдәм итә. Мәсәлән, җөмләләр текстка туры килсә, укучылар басалар, текстка туры килмәсә, утыралар.

Язучы биографиясе, текстлар эчтәлеге турында иң гади сораулар бирәм, чөнки бу эш рус төркеме өчен бик авыр. *(Язучы кем?Ул кайда туган?Ул нәрсә яза?Язучы кем өчен яза?)* Әлбәттә, биредәге татар балалары өчен авыррак сораулар бирергә була. Һәр дәрестә бер укучыны такта алдына чакырып, башкаларга сораулар бирдерәм, ә аннан сон икенчесен чакырып, сыйныфтагы башкалар аңа сораулар бирәләр, төркемнәрдә эшләтү дә файдалы, ләкин укучыларның шаулашып утыруларына юл куймаска кирәк.

Минемчә, гел зарланып кына туган тел фәнен укытып булмый. Материалны мөмкин кадәр гадиләштереп, ФДБС таләпләре нигезендә заманча педагогик технологияләрдән файдаланып эшләгәндә дәресләр уңышлы узачак. Дәресләрнең бай, нәтиҗәле үтүе шулай ук укытучының индивидуаль эшчәнлегенә, талантына да, укучыларына булган мөнәсәбәтенә дә бәйле. Туган телгә мәхәббәтне дәресләрдә тәрбияләү укытучыдан да тора, шулай ук әти– әниләр белән эшләү дә сорала.

Димәк, бүгенге чорда укытучы туган тел дәресләрен гади, кызыклы һәм заманча тәлапләргә туры китереп үткәрсә, күбрәк нәтиҗәгә ирешер. Чыгышымны И. Ньтонның «Телне өйрәнгәндә кагыйдәләргә караганда мисаллар файдалырак!» дигән сүзләре белән тәмамлыйсым килә.

# *Лэтбукларны туган тел һәм әдәбият дәресләрендә куллану*

***Әхәтова Гөлүсә Шәүкәт кызы,***
***Гарәпшина Лилия Альберт кызы***
*Казан шәһәре Совет районы 171 нче мәктәп укытучылары*

Хәзерге заман укытучысы бар яклап та өлгер, белемле, җитез булырга тиеш. Ачарга, эзләргә, тикшеренергә, проектларга – заманча дәресләрдә бу сүзләр уку эшчәнлеген оештыруда төп сүзләргә әйләнделәр. Яңа технологияләр кулланып дәресләр бирү, электрон цифрлы ресурслар- дан файдалану – боларның барсын да хәзерге заман укытучысы яхшы белергә тиеш. Мәктәп һәм укытучының төп бурычы – балага өйрәнелә торган фәннең тирәнлеген күрергә ярдәм итү, укучыларны иҗади про- цесска җәлеп итү, киләчәктә мөстәкыйль фикерләү өчен перспектива ачу- дан гыйбәрәт.

Без үз эшебездәпроект алымының бер төре буларак лэтбукларны куллана башладык. Аны дәрестә дә, дәрестән тыш чараларда да, өйдә дә файдаланырга мөмкин.

**Нәрсә соң ул «Лэпбук»?**

Лэпбук ул – интерактив тематик папка яки кулдан ясалган кесәле, ачыла торган матур китап. Аны беренче мәртәбә Америкада кулланганнар. Инглиз теленнән тәрҗемәсе (lap-колени, book-книга, «наколенная книга») күрсәтмә яки таратма материаллар тупланган китап. Ә безнеңчә, лэпбук –рәсемле китап кына түгел, ә проект эше өстендә эшләү өчен ярдәмлек тә, мәгълүматны системага салуда эффектив чара да булып тора.

➢ **Лэпбук куллануның максаты:**

- материалны яхшырак аңлау һәм истә калдыру;
- үткәнне кабатлау һәм системага салу;
- мәгълүматны тупларга һәм җыярга өйрәнү;
- фикерләү сәләтен үстерү;
- күзәтүчәнлекне арттырырга, чагыштырырга, анализ ясарга өйрәтү.

Макет төзү – иң кызыклы этап. Монда – фантазиянең иге-чиге юк. Төрле типтагы биремнәр, уеннар лэпбукның аерым-аерым элементларында: кесәләрдә, блокнотларда, кечкенә китапчыкларда, түгәрәкләрдә, төрле формалардагы конвертларда, карточкаларда, бөкләнгән кәгазьләрдә урнаштырыла. Лэпбук – укучыларның иҗади потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән плакат, китаплар һәм тарату материалының җыелу рәвеше. Ул бирелгән тема кысаларында фикер йөртергә һәм креатив эшләргә

өйрәтә, куелган проблеманы хәл итү өчен кирәкле күнекмәләрне формалаштыра. Лэпбук –кесәле кечкенә китаплар, аларга мәгълүматны рәсемнәр, зур булмаган текстлар рәвешендә урнаштырырга була. Уку- чы үзе җыйган материалны төрле төсләр кулланып, формаларга салып бербөтен итеп ябыштыра. Бу эшне аерым һәм шулай ук группа белән дә эшләргә мөмкин. Аерым эшләгәндә укучы үз көчен сынаса, группада эшләгәдә һәр укучы фикерли, үзенең күзаллавын тәкъдим итә, фикерләр төрлелегеннән группада бәхәс туа, төрле чишелеш вариантлары тикшерелә, уку дискуссиясе, уку диалогы аша үзара белем бирү бара. Бу эш барышында укытучы читтән күзәтүче булып тора, кирәк булганда гына киңәшен бирә ала. Һәр лэпбук уникаль, үзенчә, монда аерым кагыйдәләр юк. Укучы эшне ничек күзалдына китерә, шулай эшли. Лэпбук яңа теманы, лексиканы җиңел үзләштеререгә, олимпиадаларга әзерләнгәндә фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итә. Мәсәлән, «Татар халкының милли киемнәре» темасын үтеп бетергәч, өч төркемгә түбәндәге биремнәрне биреп лэтбук төзетеп була:

- татар халык милли киемнәре турында шигырьләр;
- татар халык киемнәрендә милли бизәкләр;
- татар халык киемнәрендә төсләр.

Халкыбызның милли традицияләрен саклау максатыннан ел фасыллары белән бәйләнешле йола – бәйрәмнәре турында төркемнәрдә лэт- бук төзетеп була (« Сөмбелә», « Карга боткасы»,» Нәүрүз». «Сабантуй» бәйрәмнәре);

татар һәм рус бәйрәмнәре, истәлекле урыннар, сүз төркемнәре, язучылар һ. б.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була лэпбук булдыру, укучыларда фәнне өйрәнүгә кысыксыну уятырга мөмкинлек тудыра һәм заманча белембирү бурычларын хәл итәргә ярдәм итә. Ул балага эксперимент ясап ка- рау, алган белемнәрен гомумиләштерү мөмкинлеге тудыра, аның иҗади сәләтен һәм аралашу күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә. Лэтбук эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый. Лэпбук – алган белемнәрне дәрестә ныгытучы алым гына гына түгел, ул фантазия очышы да.

# *Башлангыч сыйныф укучыларына яңа технологияләр кулланып белем һәм тәрбиябирү*

***Вафина Раушания Мингазетдиновна,***
*Казан шәһәре Идел буе районы МБГГБУ «Татарча белем бирүче 18 нче гимназия «нең башлангыч сыйныф укытучысы*

Башлангыч сыйныфларда заманча технологияләрне куллану мөмкинлеген күрсәтү минем эшемнең максаты булып тора. Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны куйдым:

1) заманча технологияләрнең күп төрле булуын ачыклау;

2) башлангыч сыйныфларда укыту-тәрбия процессы барышында проект методын куллануның нәтиҗәлелеген билгеләү.

Барлык инновацион технологияләр арасында мине укыту эшчәнлегенең киң танып – белү ихтыяҗларын һәм мотивларын формалаштыруны гарантияләүче үстерүче укыту җәлеп итә.

Еш кына үз дәресләремдә мин проблеманы хәл итүнең күмәк эзләү ысулын файдаланам. Хикәяләр буенча фикер алышу процессында барысы да катнаша, барысы да үз фикерләрен әйтәләр һәм башкаларны тыңлыйлар, барысының да хокуклары тигез. Мин үзем фикер алышуда катнашмыйм, әмма төркемнең ничек эшләвен күзәтәм. Әлеге ысул теманы өйрәтүне тәмамлаганнан соң материалны үзләштерү нәтиҗәлеген бәяләү өчен уңайлы.

Дәресләрдә индивидуаль һәм дифференциаль укытуга аерым роль бирәм. Шул максаттан, рольле уеннар дәресләре кебек иҗади дәресләр нәтиҗәле булып торалар. Әлеге дәресләрнең һәрберсенең үзенчәлекләре бар. Аларның уртак ягы – укучыларда сөйләм эшчәнлегенең һәм сөйләм иҗатының төрле төрләрендә мөстәкыйль уку күнекмәләрен үстерү булып тора. Өй эшен мин укучыларның сәләтенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп индивидуаль бирергә тырышам.

Башлангыч сыйныфта укыту һәм тәрбия бирү максатларының берсе – укучыларга заманча компьютер технологияләрен үзләштерергә ярдәм итү, алар ярдәмендә алган белемнәрне киләчәк үзүсеш өчен кулланырга өйрәтү. Бу максатны тормышка ашыру өчен дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда информацион технологияләр куллану зарури.

Белем бирүдә компьютер технологияләрен куллану түбәндәге нәтиҗәләрне бирә:

укучыларда әйләнә-тирә дөньядагы информация агымында ориентлаша алу күнекмәләрен үстерә;

информация белән эшләүнең практик төрләренә төшендерә;

заманча техник чаралар ярдәмендә информация алмашу күнекмәләрен үстерә;

укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыра;

уку материалын аңлау, истә калдыру һәм үзләштерүне оптимальләштерә;

дәресне югары дәрәҗәдә үткәрергә ярдәм итә;

төрле дәрәҗәдәге биремнәр кулланып, һәр укучыга шәхси якын килергә мөмкинлек бирә.

Мин информацион технологияләрне дәреснең төрле этапларында; укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшергәндә; проектлар методы белән интеграль дәресләр үткәргәндә кулланам. Төгәлрәк әйткәндә, татар теле дәресләрендә укучыларга компьютер технологияләре ярдәмендә төрле күнегүләр бирәм, яңа темага керер алдыннан проблемалы ситуациләр тәгъдим итәм. Әдәби уку дәресләрендә язучы биографиясенең кызыклы фактлары белән таныштырам, читтән торып сәяхәт итү кебек эш төрен кулланам, язучы иҗаты буенча куелган әкият яисә спектакльдән өзекләр күрсәтәм, нәфис сүз осталары язмаларын тыңлатам. Шулай ук дәрестән тыш чараларда; укучыларның игътибарлылык, хәтер, фикерләү кебек конкрет сыйфат һәм мөмкинлекләрен тикшерү, үстерү эшләрен алып барганда; компьютер технологияләрен куллануның уңай нәтиҗәләр бирүен күрдем.

Укучылар үзләре дә компьютер программаларын файдаланып, төрле иҗади мөстәкыйль эшләр үтиләр. Мондый төр эшләр укучыны тагын да активлаштыра, белем алуга дәртләндерә һәм мөстәкыйльлек тәрбияли.

Шулай итеп, мәгариф системасы җәмгыять куйган таләпләрдән калышмаска, ә укытучы заман белән бергә атларга тиеш.

Укытучының һөнәри эшчәнлегендә эзләнү һәм иҗат итү өчен мөмкинлекләр күп. Укытучы бары тик укучыларның үзенчәлекле якларын истә тотып, заман таләпләренә туры килерлек итеп эшли белергә һәм укыту процессын укучыларның танып – белүчәнлекләрен үстерерлек итеп дөрес оештыра белергә, укучыларны алган белемнәре үз эзләнүләренең нәтиҗәсе булуына ышандыра алырга тиеш.

## *Укытуда компьютер технологияләрен – нәтиҗәле куллану методикасы*

***Вафина Э. М., Фассахова Р. И,***
*ТР Казан шәһәре 169нчы мәктәбе татар теле укытучылары*

Татар теле дәресләрен кызыксындырырлык, нәтиҗәле, файдалы итүдә, уку сыйфатын яхшыртуда мәгълүмати технологияләрдән, аерым алганда, Microsoft Word, Microsoft Power Point программалары, электрон почта, Интернет челтәрләреннән файдалануның мөмкинлекләре зур.

Мәгълүмати технологияләрне куллану формалары:

1. Әзер электрон продуктларны куллану. Белем бирүнең сыйфатын яхшырта, күрсәтмәлелек принцибын ачык итеп тормышка ашырырга ярдәм итә.

2. Мультимедиалы презентацияләр куллану. Уку материалын тиешле бер эзлеклелектә биреп, материалны ассоциатив рәвештә истә калдырырга булыша.

3. Интернет челтәре ресурсларын куллану. Белем алуга кирәкле материалны үзлекләреннән тиз табарга мөмкинлек бирә.

Мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлекле яклары: материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы, укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар, контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары (материалны кабат укып, хатаны төзәтергә, проблема чишүнең берничә вариантын файдаланып карарга мөмкин)

Укытуны интенсивлаштыру өчен, тестларны нәтиҗәле кулланырга мөмкин. Уку, теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен дә тестлар уңайлы.

Электрон уку ярдәмлекләре түбәндәге дидактик бурычларны хәл итәргә булыша: аерым фәнгә караган база белемен үзләштерү; дәрес материалы белән мөстәкыйль эш иткәндә, укучыларга уку-методик ярдәм күрсәтү; уку материалы белән мөстәкыйль эшли белү күнекмәләре булдыру; үзләштергән белемне билгеле бер калыпка салу; аеруча катлаулы, четерекле сорауларга җавап бирергә күнектерү; үз-үзеңә контрольлек итү күнекмәләре булдыру; укучыда гомуми белем алу күнекмәләре булдырып, аны тиз арада имтихан бирүгә әзерләү.

Презентацияләрне укытучы аңлаткан чакта да, өй эшләрен тикшергәндә дә кулланырга мөмкин. Моның өчен вакыт та аз сорала. Укучылар, үзләре башкарган эшнең кирәклеген тоеп, өй эше биремнәрен

үтәүгә җитдирәк тә карый башлый. Хәтта докладлар һәм төрле чыгышлар әзерләргә бик үк атлыгып тормаган укучылар да компьютербелән эшлиләр. Презентация өчен материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайланырга тиеш.

Рус телле балаларны аралашуга өйрәтү диалоглар аша ирешелә. Шуңа да дәресләрдә төрле ситуацияләргә диалоглар күп төзелә. Ләкин коры диалог кына укучыны ялыктыра. Шуңа күрә, аларны кызыксындыру максатыннан, диалог темасына туры килгән слайдлар файдалану отышлы. Рәсемгә карап, яңа сүзләр, гыйбарәләр туа һәм сөйләмгә кереп китә. Әйтик, дәрестә әңгәмә корган вакытта укучыларның сүзлек байлыгы җитмәү һәрвакыт сизелә. Шуңа да укытучы алдында яңа сүзләрне тиешле һәм урынлы куллана белергә өйрәтү бурычы тора. Яңа сүзләрне язып куеп кына истә калдыру кыенрак. Әгәр алар презентациядә күрсәтелсә, тагын да отышлырак. Шулай ук сүзлек эшен дә шунда күрсәтергә мөмкин.

Компьютер технологиясе ярдәмендә түбәндәге эш төрләрен кулланырга була:

1. Текст белән эшләү. Презентация ярдәмендә сүзлек, тикшерү диктантларын яки контроль күчереп язуларны тикшерергә уңайлы. Моның өчен бер слайдта хәрефләре төшеп калган яки хаталы текстлар бирергә була. Эшне башкаргач, укучылар бер-берсе белән дәфтәрләрен алмашалар һәм алдагы слайд ярдәмендә тикшерәләр. Төшеп калган хәрефләр, хаталар башка төс белән бирелә. Киләсе слайдта бәяләү критерияләре күрсәтелә. Биредә укучыга җавап вариантларын сайлап алу гына түгел, аларның дөреслеген тикшерү мөмкинлеге дә тудырыла. Бер-берсен мактыйлар, хаталарны төзәтергә киңәшләр бирәләр.

2. Бирелгән сүзләрнең, сүзтезмәләрнең урыннарын үзгәртеп бәйләнешле текст төзү.

3. Дәресләр өчен өстәмә материал, мәгълүмат бирү максатыннан кагыйдәләрне үз эченә алган презентацияләр куллану һ. б. лар.

Гомумән, бүген дәресләрдә заманча технологияләр куллану белем бирү дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итә. Ул укыту-тәрбия эшен гамәлгә ашыру, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә.

# *Балалар бакчасында һөнәрләр белән таныштыру*

***Вилданова Алия Мәгъсүм кызы,***
*Казан шәһәре Киров районының*
*«Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

Тормышта һәр кеше үзенә яраткан шөгыль табып, шуннан күңеленә хуш килерлек, үзенә файда китерерлек эш табарга хыяллана. Яшәү дәверендә сине канәгатьләндерерлек һөнәрне ничек сайларга?

Балалар үзләренә таныш булган һөнәрләр сайлыйлар. Һөнәрләр балаларның белемнәренә нигезләнеп сайланыла. Ә балаларның белемнәре һөнәрләр турында бик ярлы, соңрак мәктәп яшендә генә, сирәк очрый торган һөнәрләр белән танышалар. Хәзерге вакытта һөнәрләр бик күп төрле. Көннән-көн төрледән төрле һөнәрләр туып тора. Ләкин, тормышта гомерлек һөнәр сайлау бик авыр.

Өлкәннәрнең хезмәткә карата уңай карашлы мөнәсәбәте балалар-га зур йогынты ясый. Балалар күп вакытта әти-әниләре һөнәрләрен сайлыйлар. Һәм шулай итеп, укытучылар, табиблар, галимнәр, сәнгать эшчәннәре эшчеләр династияләре туа. Моның сәбәбе – заманча иҗади һөнәрләр төрлелеге турындагы белемнәренең ярлы, сай булуы.

Мәктәпкәчә яшьтәге чор педагогик йогынты ясау өчен иң кулай вакыт.

Җәмгыятьтә һөнәрләр дөньясы – катлаулы, һәрвакыт үсештә булучы булучы бер система ул. Әле, ун ел элек кенә балаларны аш пешерүче, сатучы, автомобиль йөртүче һәм башка һөнәрләр хезмәте белән чикләгән булсак, хәзерге заман чорында алар белән генә канәгатьленелми. Гамәлдә хәзерге чор безгә яңа таләпләр куя.

**Актуальлеге** бирелгән эшчәнлекнең һичшиксез бәхәссез. Яшьтән үк хезмәткә кызыксыну уяту, тәрбиядә дөрес юнәлеш бирү күп кенә хәл итеп бетмәгән мәсьәләләрне чишәргә мөмкинлекләр бирә. Күптән билге-ле, киләчәге уңай хәл ителгән бик күп кенә балаларны һәм яшүсмерләрне уйламый эшләнелгән адымнарыннан саклап кала. Димәк, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга кече яшьтән дөрес юнәлеш бирү һәм кызыксыну уяту – үткен социаль мәсьәләләрне чишүнең бер хәзинәсе.

**Максаты**: мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иҗади һөнәрләр үзенчәлекләрен күзаллауларын формалаштыру.

Бу максат балаларның төрле эшчәнлек процессында: уен, сөйләм, хезмәт, танып белү, продуктив, музыка, матур әдәбият уку эшчәнлекләрендә тормышка ашырыла.

Нәтиҗәдә:

– Бала өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлегендә материал һәм җайланмаларны кулланылып, аларның нинди вазыйфа башкаруын белә

– Төрле сферадагы һөнәрләрне атый

– Төрле һөнәр вәкилләренең һөнәри әһәмиятле сыйфатларын атый

– Хезмәт күренеше барышы төзелешен аерып күрсәтә белә (максаты, эш кораллары, хезмәтне ничек башкаруы, нәтиҗәсе)

– Төрле төрдәге хезмәт һәм һөнәрләрнең үзара бәйләнешен аңлатып бирә, хезмәтнең кешеләргә уңыш китерүен аңлата

– Уенда төрле һөнәр ияләре арасында бәйләнешне модельләштерә

– Бала мөһим мәдәни ысулларны кулланып, эшчәнлекләрдән файдаланып, төрле төзү һәм башка эшчәнлекләрдә – уен, аралашу, танып белү эшчәнлекләрендә ачылып, башлап җибәрергә сәләтле

– Үзенә шөгыльне эшчәнлектә бергәләп катнашучыларны сайлап ала белә

– Балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать өлкәсендәге күренешләрне, табигать белеме, математиканы аңлый. Төрле эшчәнлекләрдә үз белеме һәм осталыгына таянып, мөстәкыйль карарлар кабул итәргә сәләтле.

## *Киләчәк укытучысы*

***Галиева Гөлназ Шамил кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы МБГББУ*
*«Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия» туган теле укытучысы*

*«Кешене иң бөек дәрәҗәләргә җиткергән*
*һәм исемнәрен соңгы буыннарга*
*калдырган кеше-укытучыдыр.»*
Ризаэддин Фәхретдин

Киләчәк укытучысы нинди булырга тиеш соң? Бу сорауга җавап биргәнче тарихка күз салып үтәсе килә. Үткән заманнардагы бөек философлар, укытучыларны искә төшерик әле. Платон Аристотельнең укытучысы, ә Аристотель Александр Македонскийның укытучысы булганын беләбез. Шул ук вакытта бөек галимнәребез Ризаэтдин Фәхретдин, Каюм Насыйриларны да әйтмичә уза алмыйбыз. Бу укытучылар нинди сыйфатларга ия булганнар соң? Информацион технологияләр заманы

булмаса да, алар бик күп дәрәҗәле шәхесләр тәрбияләп чыгара алганнар бит. Минем уйлавымча, алар үз һөнәрләрен яратучы, балаларның эчке дөньясын аңлап, алар өчен җан атучы, үз-үзләре өстендә даими рәвештә эшләүче киң күңелле, тугрылыклы затлар булганнар. Нәкъ шул галимнәр укучыларның күңелендә табигатьтән яралган сыйфатларны күрә алганнар, аларга, чәчәк таҗлары кебек, ачылырга, дөньяга нур чәчәргә ярдәм иткәннәр.

Мин үзем укырга яратам, һәрвакыт яңалыкка омтылам. Нинди дә булса яңа технология белү, аны дәресемдә уңышлы куллану-минем өчен зур шатлык булып тора. Шулай да мин үземне киләчәктә тагын да камилләшкән укытучы итеп күрәсем килә. Минем хыялымда зур, якты коридорлар һәм кабинетлар. Юк, мин аларны класслар дип тә атамас идем, ә виртуаль әйләнә-тирәлек итеп күрер идем. Мин анда килеп,бөек галимнәребезнең төпле фикерләрен кинәшләрен тыңлый алсам иде, әйтерсең, мин аларның дәресләрендә утырган кебек хис итсәм иде үземне. Икенче бер кабинетка кереп, бөек Тукаебызның «Әллүки», «Туган тел», Моцартның «Времена года « көйләрен тыңлап, күңелгә рухи ләззәт алып булсын иде. Соңгы елларда Интернет проектлар бик популяр булып китте. Мин укыту эшчәнлегемдә һәр балага якын килеп, аның иҗади мөмкинлекләрен ачу өчен «Центр развитие традиционных культур» сайты проектларын сайлап алдым. Элеге берләшмә хезмәткәрләре белән якыннан танышкач үз фәнемне татар, рус, чуваш, төрек милләтеннән булган балаларга нәтиҗәле укыту юллары ачылды. Бик саллы материаллар, бәйгеләр, очрашулар, фестивальләр баларны үзенә җәлеп итә һәм татар телен өйрәнүгү, эзләнүгә теләк уята.

Укытучы – универсаль кеше дип юкка гына әйтмиләрдер ул. Чыннан да, киләчәк укытучысы да балага, аның яшенә карамыйча, әни дә була белергә тиеш, психологик яктан да ярдәм күрсәтә белүе зарур, шул ук вакытта баланың дусты, иң якын сердәшчесенә әверелергә тиештер ул. Баланың мәктәпкә барасы килүе, сыйныфтагы мөхит, аның белемгә омтылуы, югары үрләр яуларга әзер булуы – болар барысы да, иң беренче чиратта, укытучыдан тора. Укытучы кеше бала белән үз мөнәсәббәтен ничек итеп төзи, аңа дөньяны кайсы ягы белән, бигрәк тә нинди төсләр белән ачып күрсәтә, шул килеш шәкерт олы тормышка яраклаша һәм үз урынын таба. Әлбәттә, күп очракта, боларның барысы белән дә әти-әни шөгыльләнергә тиеш дип уйларсыз. Әйе, килешәм, ләкин бала үзенең барлык булган вакытын диярлек мәктәп диварларында үткәрә һәм әти-әниләр ышанып, аларны безнең кулларга – укытучыга тапшыра. Ә укытучы, үз чиратында, элеге ышанычларны кара таплар төшермичә бары тик

акларга тиеш. Бу сыйфатлар барысы да киләчәк укытучысында булырга тиеш!

Сүземне йомгаклап, туган тел һәм әдәбияты укытучысы була- рак фикерләрем болайрак минем. Без, укытучылар, киләчәкне төзибез. Югарыда санап үтелгән сыйфатларга омтылган хәлдә, укучыларыңны чиксез хөрмәт итүче, үз эшеңә мөкиббән, буыннан –буынга килгән традицияләрне яратучы һәм саклаучы, шул ук вакытта яңалыкка омтылучы, шәкертләрнең киләчәге булсын дип, янып-көеп эшләп йөрүче укытучы булсаң гына ниндидер нәтиҗәләргә ирешеп була. Киләчәк буынны тәрбияләү өчен, заманнан артта калмыйча, укучыларыңнан алда атлап, аларга дөрес юнәлеш биреп барырлык эшчәнлек сайлаганда гына, чын «Киләчәк укытучысы» булырга мөмкин дип саныйм.

## *Нәселем горурлыгы –<br>Шаһвәлиева Мәрзия Габдулла кызы*

**_Галиева Лилия Сәлим кызы._**
*ТР Яшел Үзәнрайонынын 54 нче номерлы*
*«Йолдызчык» балалар бакчасы» БМББУе тәрбиячесе*

*Кеше җирдә торса торсын,*
*Эзе калсын тирән булып.*
*Үзе үлсә, эше калсын,*
*Мең яшәрлек имән булып.*
(М. Җәлил)

Муса Җәлилнең бу шигырь юллары нәкъ менә үз нәселемдә булган горурланырлык һәм балаларыбызга үрнәк итеп сөйләрлек Мәрзия апа турында язылган шигъри юллар кебек тоела. Максатым буыннар чылбырын өзмичә, гаилә тарихына үземнән өлеш кертеп үткәннәр белән киләчәк буыннар арасында арадашчы ролен башкару. Үз нәселеңнен тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту. Туганнарым турындагы мәгълүматне хәзерге һәм киләчәк буыннарга тапшыру, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

Теманың актуальлеге. Бүгенге көндә буыннар арасында тарихи бәйләнеш юк дисәң дә була. Балалар өлкән буын кешеләреннән үрнәк алып яшәргә тиеш. Шуңа күрә һәр кеше үз гаиләсендә буыннан-буынга килгән истәлекләрне, тарихи мәгълүматләрне өйрәнеп, аларны саклап, киләчәк буынга тапшырырга бурычлы. Үз вакытында Шиһабетдин

Мәрҗәнине дә бу мәсьәлә борчыган. Шуның өчен дә ул милләтнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнүгә күп хезмәт куйган.

Чыгышымның төп герое – Мәрзия апа, анын язмышында Бөек Ватан сугышыннан сон булган үзгәрешләр, анын хезмәт сөючәнлеге, тырышлыгы аркасында тарихка кереп калуы.

Бу гаиләнең тормышы меңләгән гаилә тормышына охшаган да, узенчәлекле дә; бу зур тарихнын бер күзәнәге. Чөнки зур тарих ул – аерым-аерым кешеләр язмышы җыелмасы.

Шаһвәлиева Мәрзия Габдулла кызы 1936 нчы елның 5 нче июнендә туган. 1941 елда сугыш башланганда ана нибары 5 яшь, ә энесе Әмингә 3 яшь булган. Әтиләре сугышка киткән. Ләкин исән-сау әйләнеп кайтыр дип күпме генә өметләрен өзми көтсәләр дә, ул сугыштан кире әйләнеп кайтмаган. Сугыш ачысы, тормыш авырлыгы эсез үтмәгән, әлбәттә. 1951нче елда әниләре, Маһикамал да җир куенына кергән. Бу вакытта Мәрзия апага -14, э бабаем Әмингә – 11 яшь булган. Алар әби-бабалары тәрбиясендә үскәннәр. Әби-бабайлар олы яшьтә булу сәбәпле, күп эшнең авырлыгы аларнын үз җилкәләренә төшкән. Шул вакытларда Шаһвәлиев Габделхак абыйнын хатыны үлеп киткән. Анын 3 кыз баласы ятим калганнар. Габделхак абый бу балаларны үзе генә устерергә кыенсынып Мәрзия апаны кияүгә сораган. Үзе дә әти, әни дип яшәргә тилмереп үскән Мәрзия апа, шул балаларны кызганып, аңа ризалык биргән. Мәрзия апа күпләр өчен үрнәк булырлык зат. Анда чын татар, мөселман хатын-кызларына гына хас сабырлык, зирәклек, шәфкатьлелек сыйфатларын күрергә була. Нинди генә авырлыклар килгәндә дә ул сынмаган, сыгылмаган. Үзенен эш сөючәнлеге, тырышлыгы, кыюлыгы белән ул тарихта эз калдырган.

1964 нче елда танылган рәссам Харис Якупов Шәле авылына килгән. Ул Марзия апанын һәм башка сыер саучыларның хезмәтен күреп Шәле сыер саучылары турында «Көчле кешеләр» исемле картина ясаган. Юкка гына «Данның төбе хөрмәт, хөрмәтнең төбе хезмәт», – димәгәннәр. Халыкның булганлыгы танылган рәссам Харис Якуповны да хәйран калдыра. Шулай булмаса, Шәле хезмәтчәннәре турында зур цикл язар идемени ул?! Ирешелгән уңышларымның күбесе «Шәле картиналары» өчен», – дигән бит рәссам. Сыер савучылар, көтүчеләр турындагы күренешләр дөньяның кайсы гына почмагында булмады икән?! Бу картина бүгенге көндә Мәскәүнең Третьяков галереясендә сакланланган. Шулай итеп минем туганым тарихка кереп калган.

Бүгенге көндә Мәрзия апа авылыбызнын абыстае, дини белем, тәрбия бируче, ислам диненә өндәүче, Аллахка мәхәббәт тәрбияләүче остаз, ак әби булып тора.

Уз туганымнын язмышын өйрәнү минем өчен бик кызыклы булды. Чөнки мин аның турында кызыклы һәм кызганыч мәгълүмат белдем.

Шәҗәрә төзүне, нәсел чылбырын өйрәнүне беренче үземнән, туганнарымнан башладым, киләчәктә үз алдыма балалар бакчасындагы балалар һәм аларның әти-әниләре белән дә нәсел чылбырларын өйрәнүне дәвам итәргә, дигән максат куйдым. чөнки халыкның киләчәген үсеп килүче буында.

## *Рус төркемнәрендә укучыларның язма эшләрендә еш очрый торган типик хаталар һәм аларны булдырмау ысуллары*

***Галимова Лилия Илсур кызы***
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган*
*9 нчы урта гомуми белем мәктәбенең»*
*туган (татар) теле укытучысы*

Мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын нәтиҗәле укыту – бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Татар теле һәм әдәбияты фәннәрен тирәнтен өйрәнү – милләт буларак сакланып калу һәм мәдәниятне үстерүнең иң әһәмиятле юлы. Әлеге предметлар буенча белемнәрне ныгыту, тирәнәйтү укучыларның фәнни эшләрен оештыру аркылы да тормышка ашырыла.

Укучыларның татар теленнән алган белем сыйфаты даими рәвештә тикшерүгә бәйле. Татар теле дәресләрендә укучы үзе үзләштергән теоретик мәгълүматны гамәлдә куллана алырлык белем, осталык һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш. Укучыларның татар теленнән белем һәм күнекмәләрен гадел итеп бәяләү – укытучы эшчәнлегенең иң мөһим сыйфаты. Бу таләпләрнең үтәлүе белем бирүнең сыйфатын арттыруга, аны бәяләүгә якын килүне, материалны чама белән тиешле күләмдә тәкъдим итүне тәэмин итә.

Татар теле һәм әдәбияты буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатыннан дәресләрдә төрле язма эшләр – диктант, изложение һәм сочинениеләр яздырыла.

Укучыларның хаталарын төзәтүне системага салу, аларның санын киметү юлларын күрсәтү, әлеге теманың **актуальлеген** билгели.

**Максат һәм бурычлар.** Фәнни эшебезнең төп максаты булып рус төркемнәрендә укучыларының язма эшләрендә еш очрый торган хаталарын барлау һәм аларны булдырмау юлларын ачыклау.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1. язма эшләрнең төрләрен ачыклау, аларны бәяләү критерийларын билгеләү;

2. язма эшләрдә еш очрый торган хаталарны аерып чыгару, аларның төрләрен билгеләү;

3. мәктәптә укучы балаларның язма эшләрендә еш очрый торган хаталарны булдырмау юлларын эзләү

Язма сөйләмгә өйрәтү терәк сүзләр яки сүзтезмәләр белән лексик тема яки ситуация буенча җөмләләр һәм кечкенә хикәяләр язуны үз эченә ала. Аерым җөмләләрдән бәйләнешле язма сөйләмгә күчелә.

Язма эшләрнең төрләре:

– аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешсез яки үзгәрешләр кертеп күчереп язу;

– сүзләрне хәтердән язу, диктант язу

– изложение;

– сочинение;

Укучыларның язма эшләрендә иң еш очрый торган типик хаталардан:

1) орфографик хаталар:

– Ә һәм Е, О һәм Ө, Ң әм Н, Җ һәм Ж хәрефләрен бутап язу;

2) грамматик хаталар:

– билгеле һәм билгесез үткән заман фигыль ккушымчаларын бутап язу;

– килеш кушмчаларын ялгану кагыйдәсе;

– кушымчаларның ялгану тәртибе:

3) лексик хаталар;

Әлеге хаталарны сирәгәйтү өчен без үзебезнең эшебездә түбәндәге төр күнегүләрне тәкъдим иттек:

1) хәреф төшеп калган сүзләрне язу;

2) «Паровоз уены»;

3) Фонетик уеннар, зарядкалар;

4) Күрсәтмәлелек;

5) Текст белән эш

# *Мәктәп укучыларында милли мәдәни-рухи кыйммәтләр формалаштыру*

***Галяутдинова Лариса Анатольевна,***
*Казан шәһәре Совет районы МБГББУ*
*«161 нче рус-татар мәктәбе»*

Җәмгыять алга барган саен, кайбер милли компонетлар югала бара, яшь буын мәдәни үзенчәлекләрнең әһәмиятен аңлап бетерми. Шул сәбәпле хәзерге вакытта халыкның уңай тәҗрибәсенә, аның гасырлар буе барлыкка китергән рухи һәм матди мирасына йөз белән борылу, аларны мөмкин кадәр саклап калу, киләчәк буыннарга төшендерү көн кадагына килеп басты.

XXI гасырда лингвокультурология фәне интенсив үсеш юлында эшчәнлек алып бара. Әлеге тармакка багышланган күп фәнни хезмәтләр языла. Галимнәрне кызыксындырган өйрәнү объектлары – тел, фикерләү, мәдәният һәм этнос бәйләнеше. Телебезгә мәхәббәт тәрбияләү процессында, халкыбызның гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре, тормыш-көнкүреше, дини ышануларның үзенчәлекләрен чагылдырган материалны белем бирү-тәрбия процессында сайлап алу бик зарури. Чөнки татар халкының бәйрәмнәренең күбесе борынгыдан килә. Халык бәйрәмнәре белән эшләгәндә, укытучылар күрсәтмәлелеккә таянырга тиеш. Бу телгә өйрәтү белән кызыксынуны арттыра һәм укучыларның мәдәният өлкәсендәге белемнәрен киңәйтергә ярдәм итә.

Белем бирү процессында укытучылар яшь буыны мәдәни кыйммәтләр белән дәрестә, дәрестән тыш чараларда, мастер-классларда таныштырлар. Укучыларга татар халкының һөнәрләре, милли киемнәр һәм бизәнү әйберләре, бизәкләр, уеннар, җырлар, ризык атамалары, бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр һ. б. шундый мәдәни кыйммәтләр тәкъдим ителә ала.

Дәресләрдән тыш тәрбия эшләре алып бару – балаларга белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше. Укытучы, үзенең укучыларына туган телдән белем бирү, аларны логик эзлекле, төгәл һәм матур итеп сөйләргә, грамоталы язарга өйрәтү белән беррәттән, сүз ярдәмендә безне чолгап алган табигать һәм иҗтимагый тормыштагы матурлыкны, милли һәм рухи кыйммәтләрне формалаштыручы вазыйфасын да башкара.

# *Балалар бакчасында сюжетлы-рольле уеннарның әһәмияте*

***Гибадуллина Зөлфия Ванситовна,***
*Казан шәһәре «Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган 122 нче номерлы балалар бакчасы»МББМБУ*

Уен эшчәнлеге – мәктәпкәчә яшьтәге бала үсешендә зур этәргеч. Балалар бакчасында уен тирәлеген булдыру – төп шарт булып тора. Мәктәпкәчә яшь вакытындагы уеннар логикасыннан чыгып, уен эшчәнлегенең берничә формасын әйтеп китергә була.

1. Режиссёрлык уены-уенчыклар ярдәмендә сюжет уйлап табу. Мондый уеннарны уйнаганда образлы уенчыклар һәм аларга туры килә торган предметлы тирәлек кирәк.

2. Рольле уен-Персонажлар исеменнән сюжет уйлап табу һәм шул сюжет буенча уйнау. Роль өчен атрибутлар, җиһазлар булдыру кирәк.

3. Кагыйдәле уеннар – махсус җиһазлар кулланып уйнала торган өстәл уеннары.

Мәктәпкәчә балачакның төрле этапларында уен нинди булырга тиеш? Балаларны уйнарга өйрәтергә кирәк. Бу өйрәтү тәрбияче тарафыннан җитәкче, уен кагыйдәләрен әйтеп, күрсәтмә бирүче ролендә түгел, ә кушылып бергә уйнаучы, уенга кызыксыну һәм теләк уятучы ролендә булырга тиеш.

Сюжетлы уен баладан теге яки бу эшнең реаль, кулга тотарлык продуктын таләп итми. Бала тормышта чын чүкеч белән кадак тотмаса да, бу уен вакытында («Без – төзүчеләр») уенчык чүкеч белән кадак та кага ала. Уен аша төрле ситуацияләрдә бала үзен ничек тотар, кайсы яктан күрсәтер икәнен ачык күреп була. Төрле предметлар, уен атрибутларын кулланып уйналган бу уеннарда балаларның үзара аралашу дәрәҗәсе, сүзлек байлыгы һәм диалогка бәйләнешле сөйләме үсә, үз-үзләрен тоту күнекмәләре формалаша. Уен вакытында баланың акыл үсешендә генә түгел, ә шәхес буларак формалашуында да алга китеш күренә. Уен вакытында 1, 5-3 яшькә кадәрге балалар уенчык һәм әйбер-алыштыручы белән шартлы рәвештә аралашалар, ә уендагы иптәшләре белән арала- шу кыска вакытлы була. Ә 3-5 яшьтә уендагы рольләрне бүлешеп һәм алышынып уйныйлар, предметлар кулланып диалогик сөйләм аша аралашалар. 5-7 яшьтәге балалар уенда бара торган хәлләрне чиратлаштыралар, 2-3 баланың фикерен һәм уйлап табу сәләтен эшкә җигеп, сюжет төзиләр.

Сюжетлы-рольле уеннар үзеннән-үзе килеп чыкмый. Уенга баланы, ул уенны белүче кеше өйрәтә.

Тәрбияче уен вакытында үзе дә уйный белергә, балаларның тәкъдимнәрен һәм теләкләрен кабул итә белергә тиеш. Уенда тәрбияче сүзе закон буларак түгел, ә бер уенчының теләге буларак кабул ителергә тиеш. Уенда кыенлыклар барлыкка килгәндә, ситуациядән чыга белү, сюжетны тиз һәм профессиональ рәвештә үзгәртә белү сыйфаты да тәрбияче өчен мөһим сыйфат.

Тагын берничә мөһим шарт булып түбәндәгеләр тора:

1. Балалар бакчасында уен тирәлеге өчен материаль база булдыру.
2. Уенчыклар һәм уен зоналары белән тәэмин итү.
3. Балаларның мөстәкыйль уеннары өчен уңай шартлар тудыру.

Бу шартларны тормышка ашыру-балаларның тормышын кызыклы итү, уен атмосферасын уңай эмоцияләр белән сугару өчен кирәк.

## *Проблемы и перспективы развитие родного языка*

***Гильфанова Аниса Гилемхановна,***
*учитель начальных классов МБОУ «Школа №88»,*
*Приволжского района г. Казани.*

*Самая большая ценность народа –язык,*
*язык на котором он пишет, говорит, думает.*
Д. Н. Лихачев

Язык – душа народа. Родной язык – духовное богатство народа. Веками, из поколения в поколение передавались обычаи, традиции, моральные устои, произведения искусства и литературы. Познавая их, человек становится духовно богаче.

Долг каждой нации – сохранить свой язык и сохранять другие языки, долг каждого человека – серьёзно и свято относиться не только к своему, но и к чужому языку.

Преподавание родного языка в школе имеет особое значение, так как родной язык является самым ярким признаком национальной принадлежности, национальной самостоятельности. Люди, особенно дети, мыслят на родном языке. Чем лучше они владеют родным языком, тем ярче, красивее и богаче выражают свои мысли в устной и письменной речи. Первоначальные сведения об окружающем мире и о человеческой

деятельности дети получают посредством родного языка, на котором они общаются дома, в классе, на улице. Поэтому первейшая задача школы обучить детей хорошо владеть родным языком. Тема моего доклада называется «Состояние преподавания родного языка, проблемы и перспективы». Каково же состояние преподавания родного языка в школе? Меняются времена, люди, мысли, меняется сама жизнь, но для учителя одно остается неизменным – каждый день, входя в класс, он видит глаза детей. Не зря говорят, что глаза – это зеркало души. И глядя им в глаза, мы, учителя, видим и понимаем, как многое зависит от того, чему мы сможем их научить, как сможем воспитать сегодня, чтобы завтра они смело шагнули в жизнь и сумели построить эту жизнь достойно. Да, сегодняшние дети – не вчерашние ученики, они другие, они меняются. Если вчера слово учителя было неоспоримо, все, что говорил учитель принималось без сомнений, то сегодня учитель должен быть готов доказать каждое слово, суметь убедить и построить диалог с учениками. Сегодня весь процесс обучения и воспитания строится на сотрудничестве ученика и учителя. Хороший учитель не только увлечет за собой ученика, но и сам увлечется новой идеей, поиском, то есть сам постоянно учиться быть учителем. Все это говорит о том, что учителем сегодня быть нелегко. Труд учителя – это тяжелый труд. Это постоянный труд души и сердца. Наиболее эффективным и результативным средством поддержания интереса детей и их родителей к изучению языка является народная педагогика.

В. Сухомлинский писал: «Народная педагогика – это средоточие духовной жизни народа. В народной педагогике раскрываются особенности национального характера, лицо народа! Характер народа, лицо народа, нравственные идеалы особенно ярко проявляются в созданных им сказках, былинах, легендах, эпосах, поговорках и пословицах».

Через жанры устного народного творчества я знакомлю детей с жизнью, бытом, обычаями татарского народа. Это способствует усвоению материала урока, развитию связной и диалогической речи детей, расширяет словарный запас, а также влияет на духовное и нравственное взаимообогащение.

Хороший результат дает вовлечение детей во внеклассные, общешкольные мероприятия. Становясь активными участниками таких мероприятий, как «Навруз», «Карга боткасы», «Сабантуй» и др., учащиеся детально знакомятся с порядком проведения мероприятий. В будущем эти правила дети переносят в свою жизнь.

*Проблемы и перспективы развития родных языков*

***Гараева Лилия Идрисовна,***
*учитель родного языка и литературы*
*«Адымнар -Казань» г. Казань РТ*

Родной язык – душа народа. И каждый народ (большой он или малый по численности) хранит и бережет свой язык с одной целью – передать его своим потомкам.

С самого рождения ребенок должен слышать, ощущать красоту и прелесть, глубину и богатство, силу и величие родной речи. И цель наша на сегодня– это повышение интереса к изучению родного языка, родной литературы и культуры, воспитанию наших детей на лучших традициях и обычаях своего народа, вооружение детей знаниями, формирование самостоятельности мышления.

Обучение детей родному языку решает следующие задачи:

во первых, развивать в детях ту врожденную душевную способность, которую называют даром слова;

во вторых, ввести детей в сознательное обладание сокровищами родного языка

в третьих, усвоить детям логику этого языка. Эти цели и задачи достигаются не одна после другой, а совместно.

Много сил нужно приложить, для того чтобы эти цели и задачи были выполнимы. Как это сделать на уроках родного языка и литературы? Какие новые формы ввести, чем заинтересовать детей?

Родное слово является основой всякого умственного развития и всех знаний. Очень важно заботиться о своевременном развитии речи детей, уделять внимание ее чистоте и грамотности. Чем богаче и правильнее речь ребенка, тем легче ему высказывать свои мысли, тем шире его возможность в познании действительности, содержательнее и полноценнее взаимоотношения с детьми и взрослыми, тем активнее происходит его психическое развитие.

Чем лучше они владеют родным языком, тем ярче, красивее и богаче выражают свои мысли в устной и письменной речи. Первоначальные сведения об окружающем мире и о человеческой деятельности дети получают посредством родного языка, на котором они общаются дома, в классе, на улице. Возлагать задачу сохранения и развития родных языков только на систему образования, снимая ее с других институтов воспитания, в частности с семьи, прежде всего с родителей, значит, обречь наши

языки на искусственное существование или тихое вымирание. А сегодня на самом деле эти задачи решают в основном только учебные заведения и учреждения культуры.

Такие конструктивные меры, как тесное взаимодействие органов управления образования, образовательных учреждений и научных учреждений; активизация работы по внедрению инновационных подходов в преподавании родных языков; продолжение работы по развитию системы научных, методических и психолого-педагогического обеспечения обучения родным языкам; привлечение в процесс этнокультурного образования, семью, общественность и др институтов социализации человека, является необходимым условием для развития системы этнокультурного образования.

## *Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә кече яшьтәге балаларны адаптацияләү ысулы буларак әкият терапиясен куллану*

***Гимадеева Инзиля Хамисовна,***
*тәрбияче, Казан шәһәре Киров районының*
*«Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

Беренче тапкыр балалар бакчасына килгәндә, әлбәттә бала стресс хәлен кичерә: ул балалар бакчасында әти-әнисез бер үзе, яңа урында, моннан тыш аңа үз-үзен тотышына карата билгеле бер таләпләр куела. Бу факторлар барысы да сабый өчен һичшиксез уңайсызлык тудыра, бу ситуациядә, өлкәннәрнең уртак тырышлыгыннан башка балалар учреждениесенә тискәре мөнәсәбәт формалашырга мөмкин. Моны ничек булдырмаска? Балага адаптацияне ничек җиңел итеп кичерергә ярдәм итәргә? Бу проблеманы хәл итү өчен иң беренче чиратта кече яшьтәге балаларга нәрсә якын һәм аңларга ансат икәнен ачыкларга кирәк? Мин бу сорауга әкият дип җавап бирер идем. Шуңа күрә, тәрбияче буларак мин үз эшемдә әкият терапиясен кулланам. Практик психологиядә әкият терапиясе алымы чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килсә дә, балалар бакчасы педагоглары һәм психологлары арасында бик тиз популярлык алды. Әкият терапиясе –әкият аша йогынты ясау, балага кирәкле мораль нормаларын һәм кагыйдәләрен тапшыру ысулы. Әкият терапиясе

– психологиядә, педагогикада, әкиятләр ресурсларын кулланып, тәрбия, белем бирү һәм үз-үзеңне тотуны коррекцияләү кебек күп кенә бурычларны хәл итү өчен кулланыла торган юнәлеш.

Билгеле булганча, мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәгълүматны ачык образлар аша кабул итәләр һәм әкият адаптацияләнергә генә түгел, ә тулысынча белемнәрне үзләштерүдә дә кулланыла. Әкият терапиясе адаптация ысулы булуыннан тыш, шул ук вакытта башка бурычларны дә хәл итә:

– эмоциональ киеренкелекне бетерү, стресска каршы торучанлыкны үстерү;

– сөйләмне, игътибарлыкны, хәтерне үстерү;

– вак моториканы үстерү, хәрәкәтләрне координацияләү.

Әкият – күпкырлы материал, мин үз эшемдә әкият терапиясенең төрле формаларын кулланам. Әкиятне укырга, сөйләргә, иллюстрацияләрне карарга, арт-терапиядә кулланырга, сәхнәләштерергә була. Бала өчен әкият гади һәм аңлаешлы, безнең әйләнә-тирәдәге предметларны, образларны, әкият формасы аша тасвирларга мөмкин. Кече яшьтәге балалар өчен, әкият турында әңгәмә, фикер алышу әкият терапиясенең мөһим өлеше булып тора. Әңгәмә вакытында бала үзенең фикерен әйтә ала, ягъни аның фикере тәнкыйтьләнергә, кире кагылырга тиеш түгел, киресенчә бала белән бергә әкиятнең мәгънәсенә төшенергә, аңларга, аның игътибары нәрсәгә юнәлгәнен ачыкларга кирәк. Әкият ярдәмендә педагог баланы нәрсә дә булса эшләргә күндерә, тынычландыра ала, уңай эшкә көйли, үз-үзеңә ышанычлырак булырга ярдәм итә.

Шулай итеп, балалар бакчасында әкият терапиясе ысулын куллану яхшы нәтиҗәләр бирә: адаптация җиңелрәк уза, балалар тату, ачыграк булалар, агрессия һәм борчу дәрәҗәсе кими, танып-белү үсеше һәм сүз запасы арта. Әкият баланы турыдан-туры өйрәтми, геройлар ярдәмендә бала үзенә мөһим булган сыйфатларны билгели һәм үзе нәтиҗәләр ясый, образлар ярдәмендә әйләнә-тирә дөньяны аңларга, дөреслекне табырга, яхшылыкка ышанырга өйрәтә.

# *Туган телгә өйрәткәндә заманча технологияләрне куллану*

***Гомәрова Г. А., Газизова Д. Ф.***
*Казан шәһәре Совет районы «171нче гомуми урта белем бирү һәм аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе»*

Дәресләрендә заманча инновацион технологияләр кулланып укытуның максатлары булып түбәндәгеләр тора:

– белем бирү процессының нәтиҗәлелеген үстерү;

– укыту нәтиҗәләре өчен җаваплылыкны, белем алуга кызыксынуны арттыру;

– укучыларны киләчәк тормышка әзерләү;

Яңа мәгълүмати технологияләрдән файдалану фәннилек, күрсәтмәлелек, аңлаешлылык, активлык һәм мөстәкыйльлелек кебек дидактик принципларны гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Бу очракта укытуның телдән сөйләү, күрсәтмә һәм гамәли методлары кулланыла.

Заманча инновацион технологияләр куллану кызыксынучанлык- ны арттыра, белем сыйфатына, уку-укыту нәтиҗәлелегенә, укучының шәхес булып тәрбияләнүенә йогынты ясый. Бу җәһәттән, яңа мәгълүмати технологияләр үзләре үк танып белү, белем туплау коралына әверелә, гомумиләштерү, эзләнү, үстерү, дәртләндерү, тәрбияви һәм контрольгә алу, төзәтмәләр кертү функцияләрен үти. Әмма әлеге яңа мәгълүмати технологияләр телне үзләштерүне тулысынча алыштыра алмый, ә бары тик дәрескә файдалы өстәмә, укучылар һәм укытучылар өчен үзлектән белем алуда үтемле чара булып тора ала.

Заманча инновацион технологияләрне дәресләрдә уңышлы кулла-ну өчен кирәкле җиһазлар, компьютерда эшли белү осталыгы, электрон өйрәтү материаллары һәм Интернеттан алынган материалларның булуы кирәк. Дәрестә укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыклырак итә. Бүгенге көндә мәктәпләрдә мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Без бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшебездә кулланырга тырышабыз. Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт та таләп итә.

Дәресләрдә заманча инновацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп. Бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график про-

граммалар, иллюстрацияләр әзерләргә, гади программалар төзергә, электрон почтадан һәм интернеттан дөрес файдаланырга өйрәтә.

Дәресләрдә басма күрсәтмә материаллар күп булмаганда, укучылар интернет челтәренә чыгып, сайтлардан төрле кызыклы материаллар бастырып алалар. Белемнәрне тикшерү дәресләрендә файдалану өчен төрле программада тестлар әзерләүдә дә укучылар ярдәм күрсәтәләр. Тестны эшләп бетергәч, компьютер нәтиҗә ясап, билге куя.

Дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. Power Paint программасында төрле иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратып та бирергә була. Бу эшләрне дә укучылар бик теләп башкара. Укчылар мөстәкыйль презентацияләр эшлиләр. Шулай ук видео техниканы куллану да отышлы. Түбән сыфныф укчылары мультфильмнар карарга бик яраталар. Компьютер презентацияләреннән файдалану күрсәтмә материалны кулллануны үстерә, предметара элемтәне ныгыта, дәреснең җитештерүчәнлеген арттыра, укытучы һәм укучы мөнәсәбәте ныгый. Информацион технологияләрне катнаш дәрестә, дәрес-лекциядә, проект яклаганда, семинар-дәрестә дә кулланырга була.

Шуны да әйтергә кирәк, дәрестә компьютер куллану белән артык мавыгырга да ярамый, чөнки ул укытучы белән укучының үзара аңлашуын, аралашуын алыштыра алмый. Компьютер соңгы елларда уку процессында актив кертелгән яңа һәм иң мөһим чараларның берсе булып тора. Аны куллану яңа информацион технологияләр барлыкка килүгә ярдәм итә. Дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне кулланунын өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек алар – шәхескә юнәлтелгән ныклы һәм вариатив. Төрле технологияләр, компьютер, мультмедиа технологияләре күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Заман таләбе буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, дәресләрендә компьютер технологияләрен кул- лану бик отышлы дип саныйм мин. Дәресләрендә заманча инновацион технологияләр куллану укучыларда фәнне тагын да ныграк өйрәнүгә кызыксыну уята һәм мәгълүмати җәмгыятьтә яшәргә әзерлек булып тора.

# *Балалар бакчасында татар теленә өйрәткәндә бишек җырларын кулану*

***Гыймадиева Эссана Умер кызы,***
*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия*
*һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

Мин әле дэ хэтерлим: елый башласам да, йоклар алдыннан да әнием мина матур теләклэр теләп, бишек жырлары жырлый иде. Мин шуларны тынлап, тынычланып йоклап китэ идем. Усә тошкәч, мин аларнын юату кочен анлар очен, бишек жырлары белэн ныграк кызыксына башладым. Балалар бакчасында эшли башлавым, сабыйларга тел өйрәткәндә яңа алымнар эзләвем дә моңа этәргеч булды.

Галимнәр инде күптән исбатлаган: балага белем һәм тәрбия бирүдә бишек җырлары бик зур роль уйный. Бишек җырларында ягымлы сүзләр, иксез– чиксез матур хыяллар, ана мәхәббәте туплана. Шуңа күрә алар сабыйның тыныч холыклы булып үсүенә ярдәм итә. Әнисенең җырлары аша бала туган телендә фикеләргә һәм сөйләшергә, тирә-якны танып белергә өйрәнә. Бишек җырлары баланы тынычландыррырга һәм йоклатырга ярдәм итә. Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакытта башкарыла. Бу вакытта ул баласына күңелендә булган бар назын, мәхәббәтен, уйларын, теләкләрен бирергә омтыла. Шуңа күрә дә бишек җырларында әллә нинди катлаулы стилистик һәм лексик чаралар очрамый да диярлек. Ә менә кабатлаулар, чагыштырулар, эндәш сүзләр бик күп. Боларның барсы да текстка назлылык, йомшаклык өсти. Бишек җырларында «Йөрәк маем, алтыным, күз нурым, күгәрченем, йолдызым, жан йөрәгем « кебек иркәләү сүзләре бик күп кабатлана; күгәрчен, былбыл, карлыгыч кебек кошлар, песи, куян кебек хайваннар беләнбәйле сурәтләү чаралары еш очрый. Бишек җырларында ана үз баласына теләкләрен җиткерә: ир баланы ул көчле, кыю, сабыр, ә кызларны гүзәл, зифа буйлы, инсафлы итеп үстерергә тели. Халык иҗат иткән бишек җырларыннан тыш күренекле шагыйрьләребез язган бишек җырлары да бик күп: Дәрдмәнд, Бөек Тукаебыз, Муса Җәлил, Эльмира Шәрифуллина, Рәзил Вәлиев, Резедә Вәлиева, Фирая Зиятдинова һәм башка бик күп авторлар иҗатында да бишек җырлары белән танышырга мөмкин. Без бик теләп элеге әсәрләрне балаларга татар теленә өйрәткәндә файдаланабыз. Музыка җитәкчесе белән берлектә шөгыльләрдә бишек җырларын җырлыйбыз.

Еш кына бишек җырларын үзебезгә дә иҗат итәргә туры килә. Шуларның берсен сезгә дә тәкъдим итәм:

Зәңгәр күктә ай калка,
Балам йокларга ята.
Йоклап торгач, зур булыр,
Йөзләренә нур куныр.
Әле син бик кечкенә,
Уйнар да йоклар чагың,
Синең белән йоклап китәр
Аю, куян, курчагың.
Җилләр дә тынып торыр,
Син йокыга киткәндә.
Уянырсың зур үсеп,
Бар эшләрем беткәндә.
Әйдә, тизрәк йом күзең,
Йом күзеңне тагын да.
Бернидән дә курыкма
Без бит синең яныңда.

Туган тел дәресләрендә сәламәтлек саклау технологиясен куллану үзенчәлекләре

Җәләева Гөлүзә Азат кызы., Г. Тукай исемендәге 1 татар гимназиясе, беренче категорияле туган (татар) теле укытучысы

Белем бирүдә сәламәтлек саклау технологиясе ул –ике максатка бер юлы ирешергә мөмкинлек бирә. Укучыларның сәламәтлеге ныгытыла, белем һәм күнекмәләр бирелә.

Хезмәтнең актуальлеге: бүгенге шартларда укучыларга туган телдә сыйфатлы белем бирү һәм дәресләргә кызыксыну уяту.

Традицион методларга гына нигезләнү, яңалыкка омтылмау, укучыларда туган (татар) теле дәресләнә тискәре фикер уятырга мөмкин. Сәламәтлек саклау технологиясе әлеге проблеманы чишәргә ярдәм итә.

Тикшеренүнең әһәмиятен түбәндәге проблемалар билгели:

– укучыларның татар теле дәресләрен башка кызыклырак фәннәр белән чагыштырып каравы;

– бүгенге җәмгыятьтә балаларның сәламәтлеге шактый түбән дәрәҗәдә булуы;

– әлеге технологиянең, сәламәтлек саклау максаты белән беррәттән, телгә өйрәтү, белем бирү максатларын бергә тормышка ашырырга ярдәм итүе;

– татар теле методикасында бу өлкәнең әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы.

Әлеге технология ике кушыла алмаслык әйберне берләштерә. Ул – белем алу һәм ял итү.

Сәламәтлек саклау технологиясе укыту процессында бер предмет яисә билгеле бер дәрес аралыгында гына тормышка ашырылмый. Ул һәрдаим барырга тиеш. Шул рәвешле сәламәтлек саклау технологиясе укыту формаларында да, чаралары һәм эчтәлегендә дә чагылыштаба.

## *Туган (татар) теле дәресләрендә актив алымнар технологиясен куллану*

**_Карманова А. Р., Мубаракшина Г. И.,_**
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 77 нче урта мәктәбенең 1 кв. категорияле туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары*

Эшебезне Галимҗан Ибраһимовның сүзләре белән башлап китәсебез килә: *«Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгы салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр».* Бу сүзләр бүгенге көндә бик актуаль. Чөнки ФДББС таләпләре буенча белем бирүнең төп максаты – укучыларга белемнәр, күнекмәләр бирү генә түгел, ә аның үзен мөстәкыйль рәвештә белем алырга һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү.

**Эшебезнең максаты:** танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру һәм продуктив иҗат югарылыгына күтәрелергә ярдәм итү.

Нәрсә соң ул укытуның актив алымнары?

Актив алымнар белем бирү системасында стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камиллеген ассызыклый.

Алар-интелектуаль (гамәли) эшчәнлек төре: мәгълүматны кабул итү, төшенү, хәтердә калдыру, иҗади, интуитив фикерләү.

Бу технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора: *өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту → төшенү(аңлау) → рефлексия*. Актив алымнар технологиясе шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр

чыгара. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята. Бу акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә.

## *Туган тел үсешендәге проблемалар һәм перспективалар*

***Забирова Эльмира Шафигуллона,***
*ТР МБГББУ « 2 нче номерлы Арча урта мәктәбе» укытучысы*

Мин Арчаның икенче мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барам. Үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып шундый **нәтиҗәләргә** килдем:

– **Әгәр** балагыз ике тел белүен телисез икән, кечкенәдән авыр була дигән сүзләр белән икеләнмәгез. Бала кечерәк булган саен телне җиңелрәк өйрәнә, бу аның өчен бернинди кыенлык та тудырмый. Сөйләшә башлаган гына балага икенче телне өйрәтү ярый гына түгел, ә кирәк тә. Чөнки ул яшендә бала авазларны ишетеп, үзе дә шуларны кабатларга, аларга ошатырга тырыша, ягъни анда аваздашлык процессы бара. Тел- не өйрәнүнең иң табигый юлы-аваздашлык. Ә бу аваздашлык балаларга гына хас күренеш.

– **Бала** үз телен дә, чит телне дә тигез дәрәҗәдә белсен дисәгез, аның ике телдә дә бер үк күләмдә аралашуын тәэмин итегез. Балачакта тел өйрәнү җиңел,

ләкин кабатламаган очракта белгән дә тиз онытыла. Телне өйрәнү генә түгел, саклый белергә дә кирәк.

– **Балагызны** мәҗбүриләмәгез, телләргә карата нәфрәт уятмагыз, киресенчә, кызыксындрыгыз. Тел белән беррәттән халыкның мәдәнияте белән таныштырыгыз.

**Тел өйрәнүне нәрсәдән башларга?**

– балагызга чит телдә җырлар тыңлатыгыз,

– рәсемле сүзлекләр белән кызыксындырыгыз. Китапның битендә берничә рәсем булса, тагын да әйбәтрәк.

– чит телдә мультфильмнар карагыз.

– туганнарыгыз, дусларыгыз белән сезгә кунакка килгәч, бала белән чит телдә сөйләшүләрен сорагыз.

**Икетеллелекнең өстенлекләре**

**Баш миенең югары үсеше.** Төрле телләрдә сүзләрне, авазларныәйтү ми эшчәнлеген көчәйтә. Биш яшькә кадәр ике телдә сөйләшә алган

балаың баш миендә соры матдә күбрәк була. Ә соры матдә-минең тел һәм аралашу өчен җавап бирүче өлеше. Интеллект дәрәҗәсенең югарылыгы аның тыгызлыгына бәйләнгән.

**Узидәрәнең яхшыруы.** Бер телдән икенче телгә күчү тәртибе баланы үз-үзен тотарга өйрәтә, игътибарын арттыра.

**Сәяхәт итү өчен тәрәзә.** Тел белү берничә илгә сәяхәт итүгә тиң.

**Укуга әзерлек.** Авазлар мөмкинлеген арттыра.

Шәһәрдә яшәүче татарларның да үз телендә иркен аралашканнары чагыштырмача күп түгел. Чөнки күбесе эш урыннарында рус телендә аралаша, җәмәгать урыннарында, транспортта, урамда да, кагыйдә буларак, рус телендә сөйләшә.

Олы яшьтәге һәм урта буын татар кешеләре гаиләдә күбрәк үз телләрендә сөйләшсә дә, шәһәр яшьләре һәм балаларының күбесе өйләрендә дә русча сөйләшә, русча аралашалар. Бүгенге көндә татар телен укытудагы проблемаларыбыз аз түгел. Мәктәпләрдә укыган балаларның ата-аналарыннан татар телен өйрәтүгә карата зарлануларын еш ишетергә туры килә. телне өйрәнүгә тиешле җитди караш, игътибар булмауның төрле сәбәпләре бар.

Беренчесе – балаларның сөйләм теле ярлы, сүзлек запасының аз булуында;

Икенчесе –дәреслекләрнең сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмавы;

Өченчесе –туган телләрендә сөйләшми торган татар балаларын татар теленә өйрәтүнең методикасы камил булмавы;

Дүртенчедән- патриотлылык рухы, милли горурлык хисе, әхлакый тәрбиясе җитмәү.

Мәктәп укучылары арасында укучыларның иң күп җибәргән хаталары:

а) аерым авазларны дөрес әйтмәү;

ә) сүздәге аваз һәм иҗекләрнең урынын үзгәртү яки төшереп калдыру;

б) ашыгып сөйләү сәбәпле, авазлар артикуляциясенең зәгыйфьлеге;

в) баланың сөйләм сулышындагы кимчелекләре: өстән-өстән генә, еш-еш һәм тавышлы итеп, паузасыз тын алу;

г)сөйләм темпы белән идарә итә белмәү, паузаларны тиешле урында ясамау, сөйләмнең бөйләнешле булмавы да борчу тудыра.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү өчен, иң беренче чиратта, фәнне өйрәнүгә карата укучыларда уңай мотивация тудырырга кирәк. Предметка карата уңай мотивация укучы татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүнең гамәли нәтиҗәсен күргәндә, ягъни татар телендә нәрсәдер әйтә, аңлый, башкаларга үз фикерен җиткерә, укый, укыганын аңлый алганда туа.

# *Туган телнең язмышы безнең кулда*

***Закирова Гөлшат Камил кызы,***
*ТР Арча шәһәре, МББУ*
*«Арча 3нче башлангыч гомуми белем мәктәбе-балалар бакчасы»*

Тел – халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Һәр халык үзенең милли туган телен киләчәк буынга тапшырыр өчен саклый. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү– һәр кешенең изге бурычына әверелергә тиеш.

Туган телне өйрәтү проблемалары укучыларның милли үзаңнарын формалаштыру сораулары белән бәйле. Аларны чишү безнең бүгенге дәресләр бирүгә килеп тоташа. Туган телдә алган белемнәрне камилләштерү укучының аңында акрынлап, милли тел – фәнне өйрәнү генә түгел, ә аның белән горурлану, аңа карата үзенчәлекле хис, мөнәсәбәт булдыруны да формалаштыра. Тел аша балалар милләтнең мәдәни мирасына тартылалар, «Туган тел» фәне аша милли традицияләрне, телнең үзенчәлекләрен, кагыйдәләрен өйрәнәләр. Беренче планда бу дәресләр туган телләрендә сөйләшүдән тыш, укучыларда үзләре дә үзенчәлекле, тере, табигый телне йөртүче икәнлекләре турында караш булдыра. Дәресләрдә бөек якташларның иҗатлары, тормыш юллары белән таныштыру балаларда Кече Ватан төшенчәсе барлыкка китерә, аның тарихы һәм бүгенге тормышына кызыксыну уята, туган якка мәхәббәт тәрбияли.

Шунлыктан укыту-тәрбия процессында этнопедагогик чараларны да куллану уңайлы була дип саныйм. Класстан тыш чараларга, укыту процессына халык традицияләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнүне кертү көтелгән нәтиҗәләргә китереп чыгара ала.

Туган телне өйрәнүдә туган авырлыкларны чишү өчен, безгә дәресләрнең сыйфаты өстендә эшләргә кирәк. Аларны, класстан тыш чараларны төрләндереп, кызыклы итеп, башка фәннәр белән бәйләп үткәрү дә бик отышлы була дип уйлыйм. Шулай ук мәктәпнең туган тел фәне буенча материаль – техник базасы булуы да актуаль булып кала. Башка фәннәр белән чагыштыргында, туган телдән дидактик, методик материаллар бик аз бастырыла. Мәктәп китапханәләрендә дәреслекләрнең һәм сүзлекләрнең җитәрлек күләмдә булмавы тагы бер авырлык, сыйныфтан тыш уку өчен китаплар бөтенләй юк дисәң дә була.

Хәзерге вакытта дәресләрдә мультимедиа чаралары еш кулланыла. Мультимедиа технологияләрен куллану яңалыклар белән кызыксыну

теләге уята. Беренчедән, укучыларның белемнәре формалаштырыла, икенчедән, сөйләм һәм мультимедиа чаралары белән эшләү күнекмәләре барлыкка килә. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына электрон уку-укыту ресурсларын, электрон кушымталарны файдалану, телне үстерү һәм саклаү, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү, дәрес эчтәлеклеген баерак һәм кызыклырак итү өчен зур ярдәмлек булып тора. Башлангыч сыйныфларда туган телләрендә мультфильмнар күрсәтү дә телне өйрәнүдә безгә зур ярдәмлек, кызыксындру чарасы булып тора. Ләкин мондый мультимедиа программалар, мультфильмнар бик аз.

Соңгы вакытларда Татарстан җитәкчелегенең татар телен өйрәнү, үстерү мәсьәләсенә игътибарын арттыра төшүе сөендерә. Мәсәлән, 2021 ел республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Татарстан Президенты каршында оешкан Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе дә төзелеп, үз эшен башлап җибәрде. Тагы нинди чаралар ярдәмендә телебезгә ярдәм итә алабыз соң? Бу сорау күпләрне борчыйдыр дип уйлыйм.

Гомумән, телне ниндидер вакытлыча оештырылган чаралар ярдәмендә генә саклау, үстерү мөмкинме икән? Туган телнең язмышы, аның киләчәге халыкның үз кулында. Һәр кеше үзеннән башласа, һәр кеше үз өстенә төшкән бурычны намус белән үтәсә, битараф калмаса, күп нәрсәгә ирешергә була.

## *Экологик тәрбия бирү*

***Замалетдинова Эльмира Асфировна,***
*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия*
*һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

Кешелек дөньясының табигать белән үзара бәйләнеше аерылгысыз процесс. Кеше табигатькә карата кулланучы ролен башкарганга, аның нәтиҗәләре турында уйламыйча файдаланганга күрә актуаль проблема килеп баса да. Менә шуңа күрә табигатькә сакчыл караш тәрбияләүмөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бүгенге көндә табигатьне саклау, балаларга экологик тәрбия бирү – иң зур проблемаларның берсе. Шуның өчен без бөтен көчебезне табигатьне саклауга, экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерергә тиешбез. Табигатьнең киләчәге, бөтенлеге кеше кулында. Экология проблемасының үзебез яши торган җирдә, тирәлектә дә чагылуы

без – тәрбиячеләрдә борчылу тудыра һәм төрле педагогик эшчәнлеккә этәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга аеруча кызыксынучанлык хас. Алар бигрәк тә табигатькә игътибар итәләр. Табигатьне күзәтү, аны өйрәнү, сакларга омтылу – балаларның рухи дөньясын баета, уйларга өйрәтә. Шуның өчен балалар бакчасында тирә-якны өйрәнү, табигатькә сакчыл караш, экологик тәрбия зур урын алып тора.

Экологик тәрбия бирүнең максаты булып түбәндәгеләр тора:

1. Тере һәм тере булмаган табигать, табигать күренешләре, үсемлекләр һәм хайваннар дөньсы турында белем бирү;

2. Табигатькә мәхәббәт, үсемлекләргә, төрле җан ияләренә сакчыл караш тәрбияләү;

3. Табигать кочагында үз-үзеңне дөрес тоту, җир-суны пычратмау, яшеллекне һәм җан ияләрен саклау кирәклеген төшендерү.

Тәрбияви бурычларны тормышка ашыру максатыннан балалар бакчасында бик күп кырлы эш алып барыла. Һәр төркемдә эколо- гик почмак булдырылды. Анда яшь үзенчәлекләренә туры килә торган гөлләр: бегония, алоэ, яран, традесканция утыртылды. Балалар һәр көнне гөлләрнең ничек үсүен, чәчәк атуын күзәтәләр, төпләрен йомшарталар, тузанын сөртәләр, су сибәләр. Шау чәчәктә утырган гөлләрнең матурлыгына сокланалар. Кышын тәрәзә төпләрендә суган үстерү, аның үсешен күзәтү балалар өчен бик кызык. Балалар табигать почмакларында бик теләп эшлиләр. Һәм бу эшнең нәтиҗәсе – бакчабыз шау чәчәктә утыра. Төрле тәҗрибәләр үткәрү дә балаларга бик ошый. Ел әйләнәсендә кошларны күзәтәбез. Җылы якка китүче кошлар, кышлаучы кошлар турында белемнәр туплыйбыз. Кышын «Кошларга җимлек» акцияләре оештырабыз. Бакчабызда үсеп утыручы агачларга җимлекләрне элеп, кошлар ашханәсе оештырабыз. Кошларны даими туклandырып торабыз. Саф һавага чыккач, балалар песнәкләрнең, чыпчыкларның ашаганнарын күзәтергә яраталар. Алар кошларны кызганалар. Ярдәм итәргә ашыгалар. Ә матур язлар җиткәч «Кошлар көне» үткәрәбез. Сыерчык ояларына конкурс була. Сыерчыкларның килүен, ояга мамык, үлән ташуларын, бала чыгарып аларны туендыруларын һәм бала очыруларын күзәтәбез. Матур итеп сайрауларын тыңлыйбыз. Урамнан кергәч, балалар күзәтүләрен рәсемгә төшерергә яраталар. Язын алар түбәдән тамчы тамуын, боз сөңгеләренең иртән һәм кичен ничек эрүен, беренче кара җирнең чыгуын күзәтергә яраталар. Балалар белән без табигать турындагы белемнәрне арттырып кына түгел, ә әйләнә-тирәне саклап калу һәм миһербанлылык сыйфатларын да тәрбиялибез. Табигатьтәге күңелсез үзгәрешләрне күрә һәм аларны уңай якка үзгәртергә тырышабыз. Балаларның иҗат итү сәләтләрен формалаштыру өчен төрле ысуллар кулланабыз: табигать

турында әкиятләр конкурсы үткәрәбез, икенчел калдык материаллардан (чүп-чар) киемнәр тегеп, төрле конкурсларда катнашабыз.

Балалар бакчасында гына экологик тәрбия биреп, ата-аналар тарафыннан ярдәм, алар белән аңлашып эшләү булмаса, уңай нәтиҗәләргә ирешеп булмый. Шуның өчен иң беренче чиратта табигатьне саклау, яклау үрнәкләрен без – зурлар үзебез күрсәтергә тиеш. Безнең үрнәктә, алган белемнәренә таянып, балалар кече яшьтән табигатьне аңлап һәм яратып үссеннәр иде.

## *Милли – катнаш гаиләдәтәрбия проблемасы*

***Зарипова Айгөл Мидһәт кызы,***
*Казан шәһәре ГБМБУ «94 нче гимназия»нең югары тегорияле ана теле һәм әдәбияты укытучысы*

Безнең Татарстан җирендә дә бик күп төрле милләт вәкилләре яши. Төрле дин, төрле милләт булган җирдә, әлбәттә инде катнаш гаиләләр дә күп корыла. Кемгә өйләнәсең, кемгә кияүгә чыгасың килсә, рәхим ит — ирек.

Нәрсә соң ул катнаш никах, катнаш гаилә? Бу турыда урыс лингвисты Владимир Дальнең «Аңлатмалы сүзлеге»ендә дә, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә бернинди мәгълүмат бирелми. Безнең аңлавыбызча, катнаш никах – ул ике милләт, ике дин вәкиленең парлашып, гаилә корып яшәве.

Сорау туа: милли катнаш гаиләләрдә тәрбия нинди булырга тиеш соң?

Катнаш никахтан туган балалар гомер буе кем соң мин дигән сорау белән җәфалана.

Бу проблема белән мин Казанда гимназиядә эшли башлагач ук кызыксына башладым. Бу тема минем өчен бик кызык булды. Күзәтүләрем төрле кызыклы нәтиҗәләргә китерде. Мин үземнең фикерләрем белән «Инфоурок» сайтындагы материаллар бастырдым.

2017 нче елдан безнең мәктәптә татар төркемнәре юк. Ләкин үземә укырга килгән балаларны күзәтү, гаиләләре белән якыннан аралашу матур гадәткә кергән. Катнаш гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның татар телен белү дәрәҗәсе дә, татар халкының гореф – гадәтләре, йолалары белән кызыксыну да төрле.

Үзем укыткан быел 1 класска укырга килгән 20 баланың гаиләсе белән якыннан таныштым. Гадәттә, без 1 сыйнфка укырга килгән балаларның

«Укучы карта»сын татар телендә тутырабыз. Шунда башлана инде танышу. Әлбәттә, тикшеренүләрем көтелгән нәтиҗәләргә китерде. 20 гаиләдә 15 баланың әтисе татар, 15е татар телен белмәү дәрәҗәсендә. Гаиләдә татарча сөйләшмиләр. Әниләре татар булган 5 бала татарча белә. Шуларның 3 сен тәрбияләүдә дәү әнинең өлеше зур. Шушы 5 гаиләдә 3 бала әнисенә «мама» дип дәшә.

Минем укучыларым арасында да Галиев Павел Талгатович, Хайруллин Дмитрий Айратович, Салахутдинова Ангелина Рустемовна кебек исемнәр бар иде. Хәзер исем белән фамилиянең ятышлы булып яңгыравына ата-аналар игътибарлырак була башлады. Рус фамилияле балага, әнисе татар булса да, рус исеме куяла. Мәсәлән, Андрей Лукага тормышка чыккан Ляйсән улына Максим дип исем куштырган. Ә Шайнуров Илдар белән гаилә корган Евгения улына Әмир исемен биргән. Әниләре татар булып, дәү әни тәрбиясендә үскән 3 бала татар телендә яхшы сөйләшә. Ләкин Лука Максим Андреевич, Павлов Матвей Леонидович татар егете, СемягинаАлиса Дмитриевна татар кызы дип санап була микән?!

Гадәттә, ике милләт кешесе корган гаиләдә, кемнең милләт генетикасы көчлерәк, шуныкы өскә чыга, дигән фикер белән килешәм. Ләкин минем практикада(25 ел рус мәктәбендә татар теле укытам) бары 2 гаилә генә бу сүзләрне акладады.

Гаяз Исхакый – беренче әсәрләреннән үк милләт язмышын беренче планга чыгарган реалист язучы. Шул исәптән, XX гасырның башында ук инде ул татарның рус милләте тарафыннан йотылу ихтималы хакында чаң суккан әдип.

Татарстан ЗАГС мәгълүматларына караганда, ә, 2019 елда Татарстанда 24 мең пар төркәлгән. Һәр 5 нче пар милли катнаш гаилә. Милләтара гаилә коручылар арасында иң күп санны татар белән урыслар арасындагы никахлар тәшкил итә. Аннан соң татар белән чуашлар һәм башка милләтләр килә икән.

Катнаш никах – бик четерекле мәсьәлә, ул хисләргә бәйле. Ә хисләрне законнар белән тыеп, ниндидер кысаларга куып кертеп булмый. «Татарлык сәясәттән түгел, гаиләдән килә».

Нишләргә соң?

Минемчә, һичшиксез, татарлар бары тик татар гаиләсендә генә тәрбияләп була. Гаилә һәм бала тәрбиясе нигездә хатын-кыз кулында. Баланың үз туган телендә сөйләшүе дә, анда милли аң формалашу да әтиәниләренә бәйле.

Шулай ук милләт чисталыгын саклап калуда дин зур урын алып тора.

# *Сәләтле балалар белән туган тел*
# *һәм әдәбияты буенча эшчәнлек төрләре*

***Зарипова Алсу Рәшит кызы,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 89 нчы мәктәпнең туган тел*
*һәм әдәбият укытучысы*

Хәзерге вакытта дөресен әйтергә кирәк, рус мәктәбендә укучыларны татар телендә аралашырга өйрәтү – гаять катлаулы, шуңа күрә без татар төркемнәрендә укучыларга татар телендә аралашуга өйрәтүнең уңай юлларынын тәкъдим итәргә теләдем. Югарыда китерелгән фикерләр проект эше темасының **актуальлеген** дәлилли.

Эшемнең **максаты** –татар телен туган тел буларак өйрәнүче сәләтле укучыларны үз телебездә аралашырга өйрәтүдә эш төрләрен күрсәтү.

Максатыма ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

– укыту процессында коммуникатив компетенциянең тоткан ролен ачыклау;

– укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерү максатыннан кулланылган эш төрләрен ачыклау;

– кулланырга мөмкин булган эш төрләренә күзәтү ясау.

**Тикшеренү объекты** – рус мәктәбенең татар төркемнәрендә укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерүдә биремнәр.

**Тикшеренү предметы** – сәләтле балаларның коммуникатив компетенция үстерү максатыннан кулланылган эшчәнлекнең төп төрләре.

Яңа стандартларның нигезендә әзер белем бирү генә түгел, укучыларның тикшеренү һәм эзләнү процессында үзләренең белем алулары тора. Биремнәрнең төп төрләре:килешә яки килешмәвен күрсәтеп сөйләшер, бәхәсләшер өчен кызыклы темалар тәкъдим итү, рәсемгә нигезләнеп андагы булган вакыйгалардан алдан яки моннан соң нәрсә булачагына диалог, монологлар төзү, сорау-анкеталар төзү. Үзбәя би- рер өчен укучылар бер-берләренә сораулар әзерләргә мөмкин, доклад- лар әзерләү, чыгыштан соң тыңлаучыларның сорауларына җавап бирү, дебатлар(татарча яхшы сөйләшүче укучылар өчен), өрле темаларга дискуссияләр оештыру, төркемнәрдә эшләү, ситуатив күнегүләр, эвристик әңгәмә, рольле уеннар һ. б., проблеманы чишү – коммуникатив биремнәрне чишү, проектлар. Балаларны туган тел белән кызыксындыруда, аларны туган телләрендә аралашырга, үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп җиткерә, үз җавабын дәлилили белергә өйрәтүдә дә коммуникатив биремнәрнең роле гаять зур.

Мисал итеп, эшнең бер төрен тәкъдим итәм.

Бу эш төрләрен **мини проектлар** дип тә атарга мөмкин.

1. Үзеңне мәктәп газетасының корреспонденты итеп күз алдына китер. Сезнең газетада «Минем башкалам» исемле рубрика бар. Газетага бистә сүзе кергән атама турында мәкалә яз.

2. Казан шәһәренең картасына мөрәҗәгать ит. Үзең яши торган районда һәм шәһәребезнең тарихи үзәгендә урнашкан берәр туры урамны ата. Сыйныфташларыңа үзәктәге урамга ничек барасын аңлат.

3. Белгәнегезчә, Иске Татар бистәсен реставрацияләделәр. Бистәгә барып фотографияләр яса һәм «И Казан, нурлы Казан..» дигән сыйныф сәгате өчен виртуаль экскурсия әзерлә.

4. Үзеңне атаклы төзүче дип күз алдына китер, сине мәктәпкә балалар белән очрашуга чакырдылар.

5. Текстка нигезләнеп бу профессиянең һәрвакытта да кызыклы һәм актуаль икәнен исбатла.

6. Иске урамнарны төзекләндерергә һәм сакларга кирәклеген искәртеп, «Сабантуй» газетасы редакциясенә мәкалә языгыз.)

Шулай итеп, без татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кулланылучы кайбер эшчәнлек төрләрен карадык. Алар барысы да балаларын аралашырга өйрәнү юлында актив кулланылырга тиешле эш төрләре. Бу биремнәр сөйләмне яхшыртуга гына юнәлдерелмәгән. Алар зуррак мәгънәгә дә ия. Нәкъ менә аралашканда баланың иҗади мөмкинлекләре ачыла һәм яхшыртыла. Бу төр биремнәр дөньяны танып белергә өйрәтә һәм аңа үзенең мөнәсәбәтен күрсәтә. Укучыларның әзерлекләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, дифференциаль якын килүне дә кулланырга була. Шуңа күрә бу коммуникатив эшчәнлек төрләре татар теле дәресләрендә мәҗбүри компонент булырга тиеш. Һәрбер эш төре темадан чыгып сайланырга тиеш. Шул очракта гына ул телне өйрәнү процессында уңай нәтиҗәләр бирер дип ышанып әйтергә мөмкин.

# *Федераль дәүләт белем стандартлары шартларында туган телне үстерүдә проблемалар һәм перспективалар*

**_Зарипова Дания Фирдүс кызы,_**
*Казан шәһәре «85нче мәктәп»туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге көндә күңелне борчыган мәсьәләләрнең берсе – туган телебез -татар теленең киләчәге, үсеше. Мәгариф өлкәсендә эзлекле үзгәрешләр барган хәзерге чорда сыйфатлы белем бирү зур әһәмияткә ия. Чөнки ул укучыларның интеллектуаль, иҗади, һөнәри үсешен тәэмин итә. Мәгълүм ки, бала мәктәптә һәр фәнне дә бертигез үзләштерә алмый. Укытуның эчтәлеген, укучылар эшчәнлеген оештыруның оптималь формаларын куллану, дөрес алымнар сайлау көткән нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтелгән. Туган тел дәресләренең иң мөһим бурычлары: укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү; укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык иҗади шәхесләр итеп тәрбияләү, дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү; телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү. Бүгенге көндә һәр татар баласының үз телен югалтмавын теләсәк, аңа борынгы бабаларының кем булуын аңлатырга, тарихын тиешенчә өйрәтергә кирәк дип саныйм. Балаларда туган телгә, сәнгатькә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү укытучыдан зур тырышлык сорый. Безгә, укытучыларга, моны онытмаска кирәк. Укучыларның туган телләрен яратуларын, гореф-гадәтләребезне хөрмәт итүләрен белү-күрү – үзе бер куаныч. Ана телен өйрәнүне «мәшәкать өстенә мәшәкать өстәү» дип санаучылар менә шушы хакыйкатьне истән чыгара һәм үзләрен артка сөйри. Тел-милләтнең җаны. Ул үлсә, милләт тә яшәми. Аны сакларга, кадерләргә кирәк. И туган телем, син яшәсәң генә татар милләте яшәр, тормышның да яме-гаме артыр. Милли телне күтәрү өчен төрле юллар бар. Ул матбугат-нәшриятны киңәйтү, радио-телевидение аркылы аралашу, кәгазьләрне татар телендә алып бару, төрле милләт кешеләрен татар теленә өйрәтү. Татар мәктәпләре һәм рус мәктәпләре тулысынча татар китаплары белән тәэмин ителгән. Булганны саклап калдырыйк. Тел бит әле ул милләтнең сакчысы да. Туган тел мәсьәләсе иң актуаль, иң җитди социаль, сәяси-иҗтимагый проблема булып тора. Чөнки тел– халыкның бөтен яшәү гомерендә тапкан иң кадерле зиһен байлыгы.

# *Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр*

***Зәйнәгетдинова Флүзә Фәрит кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы 169нчы мәктәпнең туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Педагогик технологияләрне төрле аспекттан якын килеп, төркемнәргә бүлеп өйрәнергә мөмкин. Фәндә бик күп төрле классификацияләр мәгълүм. Һәр галим диярлек бу җәһәттән үз классификациясен тәкъдим итә. Һәр педагогның да өстенлек биреп кулланган педагогик технологияләре булуы сер түгел. Әмма бары тик төрле технологияләрне оста чиратлаштырып эшләгәндә генә укыту нәтиҗәле булачак.

Идарә итү һәм уку процессын оештыру нәтиҗәлелегенә нигезләнгән технологияләр баланың мөстәкыйль яки төркемнәрендә башкарачак иҗади биремнәрне җәлеп итеп уку процессын оештыруны күз алдында тота (уен, проект һ. б.). Шул ук вакытта укучыларның биремнәрне укытучы җитәкчелегендә башкарулары, интеллектуаль эшчәнлек продуктын булдыру, максаты булган процесска җәлеп ителүләре дигәнне аңлата. Бу технологияләр түбәндәгеләр: Л. һәм Б. Никитиннар методикасы, проблемалы укыту технологиясе, коммуникатив укыту технологиясе,В. Ф. Шаталовның белем бирү моделе, уен технологияләре, интерактив укыту технологиясе (модерация технологиясе), проектлы укыту технологиясе.

Бу технологияләрукучыларның үз-үзен тикшерү дип аталучы үсеш һәм шәхси күрсәткечләр санын рациональ киметү хисабына укучыларның эшләү катлаулылыгы дәрәҗәсен күтәрүне күз алдындатота торган технологияләр. Аларга түбәндәгеләр керә: программалаштырылган укыту технологиясе, перспективалы укыту технологиясе,В. В. Фирсовның мәҗбүри нәтиҗәләр нигезендә укытуның дәрәҗәсен дифференциацияләү технологиясе, И. Н. Закатав, В. Д. Шадриков, И. Э. Унт, А. С. Границкаяларның балалар мәнфәгатьләре буенча дифференциацияләнгән укыту технологиясе, В. К. Дьяченконың коллектив укыту ысулы.

Компьютер технологияләре – заманча компьютер һәм башка техник чараларны куллану нигезендә мәгълүмат җыю, тапшыру, туплау, эшкәртү, саклау һәм куллану ысуллары системасы (Г. К. Селевконың компьютер технологияләре нигезендә укыту, гипертекст технологияләре, «Логомир» программа мохите технологиясе, мультимедиа технологияләре, ТВ-технология, дистанцион укытуның мәгълүмати технологияләре).

Хәзер мәктәп, укыту һәм тәрбия системасы бала шәхесендәге эшчәнлеккә кирәкле сыйфатлар булдыру мәсьәләсе белән тирәнтен шөгыльләнә. Бу системаның төп максаты – шәхес тәрбияләү, кечкенәдән үк баланы шәхес итеп күрү, аның сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү. Татар телен яңа технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү. Метод һәм алымнарны сайлау укучыларга тәкъдим ителгән материалның эчтәлегеннән, укытуның конкрет этабыннан, укучының сөйләм мөмкинлегеннән, яшеннән, акыл үсешеннән һәм яңа сөйләм, тел материалын үзләштерүгә карата кызыксыну дәрәҗесенә бәйле. Укыту процессын активлаштыру һәм интенсивлаштыру максатыннан проект, уен, кейс технологияләре түбәндәге очракларда файдаланыла: 1) фәнне өйрәнүдә мөстәкыйль технология; 2) нинди дә булса технологиянең бер состав өлеше; 3) дәрес яки аның бер этабы (кереш өлеше, яңа теманы аңлату яки ныгыту, күнегүләр эшләү яки контроль эш һ. б.); 4) дәрестән тыш эшләр технологиясе. Уен технологиясен башлангыч сыйныфта ук актив куллана алсак, урта һәм югары сыйныф укучылары белән проект, кейс технологияләрен куллану уңышлы.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, укыту процессында яңа педагогик технологияләрне кулланууукытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Әгәр укытучы дәрестә күрсәтмәлелекне җитәрлек дәрәҗәдә файдаланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре, инновацион коммуникатив технологияләр, интернет-ресурс элементларыннан кулланса, ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк.

# *Балаларның сөйләмен үстерүдә бармак уеннарының әһәмияте*

***Зиганшина Рамилә Рамилевна,***
*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган 134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

*Мин уйныйм, син дә уйна.*
*Бармак белән тыпырда.*
*Дуслар белән уйна бергә,*
*Читтә генә утырма.*
*Ф. Сахбутдинова*

Балаларны кул чукларын һәм бармакларын хәрәкәтләндерергә, җитезлекне арттырырга өйрүнүдә « бармаклы уен»нар зур урын алып тора. Бу хисле – тойгылы һәм мавыктыргыч уен. Ул әйләнә – тирәдәге чынбарлыкны, әйберләрне, җәнлекләрне, кешеләрне, аларның эшчәнлеген, табигать күренешләрен чагылдыра. Мондый уеннар барышында балалар, өлкәннәр ни эшләсә, шуны кабатлап, кулларын тиз-тиз хәрәкәтләндерәләр һәм бу җитезлекне арттыруга уңай йогынты ясый. Соңыннан сүзләрне үзләре өйрәнеп бетергәч, балаларга уйнавы тагын да күңелле була.

Баланың мәктәпкәчә яшьтәге чоры – тирә-юньне йотлыгып өйрәнү, күп кичерешләрне үзенә туплау һәм кеше шәхесе формалашуда иң мөһим чор. Баларның физик һәм психик яктан сәламәт булулары өлкәннәрнең йогынтысы бик зур роль уйный.

Бармак уеннары баланың акыл, фикер эшчәнлеген үстерүдә, дөньяны танып белергә өйрәтүдә бәя биреп бетергесез тәрбия чыганагы, чөнки әлеге уеннар аша бала әхлакый – этик кагыйдәләр белән дә танышa башлый. Бармак уеннары – өлкәннәр белән балаларның үзенчәлекле аралашу, күңел ачу чарасы. Бишек җырлары баланы тынычландыру,юату өчен кулланылса, бармак уеннары, киресенчә, баланың күңелен күтәрү, кәефен яхшырту, көлдерү чарасы булып тора. Ул баланың бармак хәрәкәтләре үсешенә дә ярдәм итә. Балаларның психикасын өйрәнүче галимнәр «бармак хәрәкәтләре үсеше нормада була» дип саныйлар. Димәк, бармакларның сөйләм үсешенә дә тәэсире зур. Бармаклар белән төрле күнегүләр ясау, аларны төрлечә хәрәкәтләндерү – баланың сөйләмен үстерүдә уңай шарт булып тора. Әлеге күнекмәләрне инде балага алты-җиде ай вакытты башларга кирәк. Моңа кул чукларының һәр

өлешен бик яхшылап массажлау кирә. Аларны язу, сыйпау көн саен ике-өч минут дәвам итәргә тиеш. Күнегүләр дә бик гади – турайтып уйнау. Алар һәр көн 2-3 минут дәвамында ясарга кирәк.

Безнең халыкта бармак уеннары да бик күп бит. «Атка печән кем сала?», «Качкан бармакны тап!», «Тычкан-төлке чабышы». Аларның кайберләрен уйнаганда без җырлар җырлыйбыз, такмак-такмазалар әйтәбез. Сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-бер артлы бөгеп барабыз. Әгәр балалар өчен күнегүләрне башкару кыен икән, өлкәннәр, бармаклар тиешсез вакытта бөгелмәсен өчен, аларны тотып тора.

Карга – килер казан асар,
Торна – тоз асар,
Саескан килер– салма салыр,
Чыпчык килер – төшерер.
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
(баш бармакны селкетәбез)
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимерер.
Кети, кети, кети!
(уч төбен кытыклыйбыз)

Балаларның бармакларын ныгыту өчен «Бармак театры» оештыру бик файдалы. Тик шуны истә тотарга кирәк: бармак уеннары биш минуттан озаграк булмасын, бу аның сөйләм функциясен стимуллаштыру өчен бик җиткән.

Кул чукларының хәрәкәтен үстерү язу хәрәкәтләренә, рәсем ясарга әзерлек эше дә әле ул. Кул һәм бармаклар хәрәкәтләрен үстерү өчен үз массаж, сурәтләү сәнгате шөгыльләре (әвәләү; рәсем; аппликация; кул хезмәте; кәгазьдән, картоннан, агачтан, тукымадан, җептән кул эшләре), шнурлау, төймәләү кебек эшләр уңай йогынты ясый. Бармакларның хәрәкәтчәнлеген үстерү буенча эшне даими рәвештә алып барырга кирәк, чөнки шул вакытта гына ул файдалы була. Күнегүләр балаларны ардырмаска һәм күтәренке кәеф белән эшләнергә тиеш.

Галимнәр әйтүенчә, бармакларның вак мускулатурасының хәрәкәтчәнлеген үстерү буенча системалы эшләү сөйләм телен үстереп калмый, ә баш миенең эшчәнлеген дә үстерә һәм балаларның хәтере, игътибарлылыгы, ишетү, күрү сәләте дә яхшыра.

# *Дәресләрдә PISA, PIRLS критерийларына нигезләнеп, укучыларның белемнәрен бәяләү*

**Зиннурова Н. З., Фәрхетдинов И. М,**
*Казан шәһәре Абдулла Алиш исемендәге*
*20 нче гимназия укытучылары*

Белем бирү, белем дәрәҗәсен тикшергәннән соң укучыларда аңлап эшләү, кирәкле материалны эзләп таба алмаулары ачыкланды. Һәм соңгы вакытларда PISA, PIRLS критерийлары дигән сүзләрне укыту- чыларга еш ишетергә туры килә. Без дәресләрдә, укучыларының аңлап уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бу критерийларга нигезләнеп тикшерү эшләре башкарабыз. Биремнәр берничә дәрәҗәдә бирелә, без өченче дәрәҗә биремгә тукталабыз.

*Бәяләү критериясе: интеграцияләү, интерпретацияләү.*

Өченче дәрәҗә биремнәре югары дәрәҗәдәге абстракция, фи-кер йөртүдә мөстәкыйльлек һәм күзаллау, текст буенча уйлануларны күздә тота. Бу дәрәҗә биремнәренә текст эчтәлеген интерпретацияләү аңлату, ачып бирү, йомгаклау һәм бәяләү тора. Укучы автор тарафыннан турыдан-туры әйтелмәгән бәйләнешләрне таба һәм аларны текстның гомуми идеясенә туры китереп аңлата; текст асты, ягъни «юллар арасында» яшеренгән мәгълүматны таба, гади метафоралар белән белдерелгән мәгълүматны аңлата; текстның мәгънәсен яисә аның төп идеясен ачыклый; төрле текстлардан алынган мәгълүматны һәм үз белемнәрен гомумиләштерә һәм аларны реаль тормыш ситуацияләренә карата куллана. Өченче дәрәҗә индикаторы булып укыганны аңлата, аңа бәя бирә белү, ягъни концептуаль мәгълүматны – төп мәгънәне, автор фикерен – табу; белем һәм тәҗрибә кулланып, иҗади характерда зур булмаган үз текстыңны төзи белү кирә.

3 сыйныфта Рөстәм Мингалимнең « Яшел күзле әнкәем» хикәсе буенча тикшерү эше үрнәге.

Хикәяне укырга, түбәндәге биремнәрне үтәргә.

ЯШЕЛ КҮЗЛЕ ӘНИЕМ (хикәядән өзек).

1. Текст нәрсә турында? Дөрес җавапны сайлап яз.

1. Әниләр турында. 2. Наилнең дуслары турында. 3. Авыл турында.

2. Әнкәйнең күзләре нәрсәгә охшаган? Дөрес җавапны сайлап яз.

1. зәңгәр күлләргә 2. яшел талларга 3. кара төймәгә.

3.»Мин һаман ак кышларның да яшел күзләрен күрәм» җөмләсендә астына сызылган сүзтезмә нәрсә була? Дөрес җавапны күрсәт.

1. Эпитет. 2. Сынландыру. 3. Чагыштыру.

4. «Мин сабый чагымны сагынып авылыма кайтам» җөмләсендә астына сызылган сүзләрне нинди сүзләр белән алыштырырга мөмкин?

5. Безнең бакча башындагы елга тагын да саеккан... Сез бу җөмләне ничек аңлыйсыз? Аңлатып языгыз.

6. Малай әнисенең яшел күзле икәнен кайчан аңлый?

7. Ни өчен элек баланы бишектә тирбәткәннәр?

8. Ни өчен малайлар үзара сугышып киткәннәр? (ике сәбәбен аңлатырга)

9. Уенчыклар сүзендәге – уен тамыр сүз нәрсәне аңлата?

10. Текста син элек белмәгән, ишетмәгән сүзләр очрый. Әмма текстны укыгач аларның мәгънәсен аңлап була.

Беренче баганада сүзгә икенче баганадагы аңлатманы тап, туры килгән санын күрсәт.

1) Әрәмә А) Яланда, күбесенчә су буйларында, уйсу җирләрдә үскән вак куаклык Б) Куе урман В) Су буе

11. Кайсы җавап текстның эчтәлегенә туры килә? Җавапны билгелә.

1) Без малайлар белән беркайчан да бәхәсләшми идек.

2) Наилнең әнисенең күзләре яшел.

3) Мин сабый чагымны сагынып авылга кайтам.

4) Безнең бакча башында тирән елга ага.

12. Түбәндәге хикмәтле сүзләрнең кайсы укылган әсәргә туры килә? Дөрес җавапны билгелә.

а) Ана күңеле балада, бала күңеле далада. (татар халык мәкале)

б) Ана күңеле шәфкать диңгезе. (татар халык мәкале)

в) Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас. (татар халык мәкале)

г) Сөямен чын күңел берлән үземнең эткәм-энкәмне, -

д) Алар олуг, алар матур, алар дөньяда иң ямьле. (Мәҗит Гафури)

13. Автор хикәясе белән нәрсә турында сөйләргә теләгән? Дөрес җавапларны сайлап ал.

1. Туган авыл турында. 2. Яшьлек турында. 3. Бала белән ана арасындагы мәхәббәт турында. 4. Матурлык турында.

14. Бирелгән өзекне укы. Анда нәрсәне төзәтергә кирәк? Өзектә шул хатаны сызып куй. Җөмләне дөресләп язып куй.

*Бәхәсләшеп, ул көнне без сугыштык. Ярый әле шунда безне эзләп су буена әниләребез килде. Барыбер, аларның иң матуры минем әнкәй иде. Минем әнкәй, кара күзле әнкәем...*

15. Бәхәстә кем җиңә? Сез ничек уйлыйсыз, бу бәхәстә җиңүче булырга мөмкинме? Үз фикерегезне аңлатыгыз.

Бу типтагы тикшерү эшләре, укучылар өчен авыр булса да, алар фикерләргә, кирәк материалны сайлап алырга, информацияне кулланырга өйрәнәләр.

## *SEL технологиясе алымнарын кулланып, укучыларның эмоциональ интеллектын үстерү*

***Каримова Алина Халитовна,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 23 нче лицей укытучысы*

Бүгенге көндә интеллект дәрәҗәсе IQ белән берлектә EQ emotionalquality күрсәткече белән күбрәк кызыксыналар. Эмоциональ интеллект – кешенең үзенең һәм башкаларның да хисләрен аңлый, контрольдә тота, шул нигездә аралашуны оештыра алуы. Галимнәр фикеренчә, кешенең тормышта уңышлы булуы 20 % кына белемнән һәм интеллекттан, ә 80 % ы эмоциональ интеллектның үсеш дәрәҗәсеннән тора.

Кызганычка каршы, наушник киеп, планшет экранына текәлгән балалар яңгыр шавын, кошлар сайравын, кар шыгырдавын ишетмиләр, кызарып кояш баюын, тәңкә карлар явуын, яшь үләннәр шытуын күрмиләр дә. SEL технологиясе шушы проблемалардан чыгу юлларын күрсәтә.

Әсәрне анализлаганда без игътибарны образ, символларга юнәлтәбез. Бу вакытта кластер алымын куллану бик уңай. Бу алымны татар теле дәресләрендә теманы гомумиләштереп кабатлаганда куллану бик уңай. Ул белемнәрне системалаштырырга, гомумиләштерергә ярдәм итә һәм схема формасында укучыларның хәтерендә кала.

Форсайт – ул социаль технология (сессия), коммуникацияләр форматы, ул катнашучыларга киләчәк образы турында сөйләшергә, шулай ук киләчәкнең теләгән образын билгеләргә мөмкинлек бирә. Функциональ грамоталылыкка өйрәтү максатыннан, бу ысулны мин еш кулланам.

Әсәрдәге образларны яхшырак аңлау өчен, йөрәк аша уздыру өчен «Тойгылар тартмасы» алымын куллану бик отышлы. Бу алымны әдәбият дәресләрендә геройларга характеристика биргәндә яратып кулланам.

«Аббревиатура» алымы укучыларның туган тел буенча белемнәрен арттыра, сүзлек запасын баета.

Предметара бәйләнешне дә онытырга ярамый. Бу очракта «Морфемалы конструктор» алымы миңа ярдәмгә килә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә SEL технологиясе алымнарын куллану укучыларны мотивлаштырырга, кызыксындырырга ярдәм итә. Иң мөһиме: бу алымнар укучыларның эмоциональ интеллект үстерә, һәм алар үзләренең, дусларының, башкаларның да хис-тойгыларын, кичерешләрен, эмоцияләрен аңларга, тоярга, тоемларга, күрергә өйрәнәләр. Шуның нәтиҗәсендә, без изге күңелле кешеләр тәрбиялибез.

## *Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә заманча технологияләр («Диаманта» алымы)*

***Корбанова Люция Әнвәр кызы,***
*Саликиева Валентина Михаил кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы 169 нчы ГУББМ*

Заман мәктәбенең төп бурычы – сыйфатлы белем бирү. Чыгарылыш укучылары алган белемнәрне рациональ файдаланып, мөстәкыйль фикер йөртеп, дөрес юл сайларга тиеш. Ә моның өчен бүгенге көн укытучысы предмет буенча яңалыклар, үзгәрешләр белән танышып барырга, яңа метод һәм алымнарны, эш ысулларын даими өйрәнергә тиеш. Чөнки хәзерге укучыны үзең укыткан предмет белән кызыксындырырга кирәк. Укытучының татар теле дәресләрендә нәтиҗәле алымнарны тиешле дәрәҗәдә куллануы укучыларның татар телен өйрәнүгә ихтыяҗын һәм теләген тудыра, укучыларның әлеге предмет буенча мөстәкыйль иҗади эшчәнлеккә өйрәтә.

Дәрестә уңай мотивация тудырмыйча, укучының актив, аңлы эшчәнлегенә ирешеп булмый. Дәреснең һәр этабын кызыклы итү, укучыларны җәлеп итәрлек итеп оештыру мөһим.

Белем бирү системасында тәнкыйди фикерләү төшенчәсе стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камилләшүен ассызыклый. Тәнкыйди фикерләү – ул мәгълүматны аңлап кабул итү, объективлык хас булган интеллектуаль эшчәнлек төре. Тәнкыйди фикерләү технологиясенең төп критерийлары:

Беренчедән, укучы белән укытучы арасында киртә, «барьер» юк. Алар әңгәмәдә, укыту эшчәнлегендә икесе дә тигез хокуклы, субъект- субъект мөнәсәбәтендә.

Икенчедән, укытучы мәгълүмат чыганагы түгел, ә юнәлеш, юл күрсәтүче буларак карала. Ул укыту эшчәнлеген кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештыра.

Шулай итеп, тәнкыйди фикерләү технологиясе буенча төзелгән дәресләр ФДББС таләпләренә тулысынча туры килә. Бу инновацион технологиянең төп үзенчәлеге – специфик, махсус алымнарында. Синквейн, диаманта, фаразлар агачы, балык кылчыгы, алты эшләпә, ыргытылган таш, зигзаг. Хәзерге чыгышыбызда «Диаманта» алымына тукталырга булдык. Бу «Синквейн» алымының бер төре. Диамант француз теленнән кергән сүз, «бриллиант» дигәнне аңлата. Формасы бриллиантны хәтерләтә. Диаманта – җиде юлдан торган шигырь, беренче һәм соңгы юллары капма-каршы мәгънәне аңлата. Аның ярдәмендә ике төшенчә арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләргә мөмкин. Диамантаны язу тәртибе:

1нче юл. 1 исем (тема).

2нче юл. 2 сыйфат (теманы ачыклау)

3нче юл. 3 фигыль (эш, хәл, хәрәкәт)

4нче юл. 4 исем (ассоциация)

5нче юл. 3 фигыль (капма-каршы эш-хәл, хәрәкәт)

6нчы юл. 2 сыйфат (капма-каршы теманы ачыклау)

7нче юл. 1 исем (капма-каршы тема)

Язучыларның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгәндә бу алымны куллану бик отышлы килеп чыга. Мәсәлән, Абдулла Алишның «Каз белән Аккош» әсәрен өйрәнгәндә һәм батырлык темасына сөйләшкәндә без түбәндәге диаманталарны төзедек.

I. Аккош баласы

Яхшы, булдыклы

Ашый, эчә, үсә

Ашаган малда өмет бар.

Ашамый, эчми, үсми

Ялкау, кире

Каз баласы.

II. Абдулла Алиш

Батыр, горур

Көрәшкән, сатылмаган, иҗат иткән

Батыр үзе үлсә дә, исеме кала.

Сугыша, алдый, үтерә

Усал, явыз

Фашист.

«Диаманта» алымы иҗади сәләтне үстерергә, үз карашыңны булдырырга өйрәтә. Мондый иҗади эш башкару – җиңел, күңелле, файдалы. Һәм иң мөһиме диаманта төзү укучыдан, уку материалында иң мөһим

элементларны табуны, йомгак ясауны һәм шуны берничә сүз белән, кыска итеп, әйтеп бирүне таләп итә.

Шулай итеп, тәнкыйди фикер йөртү технологиясе шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр чыгара. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята. Бу акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә.

## *Татар әдәбияты дәресләрендә текст белән эшләү. Проблемалар һәм чишү юллары.*

***Мәҗитова Айгөл Локман кызы,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 23 нче лицейның беренче категорияле туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы*

Мин үз эшчәнлегемдә интеграцион якын килеп укытуга еш мөрәҗәгать итәм. Интеграцион якын килеп укыту ул – укучыга дөньядагы бар әйбернең дә бер-берсе белән бәйләнештә торуын аңларга ярдәм итә, укучыларны күреп күзаллау процессына махсус әзерли.

Һәр дәрестә текст белән еш эшләргә туры килә. Кызганычка каршы, укучылар текстның эчтәлегенә тиешле дәрәҗәдә төшенеп җитә алмыйлар. Иң беренче чиратта һәр укучының күреп күзаллавы төрлечә икәненә төшенү мөһим.

Укытучының максаты– материалны һәр укучы аңларлык итеп җиткерү. Текст өстендә эшләү уңышлы барсын өчен, тиешле этаплар узарга, билгеле бер алгоритм булдырырга кирәк.




Текстны кулыбызга алуга без нәрсәгә игътибар итәбез? Әлбәттә, фонга, сүзләнең нинди шрифт белән язылуына. Икенче чиратта, текстның мәгънәсен аңларга тырышабыз. Өченче чиратта – текстны гомуми струк-

тура итеп кабул итәбез. Димәк, күреп күзаллау процессы түбәндәге тәртиптә башкарыла:

– Текстны күреп күзаллау процессы:

– Текстны бербөтен структура итеп кабул итү

– Текстның мәгънәсен аңлау

– Текстны тамга/билгесе, формасы, фоны буенча күзаллау

Бу этаплар эзлекле башкарылган очракта гына, текстны күреп күзаллау уңышлы барачак. Презентацияләр ясаганда төрледән-төрле төсләр куллану, рәсемле фоннар ясау, бер слайд эченә бик күп материал урнаштыру – еш очрый торган хаталар. Шул хаталар укучыларга текстны бербөтен структура итеп кабул итүгә комачаулыйлар.

Текстның мәгънәсен аңлау процессы башкачарак корылган. Иң беренче чиратта текстның гомуми мәгънәсен эзлибез. Текст өстендә эшли башлаганчы ук, проблемалы сорау куябыз. Укучы бу текстны ни өчен укыганын, аннан ни көткәннәрен белергә тиеш. Икенче чиратта, хәреф-сүз-җөмлә өлешенә игътибарны юнәлтәбез. Өченче чиратта, текстны аңлауга ирешәбез. Моның өчен укучыларның җавапларын тыңлыйбыз. Аларның җавапларын бербөтенгә туплап, дөрес нәтиҗә ясыйбыз.

Димәк, бирелгән текстның эчтәлегенә төшенү, күреп күзаллау һәм аңлау арасында кире бәйләнеш булганда гына уңышлы була.

**Күреп күзаллау һәм аңлау арасындагы бәйләнеш:**




Текст белән эш татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә генә түгел, башка фәннәрдә дә, имтиханнар вакытында да, гомумән алганда, тормышта бик еш очрый. Текстның эчтәлегенә төшенеп җитә алмау аркасында күңелсезлекләргә очрамас өчен, күреп күзаллау һәм аңлау арасындагы бәйләнешне истә тотып эшләү мөһим.

# *Туган телгә өйрәтү шартларында интеллектуаль һәм иҗади сәләтле балалар белән эшнең заманча алымнары*

***Нәбиева Г. М., Акбирова Г. М.***
*Туган тел һәм әдәбияты укытучы, ГБМБУ «78 нче лицей «Фарватер», Казан*
*Тәрбияче, МБМББУ «Катнаш төрдәге Балтач 1 нче балалар бакчасы», Балтач*

Заман уку – укыту эшчәнлегенең барлык тармакларына үзгәрешләр кертә. Мәгариф өлкәсендәге җитди үзгәрешләр, укыту программаларын, төрле эш алымнарын сайлап алу мөмкинлеге фәннәрне тирәнтен өйрәнү һәм балаларның табигый сәләтен үстерүгә юл ачты.

Мөгаллимнәр укучылар белән эшләгәндә берничә принципны күздә тотырга тиешләр.

Аларның беренчесе – укучыларның белем үсеше дәрәҗәсен бик тиз һәм төгәл билгеләү һәм шуның белән бәйләнешле рәвештә, дәресләрнең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләп сайлап алу.

Икенчесе – дәрестә дифференциале укытуны фәнни нигездә гамәлгә ашыру, үсеш дәрәҗәләре һәм әзерлекләре төрлечә булган укучыларның тиешле белем алуына ирешү, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү.

Өченчесе – дәрестә укытучы-укучы дуслыгын тагын да нәтиҗәле итү юлларын табу.

Акыл сәләтен эшкә җигү – шулай ук хәл итәсе мәсьәләләрнең берсе. Бу – туктаусыз алга бару мөмкинлеге тудыру дигән сүз.

Сәләтле балалар белән эшләгәндә нинди алымнар кулланыла һәм аларның нәтиҗәлелеге нинди?

Терәк схемалар (конспектлар) – үзара нык бәйләнештәге сораулар яки тема буенча кыскача нәтиҗәләр системасы ул. Алар укучыларга теманы аңлату алдыннан өләшенә һәм балалар укытучы сөйләгәннәрдән җавап эзлиләр яки тема нәтиҗәләрен таба баралар. Әлеге конспектларда көчлерәкләр өчен текстлы биремнәр яки өстәмә сораулар бирелә. Мондый укытуның уңай нәтиҗәсе бар. Сәләтле балалар да, уртача белем алучылар да биремнәрне бик теләп үтиләр, сорауларга җавап табалар. Шулай итеп аларның белеме тирәнәя.

Эшләү методларыбызның тагын берсе – кроссвордлар. Кросс- ворд чишү-җиңел эш. Ә аны төзү – авыр, катлаулы; укучыдан тырыш- лык һәм эзләнү сорый. Сүз төркемнәрен, җиләк-җимеш, яшелчә, кош- корт, җәнлек, агач исемнәрен өйрәнгәндә укучылар кроссвордларны бик рәхәтләнеп төзиләр. Аларны төзегәндә табышмаклар куллану тел дәресләрен әдәбият дәресләре белән бәйли. Әлеге кроссвордларны халык авыз иҗаты әсәрләрен үткәндә куллану яхшы нәтиҗә бирә. Шулай ук сочинение язу, шигырь, хикәя, экиятләр уйлап чыгару укучыларның иҗади фикерләү дәрәҗәләрен үстерә, сүзлек запасын баета, сөйләм телләрен үстерә.

Шактый еллар инде мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадалар үткәрелә. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүнең дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелгән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли. Теманы тулысынча ачып бирү өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенең дәлилләрен күп галимнәрнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: дәресләрдә кулланылган эш алымнары (карточкалар белән эш, рәсем, картиналар буенча иҗади эшләр, компьютерда эшләү, мультфильмнар төзү) – барысы да укучыларның сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән. Бары тик үз эшеңне чын күңелдән яратып, вакытыңны кызганмыйча эшләсәң, сәләтле балалар тагын да зур уңышларга ирешәчәк һәм калган укучылар арасында сәләтле балалар саны, һичшиксез, артачак, әлбәттә.

# *АбдуллаАлишәкиятләре буенчатөшерелгәнмультфильмнарның балалар карашынформалаштырудагы роле*

***Нәҗметдинова Гөлкәй Замир кызы,***
*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия*
*һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

«Балалар һәм телевидение» проблемасы ата-аналарны да, педагогларны да борчый. Хәзерге вакытта һәр бала өчен уенчыклар яки китаплар телевидение булып тора. Телевидение баланың җанын һәм акылын формалаштыра, аның тәмен һәм әйләнә-тирә дөньяга карашын тәрбияли. Эчке дөньяны формалаштыруда: уеннар, әкиятләр, уртак дәресләр, шул исәптән телевидение тапшырулары да зур роль уйный. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, нигездә, тәрбия чарасы булып мультфильмнар тора.

Барлык балалар да мультипликация белән әсир ителгән. Аларның күбесе уеннан баш тарта, барысын да оныта, бары тик телевизор каршында гына утыра. Шуңа күрә уңай яки тискәре карашларны тикшерергә кирәк, аларның балаларда үз-үзләрен тоту, фикерләү һәм характер формалаштыруга тәэсир итә.

«Мультипликация» термины Латинча «multiplicatio» сүзеннән – тапкырлану, арту, үсү, үрчү дигәнне аңлата.

«Анимация» сүзе – «animation» Француз сүзеннән «җанлану» дигәнне аңлата.

Танылган балалар язучысы А. Алишның мультфильмнарын аңлы тормышның башлангыч чорларында шәхес, балалар өчен ярдәмче буларак карыйбыз.

Абдулла Алиш балалар һәм олылар өчен үз әкиятләрен язган. Аның татар телендәге әкиятләре татар әдәбияты хәзинәсенә нык кереп калган. Аның әсәрләре балалар тарафыннан яратып кабул ителә. Язучының «Сертотмас үрдәк» әкиятен күпләр балачактан хәтерли. Абдулла Алишның татар телендә язылган «Сертотмас үрдәк» мультфильмы мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителде. Бу мультфильм сүзгә тугрылык, коллективизм һәм намуслылык кебек әхлакый принципларны аңларга ярдәм итә. Анда ахмаклык һәм талымлык күренә, шул исәптән хезмәт сөючәнлек һәм зирәклек сизелә. Ул безнең игътибарны үз-үзен һәм дусларын куркыныч астына куймас өчен, серләрне сакларга кирәклегенә юнәлтә. Шул рәвешле, «Сертотмас үрдәк мультфильмы балаларны бик

сак булырга һәм таныш булмаган кешеләр белән сөйләшергә ярамаганлыгы турында уйларга кирәклеген өйрәтә.

2015 елда «Татармультфильм» берләшмәсе тарафыннан «Койрыклар» әкият-риваяте анимацион фильм мавыктыргыч формада хайваннарның ни өчен төрле койрыклары һәм алар ничек барлыкка килүе турында сөйли. Мультфильмдагы җиңел һәм нәфрәтсез формада ялкаулык һәм җавапсызлык кебек кеше җитешсезлекләре күтәрелә. «Койрыклар» мультфильмы тамашачыларны битараф калдырмый. Күпләр караудан соң заманча татар мультфильмнары турында күбрәк белергә, ә әбиләр һәм бабайлар балачакларын искә алалар.

Абдулла Алишның әкиятләре татар әдәбияты хәзинәсенә нык кереп калды. Аның әсәрләре төрле буын балалары тарафыннан яратып ка-бул ителә. Ул үзенең әкиятләрендә хайваннар образларын файдаланып, кеше кимчелекләрен күрсәтә. Язучы Абдулла Алишның «Куян кызы» әкиятен күпләр балачактан хәтерли. Татар телендә шул исемдәге муль- тфильм кыш көне җылы итекләр белән йөрүдән баш тарткан һәм моның ничек килеп чыгуы турында сөйли. Ул балаларны өлкәннәрне тыңларга һәм үз сәламәтлеген кайгыртырга чакыра. «Куян кызы» балаларны ата-аналарын хөрмәт итәргә, дөреслекне генә сөйләргә өйрәтә. Мультфильм мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен татар телен өйрәнү өчен тәкъдим ителә.

Мультфильмнарны өйрәнеп һәм Абдулла Алиш әкиятләрен укып, алар ярдәмендә балалар уен һәм күңел ачу формасында җәмгыятьнең төп тормыш кыйммәтләрен һәм әхлак нигезләрен өйрәнәләр. Танылган татар язучысының мультфильмнары ярдәмендә кеше үсешенең башлангыч чорында шәхеснең социальләшүе һәм формалашуы башлана. Абдулла Алиш әкиятләре буенча төшерелгән мультфильмнар кайбер тормыш мизгелләрен аңлатырга; ел фасыллары бер-берсен ничек алмаштыралар; сәгать циферблатында вакытны ничек аерырга өйрәнергә; без табигать күренешләре турында нәрсә белүебезне; нәрсә ул «яхшы», ә нәрсә ул «начар» икәнен аңларга ярдәм итә.

Мультфильмнар балалар үсешенә һәм тәрбиясенә уңай йогынты ясый, әмма бу төр белем бирүнең берничә төп нюансы бар. Ата – аналарга, укытучыларга мультипликация картиналарын җентекләп сайларга, балаларның бары тик уңай эмоцияләр генә алуын кайгыртырга кирәк. Шулай ук балаларны мультфильмнар карау белән генә кызыксындырырга ярамый, белем бирүнең һәм дөньяны танып белүнең төрле вариантларын сайларга кирәк (музейларга, театрларга бару, әдәбият уку).

Шулай итеп, уку фильмы – дөрес эшләнгән куллану методика- сы ярдәмендә баланың коммуникатив һәм социомәдәни компетен- циясен үстерүгә, табигый тел мохитен торгызуга һәм үсеп килүче буынның танып-белү эшчәнлеген дәлилләүгә ярдәм итә торган медиа чара. Мультфильмнарның төп максаты – балаларның сөйләмфикерләү эшчәнлеген активлаштыру.

## *Заманча технологияләрне куллану туган (татар) телне укыту процессын тагын да нәтиҗәлерәк итә*

***Нигъмәтуллина Тәнзилә Хәмзә кызы,***
*ТР Балтач муниципаль районы*
*«Балтач урта гомуми белем мәктәбе » татар теле*
*һәм әдәбияты укытучысы*

*«Балаларыгызны үзегезнең заманагыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманагыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр», дип язган күренекле мәгърифәтче*

Ризаэтдин Фәхреддин.

Заманча технологияләр белән эшләү, укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Шуны истә тотып, дәресләремдә укучыларның үз эшчәнлегенә зур игътибар бирәм, белем алуга уңай караш формалаштыру өчен шартлар тудырырга, шәхескә юнәлтелгән алым һәм технологияләр кулланып, белем сыйфатын яхшыртырга тырышам. Мин үземнең эш тәҗрибәмдә түбәндәге заманча технологоияләргә мөрәҗәгать итәм: тәнкыйди фикерләү, уен, компьютер, проблемалы укыту һәм проект технологияләре.

Уеннар файдалану укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Уен технологиясен яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда, сөйләм телен үстергәндә кулланырга мөмкин. 5-6 сыйныф укучыларының психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, белемнәрне ныгыту, гомумиләштерү дәресләрендә уен (рольле, эшлекле, иҗади һ. б.) технологиясенә зур урын бирәм. «Сүз ясалышы дөньясына сәяхәт», «Фонетика буенча викторина», «Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү», «Могҗизалар кыры», «Тамчы шоу» кебек уен-дәресләр дә үткәрәм,

дәреснең бер өлешендә генә үткәрелә торган «Чылбыр», «Дөрес-дөрес түгел», «Көчсез буын» һ. б. уен элементларын да укучылар яратып кабул итә.

Мәктәптә эшли башлаган елларымда ук М. Мәхмүтовның проблемалы укыту методына өстенлек бирдем һәм хәзер дә кулланам, бүгенге заманча технологияләрнең күбесенең нигезендә шушы метод ята дип уйлыйм. Шундыйлардан Д. Б. Эльконин һәм В. В. Давыдовның үстерелешле укыту технологиясе, минемчә, укучыларда белем алуга кызыксыну уяту, эзләнү ихтыяҗы тудыру, иҗади активлыкны үстерү кебек мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итә. Үстерелешле укытуның төп принциплары: укытуда проблемалылык, фәнни фикерләү формалаштыру, укучыларның психологик үзенчәлекләрен исәпкә алу, укучының уку эшчәнлегендә актив катнашуы, укучыда укырга теләк уяту, укытуны дифференцияльләштерү һәм шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алу, катлаулы биремнәрне дә чишәргә өйрәтү.

Рус телле аудиториядә татар телен укыту нигездә коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Минемчә, коммуникатив компетен- ция формалаштыру максатына ирешүдә Р. З. Хәйдәрова дәреслекләреиң отылышлысы. Мондагы коммуникатив-ситуатив күнегүләрнең төрле дәрәҗәдә, әмма аерым бер дәрес кысаларында барысының да өйрәнелә торган темага юнәлтелгән булуы укучыларның шәхси мөмкинлекләрен искә алырга, үстерергә, куелган максатка ирешергә мөмкинлек бирә. Дәреслек яңа технологияләр кулланып эшләүне күз алдында тота, укытучыга үзенең иҗади мөмкинлекләрен файдаланырга мөмкинлек бирә. Бу дәреслекләр белән укучыларны сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә дә өйрәтергә шартлар тудырылган.

Шулай ук тәнкыйди фикерләү технологиясен кулланганда, дәрестә бала белемне әзер килеш кенә алмый, үзенең эшчәнлеге нәтиҗәсендә (билгеле, укытучы ярдәме белән) эзләп таба.

Бигрәк тә тәнкыйди фикерләү технологиясенең «Шакмак», «Интеллектуаль карта», «Идеяләр кәрзине» алымнарын дәресләрдә куллану кулай.

Иҗат – үсеш өчен иң көчле этәргеч. Һәр балада нindидер сәләт бар һәм укытучының бурычы – шуны кечкенәдән күреп алып, алга таба үстерү. Акыл, ихтыяр көче, хыял һәм фараз итү, уңай эмоцияләр, үзеңне һәм әйләнә-тирә дөньяны танып белергә омтылу – боларның барысына да иҗади эш нәтиҗәсендә ирешелә. Укучыларымның иҗади бәйгеләрдә, татар теле һәм әдәбияты буенча район, республика, халыкара олмпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә еш катнашуы һәм җиңүе, газета-журналларда язмалары басылу – хезмәтнең нәтиҗәсе.

# *Развитие мелкой моторики – залог правильной и красивой речи*

***Павлова Лейсан Наильевна***
*учитель-логопед, МБДОУ «Рыбно-Слободский детский сад «Березка» Рыбно-Слободского муниципального района*

В детстве, когда ребенок активно растет, когда формируются и совершенствуются все системы в его организма, закладываются основы здоровья и гармоничное развитие.

Все движения организма и речевая моторика имеют один механизм, поэтому развитие тонкой моторики положительно влияет на речь ребенка. У детей с задержкой речевого развития часто наблюдается недостаточная сформированность двигательной сферы, в том числе плохая координация мелкой моторики. Учеными проведено очень много исследований, в ходе которых доказано, что у детей с хорошо развитой мелкой моторикой, хорошо развита и речь.

Развивать мелкую моторику необходимо с самого раннего возраста. С первых дней жизни, тренировкой мелкой моторики является массаж кистей. Его можно делать с прибаутками, песенками. При массаже используются следующие приемы: поглаживание, легкое растирание и вибрация. Массаж не должен вызывать у ребенка неприятные ощущения. Простые движении рук убирают не только напряжение, но и снимают умственную усталость. Различные исследования показали, что каждый палец имеет представительство в коре головного мозга. Развитие мелкой моторики предшествует проявлению артикуляции слов. Благодаря развитию пальчиков, в мозгу формируется проекция схемы человеческого т ела, а речевые реакции находятся в прямой зависимости от их тренировки.

Для положительного воздействия на организм, ребенка нужно научить координировано и ловко манипулировать пальчиками. Необходимо обращать внимание на овладение ребенком простыми, но очень важными умениями– держание чашки, ложки, карандаша и т. д.

Помимо массажа можно использовать пальчиковые игры или пальчиковую гимнастику. Очень важно, чтобы и игры и гимнастика проходили в веселой, игровой атмосфере. Если ребенок будет воспринимать все, как обузу, то очень быстро потеряет интерес. Оптимально, в ходе игры использовать стихи, потешки, прибаутки, считалочки– любой фольклорный материал.

Гимнастика для пальчиков рук делится на два вида. Это пассивная гимнастика и активная гимнастика. Пассивная гимнастика идет как предварительный этап, затем следует перейти к активной гимнастики. Это пальчиковые игры. Важно помнить, что сложность игр должна выбираться взрослым и зависеть от уровня развития тонкой моторики рук. Чтобы пальчиковая гимнастика была максимально интересной, приятной и в то же время эффективной, нужно стараться строить игру поэтапно:

1. для начала взрослый должен продемонстрировать игру ребенку сам;
2. показать движения, манипулируя пальцами и кистью ребенка;
3. попытаться вместе с ребенком выполнить движения одновременно, по мере необходимости помогая малышу;
4. попросить ребенка выполнить движения самостоятельно во время проговаривания текста взрослым;
5. всегда нужно хвалить ребенка, даже если у ребенка получается плохо и неуклюже.

Постепенно все это перерастает в жизненно необходимые навыки, укрепляются пальчики ребенка, делают их послушными и умными. И все это в совокупности доставляет очень большую пользу речевому развитию ребенка.

## *Балалар бакчасында милли тәрбия бирүдә газета чыгаруның мөһим аспектлары*

**_Сабирҗанова Гөлфирә Гомәровна,_**
*Казан шәһәре Киров районының*
*«Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган*
*134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

Әлеге мәкаләдә ни өчен нәкъ менә газета аша милли тәрбия бирү һәм әлеге иҗади эшне балаларның әти-әниләре белән берлектә башкару соравына җавап биреп карарбыз.

Эштән соң баласын алырга ашыгып килгән әти-әни – тәрбияче сөйләгәннәрне ничек кабул итә һәм өйдә, иркенләп газета аша танышканда, ничек кабул итә? Минемчә, икенче вариант күпкә отышлырак та, файдалырак та – әти-әниләр өчен дә, без – тәрбиячеләр өчен дә.

Икенчедән, газета чыгаруда тәрбияче генә түгел, ә турыдан-туры балалар, әти-әниләр үзләре дә катнаша, ягъни күмәк эшкә йөз тотабыз. Ә бу

исә араларны тагын да якынайта, үзара ышаныч хисен арттыра, дуслык атмосферасы булдыра. Тәрбияче белән балалар турында гына түгел сүз, ә тәрбияче белән ата-атаналар мөнәсәбәте хакында да.

Иҗадилыкка ирек биргәндә, газетада:

* тәрбияченең әйтергә теләгән фикере аерым рубрикада,

* балаларның бакчадагы тормышы аерым биттә – фотолар белән булырга мөмкин,

* әти-әниләрнең теләк-тәкъдимнәре ирекле рәвештә шулай ук аерым рубрикада урын алачак.

Балалар белән эшләгәндә, уйнаганда, дәресләр белән шөгыльләнгәндә, «Әйдәгез, тырышып ясыйк әле, әти-әниләрегез газетадан күргәч, сезнең белән горурланырлык булсын» дип, балага өстәмә мотивация тудыруга да этәргеч була газета чыгару эше.

Газетаны ай саен чыгарырга мөмкин. Бу эшне тәбияченең айлык планына туры китереп башкарырга мөмкин. Һәр газетаның бер төп темасы булсын, мисал өчен, «Яңа ел», «8 Март бәйрәме», «Өлкәннәр көне» һәм башкалар. Ә алга таба эчтәлекне югарыда санап үтелгән рубрикалар белән тулыландырабыз. Әлбәттә, әти-әниләр өчен яңалыклар, фотолар, игъланнар да урын алачак.

Газетаның төп максаты – ата-аналар ярдәмендә балаларга милли тәрбия бирү. Бу эштә халык педагогикасы һәм татар мәгърифәтчеләре иҗатын кулланып, аларны әти-әниләргә җиткерү.

Газета чыгарырга керешкәнче, әти-әниләр белән мастер-класс уздырып алырга мөмкин. Аларның да теләк-тәкъдимнәрен ишетергә кирәк. Алга таба төркемнең үз газетасын чыгара башлау өчен нигез булып тора әлеге күмәк эш.

Эшне газетага исем сайлаудан башларга кирәк. Мисал өчен, «Тәрәзә» дип исем кушарга мөмкин. Тәрәзә ачылгач, бар дөнья күренә – тәрәзә артындагы дөнья. Ягъни бакча тәрәзәсе артында ниләр майтарыла, нинди эшләр башкарыла – шуларга күзәтү кебек булсын газета. Тәрәзәләрнең капкачлары була. Бу хакта балаларга аерым дәрес үткәрү мөмкинлеге дә килеп чыгачак: балаларны халкыбызның милли бизәкләрен кулланып ясаган хәзер инде сирәк очрый торган тәрәзә капкачлары белән таныштыру, әлеге темага рәсем ясарга мөмкин. Тәрәзә капкачлары дигәч тә, бөек шагыйребез Габдулла Тукай иҗатына мөрәҗәгать итми калып булмый. «Карлыгач» шигырен балаларга да өйрәтергә мөмкин, ә аның бер куплетын газетаның исеме астына бер девиз кебек куярга мөмкин:

«Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
Оя итте минем сөйгән Карлыгачым.

Ул көн буе аузы берлән балчык ташый,

Балчык берлән матур итеп оя ясый».

Газетаның исеме янына карлыгач рәсемен куярга мөмкин. Балалар әнә шул тырыш карлыгачлар кебек күз алдына киләләр. Көне буе алар да балалар бакчасында тырышып шөгыльләнәләр: язарга, хәреф танырга, рәсем ясарга өйрәнәләр, физик тәрбия дәресләре үтәләр.

Алга таба әзерләргә кирәкле темалар карала. Теманы, әлбәттә бакчада уздырылачак төрле чаралардан, бәйрәмнәрдән, яңалыклардан һәм куелган бурычлардан чыгып сайлана. Мисал өчен, төп теманы өлкәннәр көне дип алсак, һәр баланың әби-бабалары турында мәгълүмат, фотолар, балалар үзләренең әби-бабаларын рәсемгә төшерә һ. б.

Үзебезне чын редакциядәге кебек хис итеп, «Тәрәзә» газетасын чыгарырга алынганбыз икән инде, димәк хезмәт бүленешенә дә кагылмый булмый. Һәр кешенең үз эше булырга тиеш: язучы, фотограф, корректор, редактор. Бу эштә, әлбәттә, балалар да катнаша ала. Ничекме? Әйтик, дизайн өлкәсендә. Әйе-әйе, балаларга сораулар биреп, без алар өстенә җаваплылык йөклибез. Балалар кечкенәдән «Минем фикерем дә мөһим» дип уйласыннар. Мисал өчен, әби-бабайларын сурәтләгән рәсемнәрне алар ничегрәк – кайсын кая урнаштырыр икән?!

Алга таба аерым рубрикалар өчен җаваплы кешене билгеләргә мөмкин. Эш барышын тәрбияче күзәтә, җаваплылык аның җилкәсендә. Эшнең нәтиҗәсе – балалар редакциясе матур, күркәм, кызыклы газета чыгара. Иң мөһиме, күмәкләшеп эшләү, аралашу, бер-береңне ишетергә, аңларга өйрәнү. «Тәрбияче-бала» мөнәсәбәтләре, шулай ук «тәрбияче-әти-әни» мөнәсәбәтләре тагын да җайланачак. Иҗади мөмкинлекләрне тагын да җәелдерергә мөминлек – яңа идеялар, максатлар белән, әти-әниләр тарафыннан газетаның яңа санын чыгарырга мөмкин.

Кайчак әйтергә теләгән фикерне җиткереп бетереп булмый, балалар арасындагы шау-шу, уен атмосферасы һәм башкалар. Алда язып үткәнчә, газетада язылганнарны әти-әниләр бөтенләй башка шартларда – өйдә, тынычлыкта укый һәм кабул итә. Шунлыктан, балалар бакчасында газета чыгару эше барыннан да элек әти-әниләргә файдалы.

# *Мнемотехника – балаларны туган (татар) теленә өйрәтүдә педагогик технология*

***Сабирова Лилия Равил кызы,***
*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган 134 нче номерлы балалар бакчасы» МББМБУ*

*«Балага аның өчен билгеле булмаган нинди дә булса биш сүз өйрәтегез – ул бик озак һәм заяга интегәчәк; шундый егерме сүзне рәсем белән бәйләп өйрәтегез – һәм бала аларны шунда ук отып алачак...»*

К. Д. Ушинский

Мнемотехника – грек теленнән тәрҗемә иткәндә, «истә калдыру, хәтер үстерү технологиясе» дигәнне аңлата. Ул – балаларның әйләнә-тирә мохит, табигать күренешләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү, баету, хикәянең эчтәлеген яхшылап истә калдыру, әлбәттә, бәйләнешле сөйләмне үстерү өлкәсендә кулланыла торган методлар һәм алымнар системасы.

Күрсәтмә модельләштерү технологиясенең бурычлары: туган телдә монологик сөйләмне үстерү, актив сүзлек запасын баету, яңа сүз ясау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә төрле җөмлә конструкцияләре куллануны формалаштыру һәм камилләштерү, предметларны тасвирлау һәм чагыштыру, хикәя төзү; күзаллау, игътибарлылык, фикерләү, ишетепһәм күреп сөйләү эшчәнлекләрен үстерү; балаларның вак моторикасын үстерү.

Монологик сөйләмне үстерү максатында, төрле символлар, пиктограммалар, схемалар куллану истә калдыруны җиңеләйтә, хәтерне яхшырта, гомумән, балаларның уйлап сөйләү эшчәнлеген үстерә.

Мнемотаблицалар – сөйләм телен үстерү буенча дидактик материал булып торалар; аларны сүзлек запасын баетканда һәм сөйләм телен үстергәндә кулланырга мөмкин; хикәя төзегәндә һәм әсәр эчтәлеген сөйләгәндә, шигырь ятлаганда һәм табышмакларга җавап эзләгәндә кулланырга мөмкин.

Мнемотехника структурасы:башта балаларны мнемошакмаклар белән таныштырабыз, анансоң мнемоюллар белән, шул рәвештә мнемотаблицалар килеп чыга.

Мнемотаблица – аерым бер мәгълүмати схема булып тора. Аның асылы шунда: һәр сүзгә яки кыска сүзтезмәгә аерым рәсем уйлана, шулай, схематик рәвештә, текст «языла», әлеге схема-рәсемгә карап, бала мәгълүматны җиңел генә истә калдыра.

Уртанчылар төркемендә мнемотаблицалар төсле сурәтләрдән тора, чөнки сенсор эталоннары формалаша һәм балалар хәтерендә аерым образлар кала.

Өлкәннәр төркемдә мнемотаблицлар аклы-каралы.

Тасвирлама хикәя төзү – ул монологик сөйләмнең иң авыр төре.

Предмет турында сөйләү өчен, аны аңларга кирәк, ә аңлау — ул анализлау. Әлеге эш бала өчен бик авыр бирелә. Монда баланы предметның билгеләрен аера белергә өйрәтергә кирәк.

Мнемотаблицалар ярдәмендә ел фасылларының сыйфатларын өйрәнеп була.

Мнемотаблицалар ярдәмендә сөйләгәндә, балалар анда катнашучыларның барысын да күрәләр, үзләренең сөйләмнәрендә җөмлә төзелешенә игътибар итеп (җөмләне дөрес итеп төзеп), билгеле бер эзлеклелекне саклап сөйлиләр.

Мнемотаблицаларны индивидуаль囲эштә, төркемчек һәм бөтен төркем белән берлектә шөгыльләнгәндә кулланабыз.

Мнемотаблицалар кулланып, без балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтәбез;сүз байлыгы арту өстенә, әйләнә-тирә мохит турында- гы белемнәре дә киңәя;сөйләп бирү теләге уяна, бала бу эшнең авыр түгеллеген аңлый;шигырь ятлау бер уенга әверелә. Бу балаларга бик ошый;мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерү эшендә бик отышлы алым санала.

Истә тотарга кирәк! Баланың сөйләм үсеше дәрәҗәсе аның сүзлек байлыгына бәйле. Бу юнәлештә ясалган берничә адым мәктәпкәчә яшьтәге баланың сөйләмен үстерергә ярдәм итә.

# *Милли мәктәпләрдә тәрбиянең үсеш юллары*

**_Садыйкова Гөлсинә Солтан кызы,_**
*Казан шәһәре Киров районы «3 нче татар телендә гомуми белем бирүче гимназия»сенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*Әхлак белән әдәбият бергә булырлар.*
*Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса,*
*әхлагы да шул рәвештә булыр*

Р. Фәхреддин

Язмамны бөек мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдин сүзләре белән башлавымның сәбәбе, без – укытучылар, киләчәк буынга ныклы белем биреп кенә калмыйбыз, ә шәхес тәрбиялибез. Шәхес тәрбияләүдә төп урынны әхлак тәрбиясе алып тора.

Бүгенге көндә тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләре күпләребезне борчый. Яшь буында кешелеклелек сыйфатларын саклап калу өчен бердәнбер юл, таяну ноктасы – әхлак тәрбиясе бирү. Балаларның, үсмерләрнеңүзара аралашулары, өлкәннәргә, әйләнә – тирәдәге кешеләргә булган мөнәсәбәтләре мине уйланырга, эзләнергә мәҗбүр итә. Шушы уйланулар мине:»**Укыту-тәрбия процессында әхлакый кыйммәтләр системасы аша укучыларда шәхес тәрбияләү**»дип исемләнгән методик тема өстендә эшләргә этәрде.

Дәреснең структурасы, тәртибе нинди генә булмасын, хәзерге заман дәресенең төп максаты – шәхес тәрбияләү.

Яманны яхшыдан аера белмәү, әхлак турында тискәре тәҗрибәләр туплау исә җәмгыятьтәге әхлак кагыйдәләрен бозуга, шәхси бәхетсезлеккә илтә. Менә шуңа күрә әхлак тәрбиясенең бурычларына аеруча игътибар итәргә кирәк дип саныйм. Үз алдыма түбәндәге бурычларны куям:

- ❑ Гомумкешелек сыйфатларын тәрбияләү;
- ❑ Укучыларда актив тормыш позициясе формалаштыру;
- ❑ Балаларда әхлакый-эстетик, экологик культура тәрбияләү;
- ❑ Милли гореф-гадәтләрне саклау, милли үзаң формалаштыру;
- ❑ Балаларны сәламәтлекләрен сакларга һәм ныгытырга өйрәтү;
- ❑ Гаилә белән элемтәне, хезмәттәшлекне ныгыту;

Әлеге бурычларны тормышка ашыруда, укыту – тәрбия процессын оештыруда яңа инновацион технологияләр кулланып эшлим.

# *Башлангыч сыйныфларда дәреснең нәтиҗәлеген арттыруда яңа технологияләр куллану*

***Сәгъдиева И. М., Гыйзатуллина Л. Ф.,***
*Казан шәһәре Совет районы «Абдулла Алиш исемендәге» 20 нче гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучылары*

Яңа методлар һәм технологияләр мәктәпкә җәмгыятьтә политик һәм социаль шартлар үзгәргәнлектән килеп керә. Мәктәпнең төп бурычы – иҗади шәхес үстерү һәм формалаштыру.

Шуны истә тотып, без үз эшебездә үстрешле укыту технологияләрен киң кулланырга тырышабыз. Укучыларның эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр: уен технологиясе, проблемалы укыту, аңлатмалы-күрсәтмәле технология белем бирү системасы мондый технологияләрдән.

Укучыларның еллар дәвамында акыл эшчәнлеге белән үзләштерелгән белемнәрне генә озак саклана, төпле һәм файдалы була. Белемнәрне үзләштерүгә теләк, омтылыш уяту, моның өчен кирәкле шартлар тудыру – һәр педагогның бурычы. Укучы актив катнашкан, укытучы аның активлыгын уңышлы оештырган дәрес кенә нәтиҗәле була. Шуңа күрә үз эшебездә уен технологиясен киң кулланырга тырышабыз. Өйрәнү процессында сюжетлы дәресләр үткәрелә. Мәсәлән: «Урманга сәяхәт», «Сәламәтлек аланында», «Әкияткә кунакка», «Спорт-тайм» һ. б. Ярыш рәвешендә дәресләр дә (викторина, КВН, уйлап табучылар конкурсы) уңышлы һәм кызыклы үтә. Яңа теманы өйрәнгәндә, кабатлау дәресләрендә түбәндәге уеннар кулланам: «Кем тизрәк?», «Сүзне тап», «Нәрсә юк?», «Чылбыр» һ. б. Укучыларга сүзле башваткычлар, шаян мәсьәләләр, шырпы ярдәмендә биремнәр, зирәклеккә мәсьәләләр үтәргә дә бирелә.

Шулай ук, терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту технологиясен дә файдаланабыз. Терәк схемалар, терәк таблица, сигналлар укучыларның танып-белү активлыгын үстерә, материалны үзләштерү һәм истә калдыру тәэсирен көчәйтә. 3 класста терәк таблицаларны укучыларның үзләреннән яздырып, сөйләргә өйрәтүгә төп игътибар бирәбез. Иҗади эшләткәндә вакытта терәк схемадагы мисаллар урынына үзләре мисал, мәсьәләләр тәкъдим итәләр. Схема буенча сөйләү өчен такта чнына берәм-берәм укучылар чакырыла. Бу очракта Шаталов методын кулланнылa.

Уку һәм татар теле дәресләрендә текстлар укуны фонетик зарядкалар белән чиратлаштырабыз. Дәрестә халык авыз иҗаты үрнәкләре – табышмак, тизәйткеч, санамыш, эндәшләр кулланыла. Уку тизлеген үстерү өчен

татар һәм рус теле дәресләрендә оператив хәтернең күләмен арттыру юнәлешендә эшлибез. Моның өчен күрмә диктантлар яздырыла.

Халык авыз иҗатын дәрестә төрле уеннар, кроссвордлар рәвешендә тәкъдим итәбез. Балалар үзләре табышмаклар, экиятләр уйлап чыгару белән иҗади шөгыльләнәләр.

Билгеле булганча, баланың акыл үсешенә аның китап яратуы зур йогынты ясый. Укучыларда текстны аңлап уку күнекмәләре формалаштыру өчен, яңа сүзләрнең мәгънәләрен ачу, сорау-җавап күнегүләре, сайлап уку, шулай ук тексттан төп фикерне аңларга һәм әсәрдә сурәтләнгән фактларга һәм күренешләргә карата үз мөнәсәбәтеңне билгеләргә өйрәтүче эшләр ярдәм итә.

Үстерешле укытуның яңа формаларын һәм методларын куллану миңа укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле оештырырга ярдәм итә. Укытучының һөнәри эшчәнлегендә эзләнү, педагогик иҗат өчен офыклар һәрвакыт җитәрлек, һәм тормыш үзе дә яңа технологияләрне куллануны таләп итә. Укучылар – безнең киләчәгебез. Аларны бүгенге базар мөнәсәбәтләре шартларында конкурентлыкка сәләтле, олы максатларга ирешү юлында информацион технологияләрдән оста файдалана белүче иҗади шәхес итеп тәрбияләү – безнең бурычыбыз.

## *Абдулла Алиш музееның уку компетенциясен формалаштырудагы роле*

**_Фәрхетдинова Элмира Мингазиз кызы,_**
*Казан шәһәре Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең директор урынбасары*

*«Телебез – рухи яктан берләштерүче зур көч», – дип белдерде президентыбыз.*
*Р. Н. Миннеханов.*

Балалар укый беләме? Әйе! Язылганны укый белә. Әмма һәр укучы текстның әһәмиятен аңлый, тиешле мәгълүматны таба алмый.

Яңа белем бирү стандарты укытучыларны мөһим бурычларны хәл итү кирәклегенә ишарәли: укучының уку компетентлыгын һәм уку мөстәкыйльлеген формалаштыру, укучы үзен иҗади эшчәнлеккә сәләтле икәнен аңлавы һ. б.

Укыту процессында педагогик технологияләрне куллану-уку процессының нәтиҗәлелеген күтәрүнең мөмкин булган юлларының берсе. Нәкъ менә педагогик технологияләрне куллану укуның нәтиҗәлелеген арттырырга, тәрбия бурычларын хәл итәргә һәм укучыда әйләнә-тирә дөньяны мөстәкыйль белүгә әзерлек булдырырга мөмкинлек бирә.

Гимназиядә 2017 елдан башлап, «Милли гимназия шартларында укучыларда культурологик компетенцияләрне формалаштыруда мәктәп музеның роле» инновацион проект эшләп килә. Әлеге проект кысаларында, түбәндәге эшләр ашырыла:

*Музей-кабинетлар ачылу.* Хәзерге көндә бездә «Алиш варислары», «Милли мирас», «Мәңгелек хәтер», «Иске татар бистәсе» музейлары эшли.

Музей белән эшчәнлек, дәресләр, укыту-тәрбия процессы белән элемтәне җайга салырга мөмкинлек бирә. Укыту-тәрбия процессында төрле алымнар һәм дәрестән тыш эш формалары кулланыла:

– музей дәресләре; семинарлар;фәнни-гамәли конференцияләр; эзләү һәм проект эшчәнлеге;

акцияләрдә катнашу һ. б.

Укучылар арасында «Яшь экскурсоводлар клубы» кебек эш формасы аеруча популяр. Яшь экскурсоводларга, текст өстендә эш дәверендә күп мәгълүмат җыярга туры килә. Алар сөйләү өчен текст әзерләгәндә бары тик кирәкле материалны сайлап алып, сөйләм нечкәлекләрен өйрәнеп, укучыларга шул мәгълүматны җиткерә белергә тиеш.

Музей материаллары – укучылар өчен үзе бер хәзинә. Төрле конкурслар, бәйгеләр үткәрелсә, укучылар музей материиалларын кулланалар, чөнки монда бай материал табып була. Шул ук вакытта, укучылар экспонатлар тарихын аерым өйрәнәләр, мәгълүмат җыялар, өстәмә материал укыйлар, кирәклесен сайлап алалар. Менә бу – уку компетентлыгын формалаштыру буенча эшнең бер юнәлеше.

Музейда кичәләр, чаралар үздырыла. Аларның һәркайсы халкыбызның гореф–гадәтләрен, йолаларын, буыннан-буынга күчеп килгән гүзәл сыйфатларын үстерүгә юнәлтелгән. Шулай ук, Абдулла Алиш исемендәге лауреатлар белән дә гимназиядә кызыклы очрашулар еш уздырыла. Ләбиб Лерон, Илсөяр Сөнкишева, Йолдыз Шәрәпова, Ленар Шәех һ. б. Алар очрашуга үзләре белән төрле истәлекле әйберләр, үзләре язган китапларны алып киләләр, музейда дәрестән тыш Укучылар чын язучылардан алган китапларны тагын да кызыксынып укыйлар. Очрашу вакытында әңгәмә, диалоглар оештырыла. Диалог ул коммуникатив чара (фикерләүне уртаклашу чарасы). Шуңа да аны, мөмкин кадәр,

реаль әңгәмә кору шартларына якынайтып эшләү, укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юлларының берсе дип саныйм.

Укучыларның уку компетентлыгын формалаштыру юнәлешендә әдәби музыкаль кичәләр, милли уеннар оештыру да отышлы.

Тема кысаларында гимназиядә «Күңелле тәнәфес» проекты гамәлгә ашырыла. Анда һәр сыйныф татар халык уеннарын тәкъдим итә. Уенны өйрәнү барышында аның тарихы, ничек уйналуы өйрәнелә. Укучылар үзләренең туган телендә җырлы-биюләр башкаралар, сүз байлыкларын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү күнекмәләре өстендә эшлиләр.

Минемчә, иҗади якын килү һәм традицион булмаган эш алымнары гына хәзерге заман укучысының актив уку позициясен формалаштыруга ярдәм итә һәм балаларда белем алуга кызыксыну уята. Укыган, туган телен белгән укучы гимназиядән олы тормыш юлына әзер шәхес булып чыга.

## *Татар әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр*

***Фахрутдинова Г. М., Зарипова М. Г.***
*Казан шәһәре Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Текстны тукталышлар белән тәнкыйди уку** укучыда әсәргә карата кызыксыну уята. Әсәрнең исеменә карап укучылар анда нәрсә турында сүз барганын билгелиләр. Әсәр өлешләргә бүленеп укыла, һәр өлеш укылганнан соң укучы сюжетның үсешенә, анда нәрсәләр булачагын фаразлый. Укытучы тукталышларның кайда булачагын алдан билгеләп куя. Дәрестә бу ысулны кулланганда түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк:

– текс укучыга таныш булмаска тиеш;

– текст алдан ук укытучы тарафыннан өлешләргә бүленә;

– текстка карата сораулар һәм биремнәр танып белү эшчәнлегенең иерархия дәрәҗәсеннән чыгып формалаша.

**Гади сораулар**. Бу сорауларга җавап биргәндә билгеле бер фактларны, мәгълүматны искә төшерергә кирәк булачак.

**Аныклауны таләп иткән сораулар**. « Ягъни син шулай дип әйтергә уйлыйсың... ? Мин дөрес итеп аңласам, син. .... әйтергә уйлыйсың? Минем аңлавымча, син. ....?

**Шәрехләүче сораулар(интерпретационные).** Нигә?, Ни өчен? сораулары ярдәмендә төзелә. Сәбәп– нәтиҗә бәйләнешен күрсәтә.

**Иҗади сораулар.** Әгәр дә.   ? Шартлылык, прогноз, күзаллауга корылган сораулар.

**Бәяләүче сораулар.** Вакыйгаларның, фактларның, күренешләрнең бәяләү критерияләрен билгеләүгә юнәлгән. Нигә битараф булу начар гамәл? С. Хәким иҗатының үзенчәлеге нидә?

**Практик сораулар.** Бу сораулар теорияне тормыш белән бәйләүгә юнәлгән. Мондый күренешләр тормышта очрыймы?

Ә. Еники «Бала» әсәрен өйрәнгәндә, «хис» һәм «бурыч» сүзләрен тактага язып куябыз. Укучылар индивидуаль, парда һәм төркемдә эшлиләр. Аларның эшчәнлеге эзлекле рәвештә, бер –берсен тулыландырып бара. Укучы әсәрдә бу ике каршылыклы төшенчәнең нигә бергә килгәнен аңлата. Җавапларга нигезләнеп, дәреснең темасы билгеләнә: « Ә. Еники «Бала» әсәрендә хис һәм бурыч каршылыгы». Җавап бирергә кыенсынган укучылар өчен бу эш төре бик уңай.

Өй эшенә текст буенча сораулар төзергә биргәндә, укытучы сорауларның «таза»(толстый»), «нечкә» («тонький») булуына игътибар итәргә куша. Көчле укучыларга «таза» сораулар төзергә, авырсынганнарга «нечкә». Бу ысул укучыларны сорау бирергә өйрәтә, аларның әсәрне ни дәрәҗәдә белүен, текстны аңлауын күрсәтә. «Нечкә» сораулар репродуктив характерда, ә «таза» сорау укучының текстка карата иҗади якын килүен, өстәмә мәгълүмат белән хәбәрдәр булуын, анализ алымнарын белүен дәлилли. [4]

**«Таза»** сораулар:

Презентациянең бер төре булган – **скрайбинг** (инглиз сүзе рәсем, эскиз) – мәгълүматны рәсем ярдәмендә тыңлаучыга җиткерү. Гади генә әйтсәк– укучы сөйләмен рәсемнәр белән тулыландыра. Күрсәтмәлелек һәм кызыксынучанлык алга чыга. Дәресне авыр үзләштергән, татарча сөйләме кытыршырак булган, кеше алдында чыгыш ясарга курыккан укучыларга мондый эш төрен тәкъдим итү татар телен өйрәнүгә мотивацияне артттыра. Скрайбингта тавыш эзлекле рәвештә рәсем белән параллель барганда, нәтиҗә арта. Укучының эшчәнлеге мөстәкыйльлек төсмере ала. Скрайбинг ясаганда, укучы тиешле мәгълүматны таба, аның белән таныша, төрле чыганаклар белән эш итә, анализлый һәм үз эшен тудыра. Мәсәлән Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил иҗатлары буенча скрайбинг төзеп, ярышлар да уздырырга була.

**Буктрейлер** – ниндидер китап яки әсәр турында сөйләүче аз вакытлы видеоролик. Максаты: әсәргә кызыксыну уяту, укучының игътибарын җәлеп итү. Вакыты 3 минуттан да артырга тиеш түгел. Яңа, классик әсәрләргә карата ясарга була. Дәрес яки класстан тыш уку дәресләренә

укучыларга ясарга тәкъдим итәргә була. Уку– укыту процессына проект эшчәнлеге нык кереп урнашты. Проект эшчәнлеген язучының тормыш һәм иҗатын өйрәнгәннән соң башкарыла. «Ризалашу картасы» (Карта согласия») проект эшчәнлеге буларак бирергә була «Т. Миңнуллинның уңай һәм тискәре геройлары». «Намуслылык – татар халкының гасырлар кичеп, безнең көннәргә килеп җиткән иң күркәм сыйфаты. (М. Каратеев. «Русь и Орда»). Шушы сүзләргә нигезләнеп, «Намуслылык» – проект буларак бирергә киңәш ителә.

9 сыйныф укучыларына проект методы белән эшләүне арадаш аттестация эше итеп бирү уңай күренеш дип саныйбыз. Ф. Кәрим, А. Алиш, Х. Туфанның «Кыр казы» исемле шигырьләре бар. «Шигырьләрдә Кыр казы образы» исемле проект уку елы башында тәкъдим ителә. Һәр укучы авторны үзе сайлый. Сәләтле укучыларга чагыштырма формада язарга киңәш ителә.

## *Образные средства в татарских народных сказках*

***Хазиева Алина Рушановна,***
*МБДДОУ «Детский сад № 134 комбинированного вида*
*с татарским языком воспитания и обучения»*
*Кировского района г. Казани*

Самый популярный жанр устного народного творчества – это сказка. Ни один народ в мире еще не обошелся без сказки, не является исключением и татарский народ. Татарская сказка, как зеркало, отражает всю самобытность культуры и жизни народа, его переживания, проблемы и историю.

Сказка по-татарски называется әкият. Некоторые представители старшего поколения называют сказку старым названием хикәят (по-арабски: рассказ, повесть).

Изучая и сопоставляя **татарские сказки** и сказки других народов, были сделаны выводы, что они не только являются отражением исторических условий жизни татар, их национальной психологии, быта, но и они включают в то же время основные сюжетные мотивы, которые присущи сказкам других народов. Особенно это заметно в самой структуре сказочного эпоса, здесь присутствуют обязательно сказки о животных, бытовые сказки, волшебные, приключенческие, а также мэзэклэр (народные анекдоты), юмористические и сатирические, поучительные и сказки-

притчи. Достаточно часто в одной сказке присутствует сопряжение как бытовых, так и героических мотивов, а в героических сказках можно увидеть элементы волшебства.

Основные герои этих произведений – дикие и домашние животные, птицы, пресмыкающиеся, рыбы, насекомые. Однако в татарских сказках о животных три последних вида непопулярны.

Сказки о животных являются одной из самых древних форм не только в жанре сказок, но и вообще в фольклоре.

Так как человек, даже отделившись от мира животных, в первые периоды жил в одинаковых с ними условиях, в одной с ними среде, в его мышлении большое место занимала связь с животными. Древний человек искренне верил, что присущие ему черты характерны также для животных. Он считал, что животные, как и он сам, умеют говорить и мыслить (антропоморфизм), даже полагал себя состоящим в родстве с ними.

Если по характеру конфликта сказки о животных разделяются на две группы, то по составу персонажей их можно подразделить на три группы: 1) сказки с героями в образе диких животных; 2) сказки с героями в образе домашних животных; 3) сказки с теми и другими.

Сказкам о животных особенно свойственна форма диалога. Этот приём оживляет сказку, обостряет интерес к ней. Форма диалога помогает лучше ощущать, яснее представлять реальную жизнь героев, естественную среду их существования.

Язык сказок о животных простой и образный. Образность достигается при помощи разных тропов. В сказке «Шах-Петух», например, есть интересные сравнения, подхалимки-курицы так хвалят своего вожака-петуха: «У тебя, султан, ноги, как железо, крепки», или: «У тебя, наш падишах, голос громче львиного». Разумеется, такие сравнения применительно к петуху не могут не вызвать улыбку.

Встречающиеся в сказках эпитеты по отношению к характеру животных приспособлены к нормам сказки: голодный волк; бестолковый волк; глупый волк; хитрая лиса; сильный конь; умная коза; храбрый, хитрый петух; добрый жеребец и т. д. Эпитеты часто применяются и при описании явлений природы: большой луг, зелёный луг, холодные ветры, толстое дерево, огромный дуб, широкая долина, ясные дни, холодная зима, белый снег, густая озимь и др.

В сказках, хотя и редко, встречаются метафоры: пересчитать рёбра (побить), красная шапка (окровавленная голова волка), красные штаны (волк, у которого окровавлена нога) и др. Последние две одновременно служат метонимией. Встречаются метафоры в форме перифраза: пресветлый падишах, ясный хан, дивный султан, светлый шах (петух).

В сказках о животных часто употребляется гипербола. Например, волк говорит лисе: «Сейчас я тебя зараз проглочу» («Коварная Лиса»). В сказке «Котан Иваныч» лиса говорит о коте: «А съедает он за раз одну овцу и одного быка». А в сказке «Медвежий сын Атылахметгәрей» герой «растёт, день за год, за двадцать пять дней стал двадцатипятилетним богатырём». Герой говорит о себе: «... не смогу, видать, среди людей жить. Если придётся ударить одного – пятеро погибнут».

Таким образом, образные средства в татарских народных сказках способствуют яркости речи, впечатляющему воздействию событий.

## *Укучыларны театр сәнгатенә җәлеп итүдә татар әдәбиятының роле*

***Ханнанова Миләүшә Хатиповна,***
*Казан шәһәре Идел буе районының «35 нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» МБГББУ татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*«... театр – үткәнне бүгенгегә,*
*бүгенгене исә киләчәккә*
*тоташтыручы рухи мәйдан...»*
Марсель Сәлимҗанов.

Әдәбият һәм театр – сәнгатьнең ике төре. Аларны икесенә дә хас Сүз төшенчәсе берләштерә. Театр коллективлары төрле яшьтәге тамашачыларны тәрбияләсә, без, укытучылар, тел һәм әдәбият дәресләре аша яшь буынны тәрбиялибез. Нинди генә фән укытучысы булуга карамастан, укытучы, иң беренче чиратта, үзенең аңлаешлы сөйләме, аралашу осталыгы, үз-үзен тотышы белән укучыларга үрнәк булырга тиеш.

Мәктәптә өйрәнелә торган драма әсәрләренең саны башка төрләргә караган әсәрләр белән чагыштырганда күпкә ким. Бу драма әсәрләрен өйрәнү өчен вакытның күп кирәк булуы белән аңлатыла. Сәхнәләштерү, төрле рольле уеннар – тел укытучыларының актив куллана торган алымы. Әлеге алым дәресне кызыклы һәм нәтиҗәле итә, пассив укучы-ларны да дәрескә тарта. Әдәбият дәресләрендә кайбер эпизодларны сәхнәләштерү әсәрләрне тирәнрәк аңларга һәм кабул итәргә ярдәм итә. Әлеге дәресләрнең максаты – укучыларның хәтерен, игътибарын, образлы күзаллау кебек сыйфатларын тәрбияләү; сөйләмнәрен төзек,

аңлаешлы итүгә омтылу; шулай ук коллективта үз үзләрен тоту, кыю- лык эшләү күнекмәләрен үстерергә ярдәм итү. Мәсәлән, рус мәктәбенең 9 нчы сыйныфында өйрәнелә торган Гаяз Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясендә Җан Баевичның музыкантлар, балалары белән аралашу эпизодын сәхнәләштерү геройга тулы характеристика бирергә, аның холкын аңларга ярдәм итә, тирән гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә. Әлеге эш алымы шулай ук укучыларны эстетик яктан тәрбияли. Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә.

8 нче сыйныфта өйрәнелә торган Г. Камалның «Беренче театр» комедиясен телевизор экраннарыннан карау комедия жанрына тулы аңлатма бирүгә ярдәм итә. Шулай ук, әсәргә анализ биргәндә, комедиянең эмоциональ ягын да көчәйтә.

Драма әсәрләрен рольләргә бүлеп укуга әзерлек йөзеннән, үземнең укуым, барыннан да бигрәк, магнитофон тасмасыннан спектакльдән өземтәләр тыңлау, укучылардан тоташ итеп кычкырып укыту да укуның башлангычы булып тора. Интернет челтәрләр аша артистларның сәнгатьле укуларын тыңлау укучыларда төгәл, аңлаешлы уку, сөйләм күнекмәләре булдыруга ярдәм итәләр.

«Бүген бездә кунак бар» рубрикасы астында үткәрелгән әдәбият дәресләрендә К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрының атказанган артистлары Зөлфия Вәлиева, Гөлчәчәк Хафизо- ва, шигырьне сәнгатьле уку буенча мастер класслар күрсәтеп, укучыларнымны театр сәнгатенә җәлеп итәргә ярдәм итәләр. Алардан алган осталыкның нәтиҗәсе – укучыларымның республика һәм шәһәр күләм «Шигырь укучылар» бәйгеләрендә призлы урыннар алуы.

«Драма сәхнәдә генә яши, аннан башка ул тәннән аерылган җан кебек», – дип язган Н. В. Гоголь. Димәк әлеге төр, укып кичерү өченнән бигрәк, карап кичерү өчен җайлашкан. Шуңа күрә дә без укучыларыбыз белән берлектә татар һәм рус театрларына даими культпоходлар оештырабыз. Ә бу үз чиратында укучыларда театр әдәбе, зәвык тәрбияләргә ярдәм итә. 11 нче сыйныфта өйрәнелә торган К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» әсәрен сәхнәдән карау укучыларда драманың сәнгатьчә эшләнешен күрергә ярдәм итә. «Театрдан соң туган хисләр» исемле дәрестән тыш чаралар, тәрбия сәгатьләре укучыларның театр сәнгатен яратуларын, аңа тартылуларын күрсәтә. Т. Миңнуллинның әсәрләрен укып, сәхнәдә караганнан соң, спектакльне куюда режиссёрның, артистларның роле турындагы әңгәмәләр укучыларда зур кызыксыну уята.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: сәхнә әсәрләре татар сөйләменә өйрәнү өчен укучыларга коммуникатив мотивация, уңайлы шартлар булдыра.

Театр сәнгате әсәрләрендә халыкның рухи тәҗрибәсе, гореф-гадәтләре, әхлак нормалары. Менә шундый гадәтләрне өйрәнү, белү, күңел белән кабул итү укучы балаларда гуманлы мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен тудыра, яңа гадәтләрнең, яңа әхлак нормаларының асылын аңларга, аларны чагыштырып-үлчәп карарга мөмкинлек бирә.

## *Дөнья гаме сыйган күңел*

***Хафизова Гөлнара Нургали кызы,***
*Арча районы Яңа Кенәр урта мәктәбенең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

Мәктәпләрдә балаларны дөрес итеп туган телебездә сөйләшергә, язарга өйрәтү, аларда татар теленә мәхәббәт уяту зур тырышлык сорый. Кызганычка каршы, атнага ике дәрес татар теле һәм бер дәрес әдәби уку дәресе укып әллә нәрсә эшләп булмый. Шуңа күрә без, башлангыч сыйныф укытучылары китап укуга мәхәббәт уятырга тиешбез. Соңгы елларда телефон, интернет тәэсире аркасында балаларның китап укуга, туган телгә карашлары үзгәрде. Татарча китап уку кызыксындыруны арттыру максатыннан, тәрбия сәгатьләрендә төрле татар язучылары иҗаты белән танышабыз.

2021 нче ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлегеелы. Шушы уңайдан Роберт Миңнуллин иҗатына тукталып, аның китапларыннан күргәзмә оештырдык. Сыйныфта аның шигырьләрен яттан өйрәндек, шигырьләренә карата иллюстрацияләр ясадык. Милләт, туган җир, туган тел турында язылган шигырьләрен укып анализладык.

«Дөнья гаме сыйган күңел» дип исемләнгән фәнни-тикшеренү эше чыганагы – Р. Миңнуллинның туган җир, милләт, тел турында иҗат иткән шигырьләре.

Тикшеренү эшенең **актуальлеге** һәм фәнни кыйммәте – Р. Миңнуллин шигырьләрендә туган җир, милләт, тел турында тәрбияви идеяларны, сөйләм телен үстерү үрнәкләрен тикшерүдә.

**Эшнең максаты –** Р. Миңнуллин шигырьләре аша туган җиргә, телгә карата хөрмәт, ихтирам, горурлык хисе тәрбияләү.

**Бурычлары:** 1)Р. Миңнуллин иҗат һәм тормыш юлын өйрәнү.

2) Роберт Миңнуллин шигырьләрендә « туган тел» төшенчәсен камилләштерү.

«Дөнья гаме сыйган күңел» дигән темага әзерләнгән фәнни-тикшеренү эше кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора. Беренче бүлектә Р. Миңнуллин биографиясе, икенче бүлектә Р. Миңнуллин шигырьләрендә эш алымнарын һәм «туган тел» төшенчәсен камилләштерүгә багышланды.

Роберт Миңнуллинның күп кенә шигырьләре мәктәп дәреслекләренә кергән. Басылып чыккан егермеләп китабы да, туган тел дәреслеге, тормыш дәреслеге буларак, укучыга да, укытучыга да бик кирәк. Телебезҗаныбызның матурлыгын да, байлыгын да мавыктыргыч итеп күрсәтә алган ярдәмлек аның китаплары.

Роберт Миңнуллин 20 нче гасырның 80 нче елларыннан башлап, җәмгыятьтә һәм Татарстан Дәүләт Советында актив эшләп, халык, бигрәк тә балалар, яшүсмерләр, арасында татар халкының туган телен саклап калу кебек мөһим мәсьәләләрне күтәреп, аларны милли тарих һәмхалык язмышы таләп иткәнчә хәл итүдә җаваплы урыннарның берсен алып тора. Һәм бу игелекле, халыкка бик тә кирәк эшләрне башкарудаул армый-талмый эшләде. Язучы безнең җәмгыять тормышын читтән күзәтеп торучы булып түгел, ә бәлки шул «казанның эчендә кайнаучы буларак» истә калыр.

## *Китапка мәхәббәтне ничек тәрбияләргә?*

***Хафизова Гөлия Самат кызы,***
*Казан шәһәре Киров районы*
*70 нче мәктәпнең туган тел һәм әдәбият укытучысы*

*«Китап уку – гаҗәеп бер тәрәзә ул, шуның аша балалар дөньяны һәм үзләрен-үзләре күрәләр һәм танып беләләр.»*
В. А. Сухомлинский

Әдәбият дәресләрен бүгенге көн таләпләренә туры китереп, кызыклы итеп, балалар кызыксынырлык итеп ничек укытырга соң?

Беренче сыйныфта «Әдәби уку» дәресләре башлангач, баланы мәктәп китапханәсенә алып барырга киңәш итәм. Әле дөньяга күзе ачылып килә торган вакытта кызыксыну туа. Алар беренче тапкыр «китап йортына»

керәләр. Карыйлар, сораулар бирәләр, күзләре яна башлый, китапханә кагыйдәләре, тәртибе белән танышалар. Менә шуннан башлана индеул кызыксыну. Укучының бер кечкенә генә китапны өенә алып кайтып, әти-әнисенә күрсәтүе, укып чыгуы файдалы нәтиҗә бирә. Дәрестән тыш эшчәнлек вакытында да ешрак кереп, китапханәдәге апа табып биргән китаплардагы шигырьләрне уку галәмәт тә кызыклы булуы ачыклана, бала татар әдәбияты белән мөстәкыйль кызыксына башлый.

Башлангыч сыйныфта укучыларга дәфтәр башлатып, укыган китабының исемен, авторын, геройларын язып куярга, ике-өч җөмлә белән эчтәлеген дә язып бару да уңай нәтиҗә бирә. Бала тезисларны ае-рып алырга, төп мәгънәне язып куярга өйрәнә, геройларның исемнәрен истә калдыра, аларның характер үзенчәлекләрен билгеләп куя.

Дәресләрдә әдәби әсәрне өйрәнгәндә, мавыктыргыч итеп, интонация белән, рольгә кереп, кычкырып үзем укый башлыйм. Бала игътибарын юнәлтә, кызыксыну туа. Аннан үзләренә укытам. Озынрак хикәя бул-ганда, иң кызык урында, «Хәзер нәрсә була инде?» дигән урында тук- тап калам. Аннары нәрсә булганын, үзегез укып белерсез, дим. Балалар: «Укыгыз инде, беләсе килә бит», – ди башлыйлар. Чыннан да, балалар өйгә бирелгән әсәрне укып киләләр. Күп укыган бала иншалар, диктант-ларны җиңел яза, хаталарны да азрак ясый. Китапны яратып укыган бала текстның эчтәлеген аңлый, геройлары белән яши, алар өчен борчыла, елый, көлә, бер сүз белән әйткәндә, чын йөрәктән укый.

Үзлегеннән китап укый башлагач, аңа әсәрнең эчтәлеген сөйләтү, кирәк. «Блум сораулары» алымын куллануны кулай күрәм. Бу алымның асылы -төрле типтагы сорауларны кулланып уку дигән сүз. Теманы өйрәнгәндә, әсәрне тукталышлар ясап укыганд, һәр тукталыштан соң бер сорау бирелә. Блум сораулары төрле типта: гади, ачыклаулы, бәя бирүче, иҗади, практик, аңлатмалы була. Бу алым килеп туган проблеманы төрле яктан фикер йөртеп чишәргә ярдәм итә.

Бала кычкырып укый, ә үзе текст нәрсә турында икәнен уйламый. Бу проблемадан котылу өчен, урта сыйныфларда инсерт ысулын куллану файдалы нәтиҗә бирә. Бу ысулны куллануның уңышлы ягы шунда, уку-чы текстны пассив укымый, ә белергә, аңларга теләп, игътибар белән кат-кат укый. Укучыларны тамга кую билгеләре белән таныштырып чыгарга кирәк, чөнки текстның кырыена тамгалар куеп барырга туры киләчәк.

V *(галочка)* тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

+ *(плюс)* тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

– *(минус)* тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

**?** *(сорау)* тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

Укучылар проект эшләргә дә бик яраталар. «Минем беренче китабым», «Яраткан шагыйрьләрем», «Халык авыз иҗаты», «Туган ягым табигате» һ. б. шундый темаларга кечкенә китапчыклар ясатам. Балалар эзләнергә, китап тотарга мәҗбүр булалар.

Өлкән сыйныфлада балаларга буктрейлерлар ясарга тәкъдим итәм. Башта кәгазь вариантта, аннары презентация рәвешендә, зуррак классларда видеоролик рәвешендә ясарга өйрәнәбез. Китапнамә ясау өчен, китапның эчтәлеген белергә кирәк. Шулай итеп, балалар китапны укып чыгарга тиеш булалар.

Шушы урында «Кешегә балык бир, ул бер көн тук була; син аны балык тотарга өйрәт, ул көн дә тук була» дигән мәкалҗне китерәсем килә. Без баларны «балык тотарга» өйрәтнргә тиешбез.

Сүземне Роберт Миңнуллин сүзләре беләнтәмамлыйсым килә: «Иман нурын да, дөнья цивилизациясенең казанышларын да, халкыбызның бай тарихын да, рух ныклыгын да безгә китап биргән. Шуңа күрә дә без Китапка чиксез рәхмәтле. Бүгенге көндә безнең төп рухи таянычыбыз китап булырга тиеш. Китапсыз күңел – буш күңел, китапсыз йорт-нурсыз йорт, китапсыз милләт-киләчәксез милләт. Бәхетебезгә, без андый- лар түгел!Әлегә...»Әлегә генә түгел, һәрвакыт китаплы булыйк. Китап уку бүгенге көн балалары өчен матур гадәткә әйләнсен иде. Без моңа ирешергә тиеш.

## *Татар телен өйрәтүдә мәгъ лүмати-коммуникатив технологияләрне куллану*

***Хафизова Лидия Хәмзә кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы 156 нчы мәктәбенең туган тел укытучысы*

Заманча технологияләр кулланып эшләү ул – укучыда өйрәнә тор- ган фәнгә кызыксыну уятуга, аның танып белү активлыгын үстерүгә, укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштереп, белемнәрен тирәнәйтүгә зур ярдәм итә.

Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим.

Татар теле укытучысы өчен актуаль булган интернет-ресурсларны, бергә җыеп, төркемнәргә бүлсәң, мондыйрак бүленеш хасил булыр:

– укытучыларга методик ярдәм күрсәтә торган сайтлар һәм укытучыларның үз сәхифәләре;

– татар телен өйрәнүгә багышланган ресурслар;

– китапханәләр, тупланмалар;

– кече медиа-чыганаклар;

– мобиль кушымталар.

Безнең туган телебез – татар теле дә башка телләрдән калышмыйча, интернет челтәрендә.

2018 елның 12 ноябрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән «ШАЯН ТВ» телеканалы тәүге тапкыр эфирга чыкты. Шул ук көнне тапшыруларны онлайн-режимда карау мөмкинлеген тәэмин итүче shayantv. ru сайты эшли башлады. Сайт аша «ШАЯН ТВ» каналын Россиядә генә түгел, ә чит илләрдә дә карарга мөмкин. Телеканал заман белән бергә атлый үзенең татар теле өйрәтү ресурсларын булдырды. Алар хәзер бик актуаль. «ШАЯН ТВ» балалар телеканалының туган телебезне, мәдәниятне һәм мәгарифебезне саклап калуда әһәмияте зур дип саныйм. «ШАЯН ТВ» каналының төп максаты – татар телендә белем һәм тәрбия бирүче бердәм мәйдан булдыру; мультфильмнар, фәнни-популяр фильмнар, фикерләүне үстерергә ярдәм итүче тапшырулар аша балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту. Хәзерге вакытта каналда 20дән артык танып-белүне, белем бирүне һәм фикерләүне үстерергә ярдәм итүче оригиналь программалар эфирга чыга. Татар теленә иң яхшы мультфильмнар, халыкара дәрәҗәдәге фәнни-популяр, документаль һәм әдәби жанрдагы тапшырулар тәрҗемә ителгән.

Шаян тв каналында балалар өчен бик күп тапшырулар эшләнгән. Дәрес вакытында без рәхәтләнеп «Тукай оныклары», «Кичке әкиятләр»,»Шаян тарих», «Гаҗәп дөнья», «Гаҗәеп йорт хайваннары» һәм башка бик күп ташыруларны карый алабыз.

Мондый төр дәресләр үткәрүнең актуальлеге бәхәссез. Беренчедән, бүгенге көндә мәктәпләрдә татар халкы тарихы бик аз күләмдә укытыла яисә бөтенләй укытылмый. Шуңа күрә татар теле дәресләрендә, коммуникатив һәм тәрбияви максатларны күздә тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга үз халкының үткәне турында

күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдыра. Икенчедән, бүгенге көн укучыларында татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре турында күзаллау бик шартлы. Бигрәк тә зур шәһәрләрдә яшәүче балалар өлкән буын вәкилләре – әби-бабаларыннан читтә яши, шуңа күрә аларда татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләре турында хәбәрсез булып калуы ихтимал. Өченчедән, мондый тип информация укучыларда милли музейларга һәм аларның экспонатларына кызыксыну уята, укучылар музейга барыр алдыннан да күпмедер күләмдә мәгълүмат ала. Дүртенчедән, укучыларда татар халкының дөнья цивилизациясенең бер өлеше булуын, аның үз милли киенү рәвеше, күзаллаулары, гореф-гадәтләре, рухи һәм материаль байлыгы барлыгы турында фикер урнаша.

Мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән уңышлы файдала-ну, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикерен тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп ышанычы булып кала.

## *Дәресләрдә кейс технологиясен куллану*

***Хәйретдинова Гүзәлия Мөхәммәт кызы,***
*Балтач муниципаль районы,*
*Балтач урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кейс методы нигезендә уку-укыту процессын нәтиҗәле оештыру өчен яхшы кейслар һәм аларның дөрес куллану методикасы таләп ителә. Кейс – ул дәресләрдә анализлау өчен тормыштан алынган хәлләргә нигезләнгән проблемалы ситуацияләр. Ситуацияләрне анализлау вакытында укучылар төркемнәрдә эшләргә, нәтиҗә чыгарырга, дөрес карар кабул итәргә өйрәнәләр. Методик яктан дөрес төзелгән, мәгълүмати характердагы кейс-биремнәр укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерә, интерактив метод буларак укучыларда укуга уңай караш тәрбияли, укыту процессында тормыш белән бәйләнеш тудыра. Кейс методы укытучыга да яңача фикер йөртергә ярдәм итә, иҗади эшчәнлекне камилләштерә.

Кейсны төзүгә таләпләр:

1) төгәл, ачык максат куелу;

2) теманың актуаль булуы;

3) фикерләү сәләтен үстерүгә йогынты ясавы;

4) дисскуссиягә китерүе;

5) чишелешенең берничә булуы;

6) эшнең төркемнәрдә алып барылуы;

7) мәгълүмат (төрле чыганаклардан алынган материал, текстлар, сүзлекләр, сораулар язылган карточкалар һ. б.) салынган кейс әзерләү.

Кейс төрләре:

1) гамәли кейслар (тормыштан алынган реаль вакыйгаларны үз эченә ала)

2) өйрәтү характерындагы кейслар(уку материалын үз эченә ала).

3) фәнни– тикшерену кейслары (эзләнү– тикшеренү эшчәнлеген үз эченә ала).

<u>Кейс методының төп вазифасы</u>– укучыларны катлаулы проблемаларны чишәргә өйрәтү, танып белү активлыгын арттыру, аралашу осталыгын үстерү.

<u>Кейс методының белем бирүнең традицион формаларыннан аермасы:</u>

1) «укыту» стиле «өйрәтү» белән алышына;

2) укучыларда иҗади эшчәнлек сыйфатлары калыплаштырыла, аңлы рәвештә белем алуга китерә;

3) укытучы сайлаган проблемаларны укучылар мөстәкыйль чишәләр. Үзләштерелгән белем– күнекмәләрне файдаланып эшлиләр;

4) командада эшләү күнекмәләре камилләштерелә;

5) төрле кейс биремнәрен анализлап, укучы алдагы тормышына төрле ситуацияләрдән чыгу юлларының әзер схемаларын туплый, катлаулырак проблемаларны чишәргә күнекмәләре формалаша.

Кейс методын мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер укучылар белән эшләгәндә генә кулланырга мөмкин. Укуга мотивация булмау кейсларны өстән генә карап чыгу белән чикләнергә мөмкин. Кейс методы башка методлар белән чиратлаштырып алып барыла.

Кейсларны төрле формада бирергә мөмкин: видео-кейс, мультимедиа-кейс, язма кейс. Күләме ягыннан да кейслар төрлечә булырга мөмкин: бер бит язма материалдан алып берничә язма биткә кадәр. Ләкин зур күләмле кейслар укучыларга кабул итү өчен авыррак. Кейс методы белән эшләгәндә әзерләнгән кейслар белән бергә аларны куллану буенча методик тәкъдимнәр дә булырга тиеш.

Кейс төзү өчен методик тәкъдимнәр:

1) Кейсның темасын ачыклау (класс, бүлек, тема);

2) Кейсның максатын, бурычларын билгеләү.

3) Кейс өчен төп элементларны билгеләү (терминнар, төп төшенчәләр, презентация һ. б.)

4) Кейс төзү, дәреснең технологик моделен төзү.

5) Укучыларның тикшеренү эшчәнлеген оештыру өчен бирем әзерләү (сүзлек– глоссарий, өстәмә мәгълүмат чыганакларын әзерләргә мөмкин).

6) Кейсны куллану буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Эш алымнарының төрлелегенә ияләнгән укучылар, һәр очракта үз алларына максат куеп, шул максатка ирешү өчен ныклы эшчәнлек алып баралар.

Кейс технологиясен куллану укучыларны аралашырга, кеше алдында чыгыш ясарга, үз фикерен якларга, исбатларга, чит кешенең фикерен тыңларга, хөрмәт итәргә, анализларга өйрәтә. Ә иң мөһиме – балаларның белем алуга кызыксынуы арта, мотивация(теләк) уяна.

## *Туган тел һәм әдәбияттан белем бирүне оештыру: тәҗрибә*

***Хамидуллина Мәрьям Хасситулла кызы,***
*Абдулла Алиш исемендәге 20нче гимназиянең директор урынбасары,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге көн проблемасы булып мәктәпләрдә туган тел– татар телен укыту проблемасы тора.

Мәгариф һәм фән министры Илсур Гараевич Хадиуллин сүзләре белән әйтсәк «Проблемалар җитәрлек. Төп мәсьләләрнең берсе – белем сыйфатын күтәрү.» Шушы мәсьәләне чишү юлында ул 3 юнәлештә эш алып баруны искәртеп узды. Болар – эчтәлек, инфраструктура, кадрлар.

Кадрларга килгәндә, мәктәпләр бүгенге көндә татар телен тиешле дәрәҗәдә укыта алырлык укытучылар белән тәэмин ителгән.

Туган тел – татар теле дәресләрен нинди норматив документларга нигезләнеп укыту мәҗбүри икәнен дә һәр татар теле белгече, мәктәп администрациясе белергә тиеш.

Төп документ ул – «Россия Федерациясенең мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законы. 14 статьяда әйтелгәнчә «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программалары кысаларында Россия Федерациясе дәүләт телләрен укыту һәм өйрәнү федераль дәүләт белем

бирү стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен укыту һәм өйрәнү Россия Федерациясе дәүләт телен укытуга һәм өйрәнүгә зыян китереп гамәлгә ашырылырга тиеш түгел.»

Мәктәпнең төп документы – Төп белем бирү программасы (образовательная программа).

Төп белем бирү программасы Федераль Дәүләт стандартларын- да күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә нигезләнеп эшләнә, педагогик киңәшмәдә карала, директор тарафыннан раслана. Туган тел һәм туган әдәбият фәннәрен укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре, предмет эчтәлеге татар мәктәпләре, татар төркемнәре һәм рус төркемнәре өчен үрнәк программаларга нигезләнеп кертелә.

Димәк, ФДББС таләпләре нигезендә Төп белем бирү программасының барлык бүлекләре дә туган тел һәм әдәбият фәнен укыту материаллары белән тулыландырылган булырга тиеш.

Туган тел һәм туган әдәбият фәннәрен гомуми белем бирү системасында укыту мәҗбүри булганлыктан, әлеге фәннәр Укыту планының инвариант өлешендә, туган тел һәм туган әдәбият предмет өлкәсендә укытылырга тиеш. Сәгатьләр санына һәм фән исеменә (учебный предмет) аеруча игътибарлы булырга кирәк, ягъни «Туган тел һәм туган әдәбият» предмет өлкәсендә ике фән аерым күрсәтелә «Родной язык» һәм «Родная литература».

Дәресләрдә файдалану өчен галимнәр тарафыннан дәреслекләр эшкәртелде һәм федераль исемлеккә дә кертелде. (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 20 маеннан 254 номерлы боерыгы.)

Стандартны укучыларга җиткерү өчен белем бирү учреждениесе шушы исемлектә булган, укытучыларга дәрестә куллану өчен кулай булган дәреслекне сайлый ала.

Укытучыларның эш программалары фгос реестрга кертелгән үрнәк эш программаларына, һәм белем бирү оешмасының локаль актына нигезләнеп эшләнергә тиеш. (Положение о разработке рабочих программ).

Укучыларның белемнәрен тикшерү өчен укытучылар тарафыннан контроль үлчәү материаллары булдырыла, методик берләшмә утырышында каралып раслана. Ә уку елы ахырында белем бирү оешмасының локаль актына нигезләнеп арадаш аттестация уздырыла, «Мәгариф турындагы законның» 58 статьясында әйтелгәнчә, уку планында билгеләнгән эш төрләре педагогик киңәшмәдә карала, боерык нигезендә раслана.

Арадаш аттестация өчен эшләнгән контроль үлчәү материаллары да уку елы башында методик берләшмә утырышында каралып директордан расланган булырга тиеш.

Федераль дәүләт белем стандартында «дәрестән тыш эшчәнлек» төшенчәсенә, аны оештыру юнәлешләренә махсус урын бирелгән. Дәрестән тыш эшләрнең дәресләр белән тыгыз бәйләнештә булуын онытмаска кирәк. Чаралар укучыларның дәрестә алган белемнәрен киңәйтәләр, тирәнәйтәләр, ныгыталар. Ә укытучы алдында укучыны җәлеп итү бурычы тора. Дәрестән тыш эшчәнлек дәресләр чолтәре кысаларында да, алардан тыш та (ял көннәрендә дә, каникуллар вакытында да) оештырыла ала, тематикасы, юнәлешләре, төрләре дә бик күп: экскурсияләр, түгәрәкләр, секцияләр, түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, диспутлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, олимпиадалар, бәйгеләр, фәнни-эзләнү эшләре һ. б. Укучыларны әдәбиятка якынайту, китап укуга карата мәхәббәт тәрбияләүне дә дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында оештыру кирәк. Шундый чаралардан белем. ру оештырган әдәби марафонны бик отышлы саныйм.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру шулай ук программа нигезендә алып барыла.

Белем бирү оешмасында һәрбер документ оешманың локаль актларына нигезләнеп эшләнә. Узган уку елында прокуратура тикшерүен узганда бу ачык күренде. Оешманың сайтында да уку-укытуга кагылышлы барлык локаль актлар булу мәҗбүри.

